КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 13
13 октябрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

ҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Рәшит ЯГЪФӘРОВ.* Урыс дәүләте Казанны алган үз улларына һәйкәл салган, ә Ватанны саклау өчен тиңсез сугышка чыккан ата-бабаларыбызның исемен мәңгеләштерү өчен бер ядкарьташ та куелмаган.

5 *Зәки ЗӘЙНУЛЛИН.* Ялганны мең тапкыр кабатласаң, ул чынга охшап кала.

6 *Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.* Республикада халыкның милли бүленеше тигез диярлек, ә гәзитләр таралу ягыннан бер татарчага ике урысча туры килә.

11 *Мәгъсүм НАСЫЙБУЛЛИН.* Башкаларны хөрмәт итә-итә, татар халкы үз дөньясын онытып, үзенең икътисадына, табигатенә, мәдәниятенә, ана теленә игътибарны бермә-бер киметте.

16 *Роза ТУФИТУЛЛОВА.* Мәңгелек тәмамлана, ә гасыр ахырында без хатын-кыз табигатен бозуга ирештек.



МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Гасырлар буена дәвам иткән апартеид өчен Клерк Африканың илдәшләреннән гафу сорады. Рим католик чиркәве инквизиция корбаны Галилейны акларга мәҗбүр булды. Япония һәм Алмания хөкүмәтләре элгәреләренең хәрби җинаятьләре өчен дөнья җәмәгатьчелеге алдында ярлыкау сорадылар. Чикләнмәс хокуклардан файдаланучы тоталитар хакимият, халыклар язмышы белән теләсә нәрсә кыланып, җиребез күтәрә алмаслык гөнаһлар кылды. Бу ил кайчан тәүбәгә килер, кан-яшьле туфрагына кайчан бәрәкәт иңәр? Һәм кайчан да булса иңәрме ул?..

Мансуров

Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ

Рәшит ЯГЪФӘРОВ

Хәтерсезләр дәүләт төзерме?

1552 елның 15 октябре ул безнең милләт өчен олы фаҗига — дәүләтебезне югалту көне. Бу җәһәттән матәм көне уздыру шул фаҗигадә һәлак булган ата-бабаларыбызны искә алу, тарихи хәтеребезне югалтмау һәм «без — татарбыз» дигән үзаңыбызны барлау чарасы булып тора.

Кайберәүләр әйтә: үткән эшкә салават, хәтер көнен уздырмыйк, ул татар белән урыс мөнәсәбәтен боза гына диләр. Бу дөрес түгел. Киресенчә, мондый чараны уздыру татар белән урыс халкы арасындагы дуслыкны ныгытуга хезмәт итә. Ни өчен? Чөнки 1552 елгы фаҗига татар күңелендә тирән эз калдырган. Казанны алганда баскынчылар кылган вәхшилек халык хәтеренә җуелмаслык булып уелып калган. Татар күңеле рәнҗүле. Ә баскынчылар исә безнең бай җирләрне басып алу өстенә, җиңелгән халыкның «вәхшилеге» турында дүрт гасырдан артык миф таратканнар. Нәтиҗәдә, татар халкы турында урыс милләтендә алай гына да түгел, дөнья алдында «алар кыргый» дигән гайбәт урнашкан.

Татар дүрт йөз елдан артык кыерсыту, җәбер-золым күреп яшәгән. Бу хәлләр әлбәттә татар белән урыс арасындагы хәзерге мөнәсәбәтләрдә дә чагыла. Дөрес, дәүләт сәясәтендә алар һәрвакыт матур итеп күрсәтелә. Чынлыкта исә бу ике милләтнең күңел төпкелләрендә 1552 елда башланган ызгыш дәвам итә әле. Бу ике халык яшәгән җирләрдә милли мәгарифне, мәдәниятне күтәрү процессында без әлеге каршылыкны һәрдаим тоеп-сизеп торабыз. Миңа калса, хәтер көне уздыру — менә шушы ике милләт күңелендә дәвам иткән каршылыкка чик кую, тарихи дөреслекне ачыклау чараларыннан берсе. Билгеле ки, мондый каршылыкны «әйдәгез, дус-тату яшик» дигән сүзләр белән генә бетереп булмаячак. Күңелләрдәге бу чир урыс-татар арасындагы мөнәсәбәтләрдә әлеге дә баягы тарихи дөреслекне ачыклау белән генә «давалана» ала. Бу авыру татар халкы өстеннән «кыргый» дигән ярлыкны алып ташлануы, урыс халкының 1552 ел һәм аннан соңгы тарихи вакыйгаларга гаделлек күзе аша карый башлавы белән генә юылачак. Күренә ки, бу әле тиз генә китәсе чир түгелдер. Ә шулай да ышаныч бар. Хәтер көне традициягә әйләнсә, терелү процессы акрынлап башланыр дип уйлыйм.

Һәм шунысын да әйтик, 1552 елгы фаҗига ул Русия дигән империянең башлануы да бит. Әлеге «бергәлек» никадәр милләтләрнең башына җитте, никадәренә җәбер-золым күрсәтте. Хәзер Русияне демократик, федератив дәүләт итеп үзгәртеп кору чорында шундый вәхшәтле вакыйгаларны гыйбрәт итеп искә алу бик кирәк. Бу ачыктан-ачык хәрәкәт итүче шовинистик көчләрне айнытып җибәрү чарасы да булсын.

Кыскасы, мондый даталарны билгеләп үтү татар халкының үзаңын тарихи чынбарлык нигезендә үстерү, урыс һәм татар халыклары арасында чын тарихи җирлеккә корылган дуслыкны ныгыту һәм Русиянең демократик юл белән тәрәккый итүе өчен бик зарур. Шуның өчен дә аны традициягә әйләндереп, киңрәк күләмдә билгеләп узу үтә мөһим.

Билгеле булганча, шәһит киткән ата-бабаларыбызны искә алу хәзер Казанда һәм Татарстанның кайбер шәһәрләрендә (Чаллы, Түбән Кама һ.б.) урамнарда, мәйданнарда матәм митинглары, матәм җыеннары төсендә уздырыла. Бу рәвештә аны барлык район үзәкләрендә, авылларда да үткәрергә мөмкин. Кайбер җирләрдә аны зиратлар, тарихи урыннарны рәткә китерү өмәләре төсендә дә уздырырга була. Мәчетләрдә исә бу көнге намазны 1552 елда Казанны алганда һәлак булганнар рухына багышлау гадәткә кереп бара. Хезмәт коллективларында бер минутлык тынлык яки, тарихчы-белгечләр чакырып, хәтер көне турында әңгәмә уздыру мәслихәт.

Хәтер көнен мәктәпләрдә, балалар бакчаларында уздыруның әһәмияте турында тәфсилләп торуның кирәге юктыр. Мәктәпләрдә корбаннарны искә төшерүнең иң кулай алымы — «Хәтер сәгате» уздырудыр. Аны тарих укытучысы, алдан әзерләнеп, 15 октябрьдә (быел ул ял көненә туры килә) яки аннан алдагы көннәрдә үткәрә ала. Әдәбият укытучылары, китапханәчеләр белән бергә, тарихи романнар (әйтик, М.Хәбибуллин, Н.Фәттах, Батулла, Ф.Латыйфи әсәрләре буенча) укучылар конференциясе үткәрә алалар. Шулай ук китапханәләрдә татарның дәүләтчелеге тарихы, Казан ханлыгы фаҗигасе турында күргәзмәләр оештырырга мөмкин. Татарстан милли китапханәсендә, мәсәлән, быел шул вакыйгага багышланган зур күргәзмә ачылачак. Бу көнне изгеләр зиратына, сугышларда шәһит киткәннәрнең һәйкәлләренә чәчәкләр куюны да оештырырга мөмкин бит. Шулай ук татар дәүләтчелеге турында, әйтик, Р.Фәхретдинның «Казан ханнары» хезмәтен кулланып, викториналар, кичәләр үткәрү дә фарыз булыр иде.

Балалар бакчаларында бу датага багышланган махсус «иртәләр» оештыру да мөмкин эштер. Әйтик, туган тел, туган ил, татарның билгеле шәхесләре-баһадирлары турындагы әсәрләр җирле-

гендә андый чараны әзерләү [...]
түгел. Оештыручыларга «Салав[...]
күпере» журналында даими бир[...]
лүче рәсемле тарихи хикәяләр[...]
шигырьләр дә ярдәмгә киләче[...]
Әйтергә кирәк, әлегә татар тар[...]
хына, Казан фаҗигасенә багы[...]
ланган хезмәтләр азрак. Ләкин х[...]
тер көнен әзерләгәндә кулланы[...]
га мөмкин булган әдәбият бар. Б[...]
җәһәттән Р.Фәхретдин, Ш.Мәрҗ[...]
ни, М.Худяков, А.Халиков, С.А[...]
шев, Ә.Мөхәммәдиев, Д.Исхак[...]
А.Хуҗин, Г.Дәүләтшин, И.Изм[...]
лов, С.Шәмси хезмәтләре файд[...]
лы чыганаклар буларак хез[...]
итәр. Шулай ук бу чараларда «Ка[...]
зан утлары», «Татарстан», «Иде[...]
«Мирас» журналларының со[...]
3-4 елдагы октябрь саннарын[...]
басылган язмаларга игътибар б[...]
рү урынлы булыр. Һәм мондый ч[...]
кта Х.Нәфыйков, Р.Шәмсетди[...]
кебек рәссамнарның әсәрләре [...]
ямь биреп торыр. Чараларны әз[...]
рләү барышында тарихи леген[...]
лар, риваятьләр, бәетләр дә к[...]
ланырга онытмагыз.

Күрәсез, материаллар юк түге[...]
Безгә бу әһәмиятле чараны [...]
әзерлек һәм тырышлык белән у[...]
дырырга гына кала. Киләчәктә [...]
көн рухи тормышыбызның аерг[...]
гысыз бер өлешенә әверелс[...]
иде. Һәм бу игелекле эштә хөк[...]
мәтебезнең дә катнашуы сораг[...]
билгеле. Без инде, милли оеш[...]
лар вәкилләре, бу чараның ха[...]
күңеленнән, рухыннан чык[...]
бер нәрсә итеп күрдек һәм ан[...]
традициягә әйләндереп, киләбе[...]
Хәзер хәтер көненең төп макс[...]
тын дөрес аңлап, «бу — татар э[...]
стремистлары уйлап чыгарган н[...]
рсә генә», дигән фикердән китәр[...]
вакыт җитте шикелле.

Тагын бер мөһим зарурият[...]
игътибар юнәлтәсе килә урыс д[...]
үләте Казанны алганда һәлак б[...]
лган үз улларына һәйкәл салга[...]
ә Ватанны саклау өчен тиңсез с[...]
гышка чыккан ата-бабаларыб[...]
ның асыл сөякләре әле дә [...]
йөргән урамнар, йорт-бинал[...]
диварлар астында таралып я[...]
Аларның исемен мәңгеләште[...]
өчен бер ядкарьташ та куелмаг[...]
Без Татарстан хөкүмәтенең ба[...]
калабызны саклаучыларга һәйк[...]
салуны, Казан Кремлен реставр[...]
цияләү программасын кертеп, [...]
халыктан җыелган иганәләрне [...]
файдаланып, тизләтүен телибе[...]
Шулай ук Татарстан Дәүләт Сов[...]
ты сессиясендә 15 октябрь көн[...]
рәсми рәвештә «Матәм көне» иг[...]
игълан ителүен көтәбез. Бу тур[...]
да милләттәшләребез дә хөкү[...]
дайрәләренә үз фикерләрен [...]
керерләр дип уйлыйбыз.

Кыскасы, дәүләтчелекне тор[...]
зу юлына аяк баскан республи[...]
аның халкы тарихи хәтерен [...]
чак яңартып торырга тиеш. Хәт[...]
сезләр дәүләт төзи алмый.

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар
5 6 7 1 2 3 4

Якты көн, илһам бир аңа!..

Укучыларыбыз инде белә: әдәбиятыбызның хөрмәтле аксакалы, Татарстанның халык язучысы, җәмәгать эшлеклесе Гариф ага Ахунов ошбу елның сентябрь аенда җитмешне тутырды. Ә менә 9 октябрь көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академиясе театрында киң җәмәгатьчелек бу бәйрәмне зурлап-олылап билгеләп үтте.

Юбилярны котларга язучының туган ягы Арчадан, ул укыган Арча педагогия училищесыннан, башка күп кенә төбәкләрдән кунаклар килде. Аны Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев шәхсән котлады, җөмһүриятебез халкы исеменнән тәбриклап рәхмәт белдерде, Мактау грамотасы, истәлек сәгате тапшырды. Язучыны шулай ук Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаков, «Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Ринат Галиев, республикабызның иҗат берлекләре, Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим һәм башка бик күп, бик күп кунаклар тәбрикләде. Гариф ага һәм аның хәләл җефете Шәһидә ханымны котлап килгән телеграммалар укылды. Тантананың рәсми өлешен кереш сүз белән Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев ачты һәм алып барды. Ул юбилярга Гаяз Исхакый исемендәге бүләкнең дипломын һәм акчалата өҗерен тапшырды.

Кичәнең икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

Тантаналы кичәдә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев, Премьер-министр Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

10 октябрьдә әдипнең каләмдәшләре, кунаклар аның туган ягына — Арча районына сәфәр чыкты. Нәкъ менә шушы урында Татарстан Фәннәр академиясенең президенты Мансур Хәсәновның тәбрикләвендә әйтелгән сүзләргә игътибар итәсе килә. «Гариф Ахунов, кайда гына булмасын, нинди генә ерак илләрдә йөрмәсен, нинди генә гүзәл җирләрне күрмәсен — һәрчак үзенең туган җире, туган авылы Өчилене сагынды, аны яшәтү турында хыялланды», — диде академик.

«Мәдәни җомга» газетасы да Гариф ага Ахуновны котлау-тәбрикләүләргә чын күңелдән кушыла: аның шигыренә язылган җырны чак кына үзгәртеп, янә кабатлыйк: якты көн, илһам бир тагын да Гариф агага!..

Уфа — Казан арасы

Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев Башкортстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүнең биш еллыгына багышланган тантаналарда катнашты.

Тантаналы җыелышта катнашучылар М.Шәймиевнең чыгышын җылы каршыладылар. Ул, аерым алганда, түбәндәгеләрне билгеләп үтте: дәүләт суверенитеты турында Декларацияләр игълан ителгәннән соң үткән биш ел эчендә без республикаларыбызның хокукый нигезләрен ныгыта алдык. Үз Конституциябезне һәм бик тә мөһим законнарны кабул иттек. Без, ике яклы шартнамәләргә һәм хокуматара килешүләргә кул куеп, Үзәк белән принципиаль яңа мөнәсәбәтләргә күчтек. Заман никадәр кенә авыр булмасын, халыкларыбызның рухи тормышы үзгәрде. Татарстан һәм Башкортстан үз йөзләрен, үз тавышларын таптылар, аларны халыкара мәйданда таный башладылар.

Татарлар һәм башкортлар кыен чакларда бер-берсенә булышып яшәделәр, бергәләп көрәштеләр. Тарихи тәҗрибәгә таянып, Башкортстан һәм Татарстан демократизм, татулык һәм тотрыклылык үрнәге була алалар һәм булырга тиешләр, дип басым ясап әйтте М.Шәймиев.

Театрның һәм драматургның юбилей сезоны

Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының 90 нчы сезоны ачылу Туфан Миңнуллин исеме, аның әсәрләре белән нык бәйләнгән. Драматургка 60 яшь тулу уңае белән театрда Татарстан һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан һәм Русиянең дәүләт премияләре лауреаты иҗат иткән спектакльләр декадасы уза, «Гөргөри кияүләре», «Җанкисәккәем» дигән әсәрләрнең премьерасы була. 17-20, 27-29 октябрьдә Татарстан тамашачылары шушы спектакльләр белән танышачак. Ә 14 октябрьдә сезон ачылуга багышланган театр бәйрәме узачак. 21 октябрьдә — Татарстан Республикасының атказанган артисткасы Наилә Ибраһимованың иҗат кичәсе.

Театрның кече залы «Инсаният» фонды эшчәнлеген яктырта. Биредә Рәшидә Җиһаншинаның «Үлгән ярларым», «Сөйдергеч ботие» дигән әсәрләре уйналачак. Балалар өчен «Авыл эте Акбай», «Акбай нигә күңелсез?» дигән тамаша күрсәтеләчәк. Яңа сезонда җәмгысе җиде спектакль премьерасы булачак.

Ә Хәтер көнендә театр сәхнәсендә «Идегәй» трагедиясе куела.

Халкыбызның яраткан театры юбилей сезонын ачып, дусларын, театр сөючеләрне үзенә чакыра.

Үнче булса да җомга көн бит

Бүген, 13 октябрьдә, Казандагы офицерлар йортының колонналы залында Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең камера һәм опера музыкасы бүлеге үзенең чираттагы концерт сезонын ачып җибәрә.

Биредә татар, урыс, чит ил композиторларының вокаль һәм инструменталь әсәрләре яңгыраячак. Концертта Лариса Маслова (виолончель), Рәүф Аббасов, Георгий Ибушев, Илсур Сафин кебек танылган башкаручылар катнаша. Шулай ук «Кантилена» кыллы квартеты да чыгыш ясар дип көтелә.

«Ядкарь» конкурсы

Татарстан җөмһүриятенең Мәдәният министрлыгы, Композиторлар берлеге, Язучылар берлеге һәм М Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры моннан ике ел элек татарча музыкаль сәхнә әсәрләре өчен опера, балет, музыкаль комедия жанрлары, шулай ук аларга либреттолар язу буенча «Ядкарь» дигән республика конкурсы игълан иткән иде. Инде бәйге тәмамланып килә. Профессиональ язучылар һәм профессиональ композиторлар гына катнашкан конкурска элек башкарылмаган, нәшер ителмәгән, сәхнәгә куелмаган әсәрләр генә кабул ителә.

Барлык материаллар ябык конвертта кабул ителә. Кульязмалар ике нөсхәдә тушь һәм каләм белән язылган (ноталар) яисә машинкада басылган (әдәби материал) булырга тиеш.

Документлар 1995 елның 25 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420014 Казан, Кремль, 3 нче подъезд, Мәдәният министрлыгы.

Әби милицияне «дуэль»гә чакыра

Казаннан сиксән яшьлек пенсионер Ольга Петрова «ирекле төстә утлы корал тапшырган өчен» акча алу нияте белән Совет районы эчке эшләр идарәсенә ... дуэль алтатары илтеп бирә. Белгечләрнең әйтүенә караганда, әлеге корал чит ил остасы тарафыннан 1811 елда эшләнгән, һәм ул бу әбигә дворян бабасыннан калган. Пенсионерга мондый истәлекле ядкарьдән аерылу бик кызганыч, әлбәттә, әмма бүгенге авыр тормышта җан асрар өчен акча да кирәк. Әгәр баллистик тикшерү алтатарны атуга яраклы дип тапса, милициядә әлеге коралны кабул итеп алачаклар.

Татарстан Республикасы Президенты Указы

Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән бүләкләү турында

Татар әдәбиятын үстерүдәге әһәмиятле шәхси хезмәтләре өчен язучы **Ахунов Гарифҗан Ахунҗан улын Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы** белән бүләкләргә

Татарстан Республикасы Президенты

М.Ш.ШӘЙМИЕВ.

Казан, Кремль, 1995 елның 9 октябре.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Сынлы сәнгатьне үстерүдәге иҗат белгечләре әзерләүдәге зур хезмәтләре өчен һәм оештырылуына 100 ел тулу уңаеннан **Казан сәнгать училищесы коллективы** Татарстан Республикасы **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде

* * *

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм Халыкара коммерция берлеге карары белән язучы **Гариф Ахуновка** «Идел кызы» романы һәм соңгы еллардагы публицистик эшчәнлеге өчен 1995 елның **Гаяз Исхакый исемендәге премиясе** бирелде

* * *

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе ректоры **Беляев Рәис Кыям улына «Русия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре»** Казан сәнгать училищесы укытучысы **Юдина Татьяна Михайловнага «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исемнәр бирелде

Буалылар 600 мең кешене бер елга шикәрле иттеләр

Буа кырларында шулкадәр кешенең чәен татлы-баллы итәрлек шикәр чөгендере үстерелгән. Алай гына да түгел, җыеп-җыештырып шикәр заводларына озатылган. Шулай итеп, буалылар дәүләт алдында килешү йөкләмәләрен үтәгәннәр. Бу хакта редакциягә район хакимияте башлыгы Абделхәй Хәйруллов телеграммасында әйтелә.

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

11 октябрьдә Татарстан Дәүләт Советының дүртенче пленар сессиясе үзенең эшен башлады.

Казанның «УНИКС» залында Анатолий Лупповның «Карурман» симфониясе белән Татарстанның һәм Казагыстанның халык артисты Фуат Мансуров дирижерлык итүче республика симфоник оркестры үзенең концерт сезонын ачып җибәрде.

Мәскәүдә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә «Сәламәт дөньяда балаларның сәламәтлеге өчен» дип аталган Беренче бөтендөнья хәйрия сәнгать фестивален оештыруда һәм үткәрүдәге хезмәте өчен Мактау дипломы тапшырылды.

Казандагы үзәк кием-салым базары үзенең гәзитен чыгара башлады. Мәгълүмат-белешмә рәвешендәге бу басма базарга килүчеләргә бушлай таратыла.

Молдова Президенты Мирча Снегур 9 октябрьдә Кишиневта Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Равил Моратовны кабул итте.

Чаллыда Татарстан Президенты Кубогына узган якшәмбедә футбол буенча үткәрелгән беренче халыкара турнирда Белоруссия спортчылары җиңеп чыкты

Республика милли китапханәсендә Хәтер көненә багышланган күргәзмә ачылды.

ВИКОда 17 фирма катнашында «Франция-95» дип аталган күргәзмә эшли башлады

Зеленодолда район һәм шәһәр хакимияте оештырган «Яшел Үзән» гәзитенең тәүге саны басылып чыкты.

Узган җомгада Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның өенә Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев кунакка килеп, юбилярны җылы тәбрикләде, алар иҗат берлекләренең хәл-әхвәле, нәшрият эше, китап чыгару һәм аны таратудагы кыенлыклар, милли әдәбиятны үстерү хакында фикер алыштылар.

Беренче биттә Нәҗип НӘККАШ эше.

Тарих архивтан башлана

Алматы шәһәрендә БДБ һәм Балтыйк буе илләренең дәүләт архив эшләрен башкаручыларының җитәкчеләре тагын очрашты. Анда Татарстан Республикасы дәүләт архив эшләрен башкаручылар да бар иде.

Очрашуда архив эшләре мәгълүмат үзәге положениесе, шулай ук гражданнарның социаль-хокукый үтенечләрен башкарып чыгу чаралары турында фикер алыштылар, Татарстан Республикасында архив эшләре буенча кадрлар әзерләү тәҗрибәсе турында мәгълүмат тыңладылар.

Республикабыз вәкиле Казакъстан Республикасында архив эшләренең 200 еллыгына багышланган тантанада катнашты һәм чыгыш ясады.

Тиздән кубызлы да булачакбыз

Казандагы музыка кораллары фабрикасы акционерлык җәмгыяте кубызлар һәм курайлар җитештерә башлады.

Торгынлык кичергән бу предприятие акрынлык белән булса да аякка баса. Тиздән «Казан» пианиносы кибетләрдә яңадан күренер. Чимал булмау сәбәпле ул җитештерелми башлаган иде. Гармуннар, баяннарның да сыйфаты яхшырачак, чөнки предприятиегә бу эшнең барлык серләрен белүче тәҗрибәле осталар чакырылды.

«Идегәй» дастаны Төркиядә нәшер ителә

Истанбулда тиздән «Идегәй» дастаны китабы нәшер ителәчәк. Бу игелекле эшкә «Түрксой» оешмасы алынды. Әлеге оешма Төркия, Әзәрбәйҗан, Төркмәнстан, Урта Азиянең һәм башка дәүләтләр мәдәният министрлыклары тарафыннан төзелгән иде. Татарстан Мәдәният министрлыгы «Түрксой» оешмасы эшчәнлегендә күзәтүче сыйфатында катнаша.

Татар халкының әлеге мәшһүр дастаны — рәсемнәргә бай һәм ике телдә — татарча һәм төрекчә дөнья күрәчәк. «Идегәй»нең татарча варианты укучыга латин һәм кирилл графикасында тәкъдим ителәчәк.

«Түрксой»ның утырышлары аңа әгъза булып кергән илләрнең башкалаларында чират белән үткәрелә. Әлеге оешманы гамәлгә куючыларның берсе — Әзәрбәйҗан мәдәният министры, танылган эстрада җырчысы Полад Бюль-Бюль оглының әйтүенә караганда, «Түрксой» оешмасының киләсе елгы утырышларының берсе Казанда үтәчәк.

«Дуслык»ның кадере читтә ныграк беленә

Ташкенттагы авиация җитештерү берләшмәсенең мәдәният һәм техника сараенда «Дуслык» исемле татар эстрада театры үзенең яңа программасын тамашачылар хөкеменә тәкъдим итте. Һәвәскәр коллектив бу чыгышын театр оештырылуның 10 еллыгына багышлады.

«Дуслык» эстрада театрын Үзбәкстанда гына түгел, күрше республикаларда да яхшы беләләр. Әлеге коллектив җыр фестивальләрендә дә, төрле бәйрәмнәрдә дә чыгыш ясый. Аның җырлары җөмһүрият телевидениесенең «Күңелем җылысы», «Безнең мирас» программаларында, Үзбәкстан радиосы аша да еш яңгырый. Бу тату коллектив җыр сөюче милләттәшләребезнең күңелләрен киләчәктә дә сафландырыр, аларга онытылмаслык очрашулар бүләк итәр.

Серле Себернең таныш сәхифәсе

Түбәндәге өлкә гыйльми китапханәсенең Русиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Асия Сәйфуллина җитәкчелек иткән нәшрият бүлеге «Себер татарлары» дип аталган үзенчәлекле библиографик күрсәткечнең яңартылган басмасын төзүне тәгәлләде. Бу төзәтелгән, тулыландырылган икенче басмага 500 гә якын авторның гыйльми мәкаләсе тупланган. Алар үз вакытында республика, өлкә матбугатында һәм атналык «Татар иле» газитендә дөнья күргән.

Әлеге бүлек хезмәткәрләре Себер татарларының Ислам динен кабул итүенә 600 ел тулу уңаеннан фәнни материаллар җыентыгын да әзерләп бетерделәр.

Гыйраклыларга барып гыйбрәт ал син...

Гыйракта үткәрелгән халыкара фольклор фестивалендә катнашкан Татарстан делегациясе Казанга әйләнеп кайтты.

Сәфәрне «Татарстан-Гыйрак» дуслык җәмгыяте оештырды. Делегация составында музыкантлар һәм җырчылардан тыш, табиблар, укытучылар, эшмәкәрләр дә бар иде.

Татарстан вәкилләре фестивальдә катнашудан тыш, Гыйракта сәламәтлек саклау, сәүдә һәм сәнәгать министрлыкларының рәсми вәкилләре белән очраштылар. Әңгәмә вакытында «Татарстан-Гыйрак» дуслык җәмгыяте рәисе А.Михеев Гыйрак балаларын Татарстан хастаханәләрендә дәвалау мөмкинлеге барлыгын әйтте. Ә Багдад университетында сүз нигездә югары белем мәсьәләләре, ике ил арасында белгечләр алмашу турында барды.

Хәтер көне Азатлык мәйданыннан башлана

Алабугада Хәтер көнен билгеләп үтү Азатлык мәйданында җыен белән башланып китәчәк.

Җыеннан соң мөселманнар шәһәр буйлап Бөек Болгар дәүләтеннән ядкарь булып калган изге урынга — Шәйтан каласына юл алачак. Анда шәһитләр рухына багышлап намаз укылачак.

Җыен бертуган Кашаповларның матди ярдәме белән оештырыла.

Сез бу рәсемдә халкыбызның танылган рәссамы Кәнәфи Нәфыйковны күрәсез. Ул соңгы елларда актив иҗат итә. Моңа дәлил эзләп ерак барасы юк — «Казан» милли мәдәният үзәгендә аның шәхси күргәзмәсе зур уңыш белән бара. Рәссамның тагын бер иҗат җимешен ватанпәрвәрләр аеруча якын кабул итте — К.Нәфыйков 1552 елда Казанны Иван Грозный яуларыннан саклаганда шәһит киткән бабаларыбыз истәлеген мәңгеләштергән һәйкәлнең эскизын эшләде.

Солтангалиев турында, ниһаять, чын дөресен белербезме?

Казан документаль фильмнар студиясендә күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Мирсәет Солтангалиевкә багышланган ярты сәгатьлек документаль фильм төшерелә. Ул — Татарстан Республикасының Дәүләт киносы заказы буенча эшләнә.

Фильмны төшергәндә тамашачыга әлегә кадәр билгеле булмаган документлар, фоторәсемнәр, фильмнардан өзекләр файдаланыла. Анда академик И.Таһиров, язучы Р.Мөхәммәдиев, сәясәтче Р.Хәким Мирсәет Солтангалиев турындагы фикерләре белән уртаклашалар. Документаль фильмның сценарием Б.Солтанбәков белән Н.Үтәгәнова язган.

Фильм экранга шушы елның декабрь аенда чыгачак.

Татарстанлыларны атыш та, суеш та, җенси азгынлык та тәмам туйдырган икән

Республика кинотеатрлары эшчәнлеген тикшергәннән соң «Таткиновидеопрокат» хезмәткәрләре, «Татарстан тамашачысын чит илдән кергән атыш, суеш, җенси азгынлык турындагы фильмнар тәмам туйдырып бетерде», дигән нәтиҗәгә килде.

Билет бәяләре ике-өч мең сум булуга карамастан, кинотеатрлар үз-үзләрен акламыйлар. Казандагы «Победа» кинотеатры, мәсәлән, инде икенче ай прокатка яңа фильмнар сатып алырга акча таба алмый. Ремонттан соң башкалабыздагы «Звезда» кинотеатрының язмышы ничек булып бетәчәге дә әлегә билгеле түгел.

Ягу сезоны башлангач, кинотеатрларның чыгымы тагын да арта. Бу хәл, һичшиксез, билет бәяләренең тагын да кыйммәтләнүенә китерер. Болай да ярым буш кино заллары тәмам бушап калмас микән?

Кәнфитләрнең... тәме үзгәрә

«Заря» акционерлык җәмгыятендә «Фея» һәм «Снежинки» конфетлары эшли башладылар.

Тәм кертү өчен аларга Алманиядән кайтарылган кокос бортекләре кушыла, хуш исле булсын өчен Швейцариянең «Флоксман» фирмасында ясалган тәмләткеч өстәлә.

«Красная шапочка» конфетларын төрү өчен яңа җайланмалар эшли башлады. Ә «Ассорти» конфетын тутырырга Кипрдан бик матур тартмалар кайтты.

3 нче һәм 4 нче сәхифәләрдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

КАРАШ

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН

Чынга охшаш ялган

Русиянең 1994 елның декабрендә Ичкериягә басып керүе өченче тапкыр чечен халкының азатлыгын буарга маташуы булды Берегын кесендә Борис Ельцин боерыгы белән егерме сигез хәрби транспорт самолеты (1992 елның июнь [ае]) Грозный аэродромына төшеп утырган иде «По просьбе чеченского народа!» дигән аклану да табтылар Тик бу диверсия барып чыкмады Җәүһәр Дудаев гаскәрләре аэродромны инде бөҗрага алып өлгергәннәр иде Егерме биш самолет төшеп утыруга, аэродром уртасына таш төялгән зур самосвал чыгып туктый Шуның самолет егерме алтынчы самолыктан егерме алтынчы само-, кая төшеп утырырга белмичә, ыны белән аэродром читендә бер сазлыкка чума. Без Әмир Мәхмүтов белән шул елның августында Чечняга килгән чакта, әлеге очкыч һаман да шунда ята иде әле. Чеченнар әсиргә төшкән урыс десантын автобусларда Владикавказ ягына озаталар Аннары, Мәскәү белән сөйләшүләр барышында, аларны кире Русиягә кайтарып җибәрәләр Тик Мәскәү яхшылыкка яхшылык белән җавап бирмәде Автурханов җитәкчелегендә оппозиция оештырып, аны коралландыра башлады Әмма бу азатлыклар, бик аз санлы булу сәбәпле, әллә ни кыра алмадылар. Дудаев гаскәрләре аларны бер көндә туздырып ыргытты. Урыслар бу гаскәрләрне «бандформированиеләр» дип әйтергә яраталар Гүя Җәүһәр Дудаев сугышчылары Мәскәү урамнарында сугышып йөри һәм монда гаҗәпләнерлек нәрсә дә юк Русия колонизаторлары элек-электән башка халыкларга ялган исем тагу белән шөгыльләнәләр Моның шулай икәнен аңлау өчен тарихка күз салу да җитә

1920 елның җәе. Кызыл Армия 1917 елны Русия составыннан аерылып чыккан Польшага бәреп керә. Комиссарлар үз илен, ирекен, азатлыгын саклап сугышкан поляк гаскәрләрен ак поляклар, поляк бандитлары, поляк интервентлары дип атыйлар Әйтерсең, бу сугышны Совет Русиясе түгел, ә Польша башлап җибәргән

1921 ел Кызыл Армия Әзәрбәйҗан, Грузия, Әрмәнстан җирләрен басып ала Урыс алып килгән яңа чирне — коммунизм чирен үз җиренә кертергә теләмичә коралга алынган бу халыкларны да милләтчеләр, бандитлар дип атыйлар

1920 елдан 1935 елга кадәр азатлык өчен көрәш алып барган Урта Азия халыкларына (бигрәк тә үзбәкләргә) басмач дигән исем тагыла Юк, җәмгать, урыс үзе басмач булды ул заманда.

1934-1940 еллар Фин сугышы Хәзер инде беркемгә дә сер түгел бу суешны да Кызыл Армия башлады Нинди генә төскә буясаң да, ул Русия армиясе инде Аны чит илләр генә түгел урыслар үзләре дә урыс армиясе дип атадылар Тик пропаганда шундый яхшы эшләде ки, урыслар барча халыкларны да сугышны Финляндия башлады, дип ышандыра алуга ирештеләр Финнар... ак финнарга әверелде Гаскәр башында Маннергейм дигән фашист тора, имеш Сүз уңаеннан шуны искәртеп узыйк бу хәрби җитәкче 1917 елга кадәр урыс генералы була.

1979-1987 еллар Әфган сугышы Мөҗәһитләрне ни өчендер басмач дип атадылар Чөнки Урта Азиянең үзендә басмачлар хәрәкәте күтәрелүеннән курыктылар Урыс оккупантларына каршы сугыш хәрәкәтләре алып барган мөҗәһитләрне «дошман» дип атау кулайрак булып чыкты

Инде менә хәзер Русия гаскәрләре Чечняга басып керделәр Янәсе, әлеге республика Русия составында һәм Чечняның аннан аерылып чыгарга хакы юк Конституцион тәртип урнаштырырга кирәк икән Нинди Конституция турында сүз барырга мөмкин монда?

Узган гасырда чечен халкын суйган Кавказны канга батырган 1944 елның февралендә чеченнарны илләреннән сөргән кышкы карлы-буранлы юллардан үтә алмаган картларны хатын-кызларны бала-чагаларны авыл мәктәпләренә мал абзарларына тутырып (халыкның 27 проценты) тереләй яндырган Русия Конституциясе ич ул

Оят юк Русия җитәкчеләрендә! НАТО Югославиядә сербларны бомбага тота башлагач Русия шуңа каршы «протест» белдерде Халыкара кануннар бозыла икән дә НАТО агрессор икән ә сигез ай буена Ичкерияне бомбага тоткан Русия кем? НАТО Русиядән үрнәк алып сербларны бомбага тота Русиягә ярагач димәк, НАТОга да ярый!

Менә шундый хәлләр җәмәгать Ирексездән Геббельсның «Ялганны мең тапкыр кабатласаң, ул чынга охшап кала» — дигән сүзләре искә төшеп китә Аллага тапшырдык инде «бердәм һәм бүленмәс Русия» өчен көрәшүче урыс шовинистларының сүзләре мәсләкләре һәм гамәлләре дә фашистларныкыннан бер дә ким түгел

Җәнәт әңгәмә

Вафирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА:

«Телем аркасында мине җырымнан аерылырга да мәҗбүр иттеләр»

— Мәрхәбә, Вафирә ханым, [як]ынарак кына чыга башлаган «Мәдәни җомга» газите чәйханәсенә [х]уш килдең!

— Шушындый бер олы газитнең [чы]га башлавын мин җаным-тәнем белән көтә идем. Бу — әдипләр, сәнгатькәрләр, сәясәтчеләр, философларның рухи мәркәзе булыр дип өметләнәм.

— «Мәдәни җомга» белән Вафирә Гыйззәтуллинаның киләчәктә мөнәсәбәт-мөгамәләсе ничегрәк булыр?

— Гомер буена сезгә хезмәт итәргә әзермен. «Мәдәни җомга»ның мәйданы киң. Олы шәхесләр, онытыла язган сәнгать әһелләре турында зур-зур мәкаләләр язар идем.

— Ә яшьләр турында? Һәвәскәрлектән профессиональ сәхнәгә менгән җырчылар турында?

— Яшьләрнең үз юлы Әлбәттә, газит алар иҗатын да яктыртырга тиеш.

— Вафирә ханым, син азатлык хәрәкәтенә кушылып, шау-шулы мәйданга атылдың. Үзебезнең байлыгыбызны ятларга бушлай бирмәс өчен ике тапкыр Әлмәт нефтьүткәргеченә сәфәр чыктың, кыйналдың, нәмаешларда үз тавышыңны кызганмыйча, җырладың, сөйләдең. Бу ысуллар искердеме, алга таба көрәш ысулларын ничегрәк күзаллыйсыз?

— Шуның аркасында мине җырымнан аерылырга да мәҗбүр иттеләр. Әмма бу әле көрәшнең дәвамы гына. Алда мостәкыйльлек өчен тагын да зуррак көрәш көтә Хәйләкәр, мәкерле көчләр белән урамда кычкырып кына көрәшеп булмас.

— Син үзеңне Русиянең Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидат итеп куйгансың икән... Кайчандыр Русия биргән артистлык таныклыгын мәйданда яндырган Вафирәнең Думада вәкил булып утыруы сәеррәк тоелмасмы?

— Әйттеләр Вафирә милли хәрәкәт мәнфәгатьләрен саткан икән, Дума вәкиле булырга йөри икән, диделәр Юк! Сатмады Вафирә үз милләтен Көрәш ысулларын гына үзгәртте Мине Русия мөселманнарының «Нур» җәмгыяте Думага тәкъдим итте Каршы килмәдем Русия Думасында Зәки Вәлидиләр Йосыф Акчуралар Садри Максудилар утырган татар халкының мәнфәгатен яклаган Мин — аларның бер оныгы пабаса. Юкса Русия эчендәге алты миллион татарны кем яклар?

Әңгәмәне **АЛТАТАР** әзерләде

Рахмай ХИСМӘТУЛЛА

«Шахта» көе

(Нәсер)

Чит җирләрдә бәхет эзләп, бөтен ил буйлап чәчелгән, сибелгән татарларны Олы Сабантуй мәйданы[на] җыеп, бер генә тапкыр, мең елга бер генә тапкыр [бу]лса да, «Шахта» көен тыңлатасы иде Туган җирләрен, кыр-басуларын ташлап киткән милләттәшләрнең бу җырында и күпме яшәлмәгән гомерләр мо[ңы], күпме өметләр, и күпме күмәк сагыш!

Көйне башта бик озын, бик моңлы итеп уйнарлар [и]де. Моң дулкыннары, чоңгыллар буйлап үткән сы[ман], бер югары менәр, бер түбән төшәр иде Анннары, кинәт ашкынып, кызулана барып, биеккә-биеккә, бик югарылыкка талпыныр, ярсып, тетрәндергеч давылга әверелер иде Караңгы шахталар яктырыр, күмерләр көчлерәк янар, күзләр шахталардан йолдызларга төбәлер иде.

Гасырлар буена бер-берләрен күрмәсәләр дә, һаман да бер телдә сөйләшүче, һаман да бер моңны тын да алмыйча тыңларга яратучы татарлар бер-берләренә карап таң калырлар, шаккатарлар иде Мөокенләнеп дөнья куып, киләчәк һәм бетәчәк байлык артыннан чабуларына үкенеп, туганлыкларын онытып бер-берләрен белми яшәүләренә исләре китәр иде Алар бер-берләре белән аңлашып, шундый ягымлы, шундый сагынып гөрләшерләр, шатланырлар иде Урал тауларының мәрмәрләре дә мамык кебек йомшап калыр. Идел елгасы, агудан туктап, гаҗиз булып тыңлап торыр иде. Алар башка халыкларга да ягымлырак булырлар, дуслык хисен тагын да олылый төшәрләр иде

Илдән аерылып еракларда моңсыз яшәүләренә бик каты егълап үкенерләр иде Әй Олы Мәйдан-нар сыйдырыгыз милләттәшләремне бер генә мизгелгә көй корабына! Алар йөрәген, бер генә тапкыр булса да, бәхет шатлык яңгырлары сафландырып үтсен

Шунда «Шахта» көенең авыл көе кин күңелле урам көе туган кыр-басуларыңны авылларыңны борынгы тамырларыңны сагыну көе икәнлеге аларның исенә төшәр иде Шунда алар Бөек Иген шаулап үскән кырлар каршында баш иярләр көне-төне анда янып-пешеп эшләүчеләргә сокланып туган җирләрен ташлап китмәгәннәр бездән бәхетлерәк икән диярләр иде

«Шахта» көе! Җый әле безне Олы Сабантуй мәйданына!

Көндәлек матбугатка язылу бара

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ

Өстәлдә ак кәгазь...

Матбугатка язылу вакытлары җитсә, республика газит-журналларыннан районнардагы һөнәрдәшләренә үз басмаларын рекламалаган язмалар яисә тулы-тулы сәхифәләр килә башлый. Хәзер бу хәл елга ике тапкыр була. Элек, газитләр атнага өч-дүрт тапкыр чыккан чакта, районнарда аларны көтеп диярлек алалар иде. Инде мондый язма-битләргә, җитмәсә елга ике тапкыр, урын табу кыенлашты һәм бераз сайлану башланды. Менә шундый сайлау вакытында кайдадыр кемдер әйтеп куя:

— Бу газитне (яки журналны) мактасаң да инде... Бер рәтле мәкалә чыгарганнары юк.

Мондый фикергә каршы берни әйтәсе килми минем. Зәвык турында бәхәсләшәләрмени? Аннары, нәрсәне «рәтле» дип уйлыйсың бит әле. Томана өчен — аң-белемгә чакыру, исерек өчен эчмәскә үгетләү иң рәтсез, кирәксез сүз булып ишетелергә мөмкин. Икенче яктан, «теге» газиттәге журналистларга биредәге каләмдәшләреннән башка тагын кем теләктәшлек итәр, «алар» уңышын хезмәттәшеннән бүтән тагын кем күрер? Шулай уйлана башлыйсың да, ахырдан нәтиҗә ясагандай итәсең: әйе, безнең һөнәрдәшләрдән дә таркаурак, бер-берсен якламый, аралашмый, очрашмый, сөенеч-көенечләрен бүлешми торган тагын кемнәр бар икән? Безнең арада конкуренция дигән нәрсә, аның да ямьсезрәге, базар чорына кадәр үк бар иде инде. «Туган партиябез» журналистлар арасына ызгышчыларны шактый кузгатып торды. Газиткә килеп эшли башлавыма өч дистә елдан артып китте, шул вакыт эчендә республикадагы каләмдәшләр белән уртак бер очрашу, фикер алышу күргәнем юк. Ә аңа кадәр колхозда эшләп, газитләрдә читтән торып кына катнашкан унбер елымда ике тапкыр эшче-авыл хәбәрчеләренең Татарстан съездларында, бер тапкыр авыл хәбәрчеләренең республика конференциясендә булган идем. Кем әйтмешли, ике зур аерма бит монда. 40-45 ел эшләүчеләрнең дә журналистлар дөньясындагы хәле шундый ук. Тәҗрибә алмашулар, бергәләшеп кыйбла ачыклаулар, газитнең теле хакында төпле сөйләшүләр булмагач, һәр журналист үз казанында кайнаудан, үз мөхәрриренең иҗат планкасыннан үтә алмый. «Планка» үзе нинди биеклектә бит тагын! Мин ул яктан шактый бәхетле анысы: яшь чакта язмыш мине Вәгыйз Вәлиев, Суфия Әхмәтова, Шакир Гафаров, Мәгъсүм Хуҗин кебек чын остаз-журналистләр, таләпчән каләм ияләре белән очраштырды.

Элек районнарга килгән республика журналистлары җирле редакцияләргә сугылмыйча, анда шау-гөр килеп бер сөйләшеп алмыйча калмыйлар иде, хәзер аларның мәкаләләрен укыгач кына, районнан чаптырып узуларын беләбез. Андыйларның район тормышы турында хаким кабинеты яисә автомобиле тәрәзәсеннән генә күреп язган мәкаләләре кайвакыт чынбарлыкка туры килеп тә бетми. Бервакыт Казанның мактаулы бер журналисты Арчадан үтә һавалы һәм гел берьяклы мәкаләләр язып, ул райондагы һөнәрдәшләрен шулкадәр тинтерәтте, аны күрәлмас, язмаларын укый алмас хәлгә килделәр.

Күптән түгел республика матбугатында үзебезнең районнан бер күмәк хуҗалык рәисе турында җылы гына әйбер басылып чыкты. Икенче көнне шул хуҗалыкта булдым — риза түгел рәис.

— Әле редакцияләренә шалтыратып, авторын эзләгән идем дә, тапмадым. Мактыйм дип, арттырыбрак җибәргән бит ул, колхозчылар алдында уңайсыз хәлгә калдырган, болай итеп бүтән газиткә дә чыгара күрмәсен тагын, — ди.

Ләкин монысы әйбәт очрак әле: рәис зур газиттә артык бизәлгән сурәтеннән уңайсызлана белә. Әмма арада журналистны читтән махсус чакырып мактатырга омтылучылар да бар. Ә тегеләр йөгерә-йөгерә килә, «тукта әле, һәр районның үз журналистлары да бар ич, бу әфәндедән шөп эшләрен алар ник язмый икән? Бер-бер сәбәбе юкмы моның, баргач, андагылар белән киңәшергә кирәк, фикерләрдә капма-каршылык чыкмавы хәерле», — дип уйлап та карамый.

Капма-каршылык дигәннән, үткән ел микән, Русиянең ул чактагы эчке эшләр министры Виктор Ерин «Аргументы и факты» атналык газитә хәбәрчесе белән әңгәмәсендә безнең һөнәрдәшләр өчен кызыклы бер фикер әйтте. «Америкада бүтәннәр кагылырга батырчылык итми торган ике төрле «изге сыер» бар — полисменнар һәм журналистлар», — диде ул. Менә ни өчен безнең «кайнар нокта»ларда чит ил хәбәрчеләре күп һәлак була. Чөнки алар Русия журналистларының бөтенләй үзгә шартларда, бүтән җәмгыятьтә эшләүләрен, яклаучысыз булуларын абайлап җиткермиләр.

Ә экс-министр сүзләренең мәгънәсе болай: Америкада полисменнар да, журналистлар да кемнәндер җәбер күргән, мыскыллы сүз ишеткән коллегаларын шундый итеп бердәм яклыйлар, җәбер күрсәтүче моны гомере буена онытмый. Ә без, алай яклашмау гына түгел, зәһәр чәнечкеле сүзне бер-беребезгә әйтүдән ләззәт табабыз. Мисаллармы? Кемнекен искә төшерим? Ә бит үз-үзен дә яклый белгән бердәм журналист коллективы гына халыкны, үз укучысын гаделсезлекләрдән араларга мөмкин. Ә халыкны яклый алу газитнең укучысын табу, әйбәт тираж, матди яктан азмы-күпме ирекләрәк булу һәм үз сүзеңне тагын да кыюрак әйтергә мөмкинлек алу, дигән сүз. Болар бер-берсенә нык бәйле. Менә шуңа күрә матбугатның, журналистлар коллективының бербөтенлеге, бердәм булуы рәсми хакимияткә әллә ни кирәкми. Болар хәтта безнең Журналистлар берлеге өчен дә әһәмиятле саналмады, моңа кадәр аның эше дә хөкүмәт структурасының бер вазифасын үтәүдән узмады. Ихтимал, баштан ук ул шул максат өчен төзелгәндер дә. Шуңа күрә каләмдәшләрнең туплану — өйрәнүендә, үзара ярдәмләшүендә Журналистлар берлеге әлегәчә иҗат штабы да, теләктәш тә була алмады. Берлекнең үз басмасы да булмады, ул хәтта берәр газит-журналның оештыручылар составына да кермәде. Инде шулай икән, мин үзебезнең каләмдәш-фикердәшләрнең республикадагы бер басма, әйтик, андагылар тарсынмаса, «Мәдәни җомга» тирәсенә тупланып эшләүләрен, кирәксә, шуның аша үз сүзләрен әйтүләрен теләр идем. Акыллы басма булырга охшап тора ул. Таралуы гына ничек булыр, аның мәдәниятле булырга ча... кыруларын милләттәшләр ничек ка... бул итәр?

Республикада зур формат белә... чыга торган татарча һәм урысча газитләрнең гомуми тиражларын чагышты... рып карыйм да, тел аптырыйм ми... Халыкның милли бүленеше тигез д... ярлек, ә газитләр бер татарчага ике урысча туры килә, җитмәсә, безне... телдәгесе гел кими бара. Чөнки, әйт... кәнемчә, бер-беребезнең уңышын к... рә һәм күрсәтә белмибез, киресенч... үзара «тешләшеп» торабыз. Гаять үзе... нчәлекле булган «Татарстан хәбәрлә... ре»н шулай тирги-тирги чыгудан да т... ктаттык, бер-ике һөнәрдәшебез хәтт... шуннан соң да аңа таш ыргытып ка... ды. Ә файда нинди? Татар тормыш... хәбәрләрен аның кебек итеп хәзе... кем яктырта? Аз гына гомерендә бе... нең кечкенә Балтач районыннан гына да бер йөз иллеләп хәбәр чыккан иде анда. Инде менә «Мәдәни җомга» исемле бик мәгънәле, бик матур атналык басманың ун саны дөнья күрде, т... аның турында җитди уңай сүз язып чыккан бер газит тә юк әле. Әйе, аларның тиражда конкурент булуын теләмибездер. Татар журналистлары шулай бер-берсенең хезмәт җимеше турында җылы сүз әйтүдән шикләнеп йөргән арада, милләттәшләребез «Вечерняя Казань»га язылып та куя. Ә без һаман сабак алмыйбыз. Язылучы аз, тиражы кечкенә, дип бер газитне ябып куюдан бүтәннәрнең сулышы иркенәйми, матбугат һәм журналистлар тулаем зыян гына күрә. Үз-үзебезне саклау инстинкты да юкмыни соң бе... дә?

...Радиодан Ренат Харис шигырена язылган «Өстәлдә ак кәгазь» исемле җыр тапшыралар. Рәмзия Зиннәтуллина җырлый.

Үзгә тавыш, серле сүзләр:
Тәрәздә алсу таң,
Өстәлдә ак кәгазь,
Каләмем яз төсле карада...

Бүген күп журналистлар алдында да ак кәгазь. Ә язу карасының төрлесе бар. Коньяк төнедәй карасы, таң төсле алсуы, Ислам әмәледәй яшеле, кандай кызылы. Каләмен кайсына манып, нәрсә язар — анысы укучының ихтыяҗына, аңлавына, кирәксә, яклавына бәйле булыр.

Ә укучы булыр микән әле? Бәлки инде язарга кирәк тә түгелдер...

Балтач

Дөньяны әхлак тота

Бала... чагарга да мөмкин

Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм Госманов «Татарга интеллектуаль кризис янамыймы?» дигән сораута: «Янау гына түгел, хәзер инде аның эченә үк кереп утырдык. Ул күп өлкәдә шул исәптән мәктәп-мәгариф тормышында да чагыла», — дигән иде.

Кайбычта булып узган укытучылар конференциясендә дә шушы сорауга җавап эзләдем. Кайбыч районы әле яңа оешкан, быел ул бишенче уку елын башлап җибәрде. Райондагы 42 мәктәптә (16 урта, 2 сигезьеллык һәм 24 башлангыч) барлыгы 2610 укучы белем ала, аларда 375 мөгаллим һәм тәрбияче эшли. Узган уку елында татар балаларының 93 проценты туган телләрендә белем алган. Ата-аналар теләге белән исәпләшәләр икән биредә. Әйтик, беренче сыйныфка килүче берданбер укучының әти-әнисе балаларын чуваш телендә укытырга теләк белдергән һәм Урсак мәктәбендә чуваш сыйныфы ачканнар. Мондый очракта башка төбәкләрдә дә, бигрәк тә шәһәрләрдә ата-аналар теләге һәрвакыт искә алынсын иде, диярге генә кала.

Конференциядә район мәгариф бүлеге мөдире Илдар Шакиров фронталь тикшерү нәтиҗәләренә дә киң тукталды. Саннар бу юлы куанычлы түгел: контроль биремнәр буенча өлгереш 76 процент тәшкил итә. 600 дән артык бала ул биремнәрне эшли алмаган. Тугыз мәктәптә чит телләр, белгечләр булмау сәбәпле, укытылмаган, быел да шундый ук хәл. «Хәзер безнең бурыч — үз белгечләребезне укытып кайтару», — диде Илдар әфәнде.

Укучыларның күчмичә класста утырып калуына инде күнегеп киләбез. Кайбычта аларның саны — 1,1 процент. Процентлар нисбәтендә бу, бәлки, күп тә түгелдер, әмма ул бит 31 бала һәм аларның әти-әнисе фаҗигасе. Шуны да әйтергә кирәк, узган ел күчмәүчеләрнең саны 21 булган.

Республика олимпиадаларында кайбычлылар нинди урыннар яулый? Балаларның интеллектын ачык күрсәтүче бу саннар да артык куанычлы түгел. Хакимият башлыгы Азат Хәнифәтуллин әлеге мәсьәлә турында аеруча борчылып сөйләде. 1993 елда укучылар чит телләр, татар һәм урыс теле буенча республикада призлы урыннар яуласа, узган уку елында урыс теленнән — 50, физика, химиядән — 39, татар теленнән — 35, географиядән — 33, математикадан 31, биологиядән 28 нче урыннарга тәгәрәгәннәр. Бер ел эчендә район буенча урыс теленнән өлгереш — 11, белем сыйфаты — 6, математикадан 34 һәм 15 процентка кимегән.

Балаларның интеллектуаль үсеше кимүе хакында тагын бер мисал ачык сөйли: Татарстан Мәгариф министрлыгы инспекторы Әнзия Чайка әйтүенчә, уку елын 630 укучы алтын һәм 1058е көмеш медальгә тәмамлаган, бу һәр районга якынча 10 алтын, 17 ләп көмеш медаль туры килә дигән сүз. (Исегезгә төшерәбез: Кайбычта 1 алтын, 12 көмеш медаль).

Балаларның сәламәтлеге дә бер Кайбычта гына түгел, республика күләмендә начарлана бара. Бәяләр арту ата-аналар кесәсенә сукты. Хәзер баланы мәктәпкә әзерләп җибәрү өчен кимендә 350—400 мең сум акча кирәк. Бу әле көндәлек кирәк-яракларны исәпкә алмаганда. Бер дәфтәрнең бәясе 600 сум тора. Калын дәфтәрнең бәясе 3500, көндәлек 1000—1500 сум чамасы. Кесә электрон-хисаплау машинасы кимендә 15—20 мең, готовальнялар 20—25 мең сум тора. «Просвещение» (Мәскәү) һәм «Мәгариф» китап нәшриятлары вакытында дәреслекләр әзерләп өлгертә алмый, басылган дәреслекләрнең күбесе төрле юллар белән базарга «шыла», ә анд... бәяләр — ирекле.

Балаларны кайнар ризык белән тәэмин итү аеру... ча мөһим. Башка авылдан килгән бала көн буе... авызына кайнар ризык капмаса, аңарда дәрес ка... гысы булмый.

Авылларда җәелгән коточкыч афәт — эчүчелек... югары даирәләр дә күрмәмешкә салышалар, күз й... малар. Итәгенә ут капканнар гына яна-коя, ә бит б... фаҗиганең эчендә балалар, яклаучысыз балал... һәм чарасыз аналар интегә. Авыру, зәгыйфь, йом... кый балаларның күбесе шундый гаиләләрдән.

Алда санап үткән сәбәпләр, аяныч ки, Кайбыч районына да хас. Район милиция бүлеге җитәкчес... Марат Нәҗиев үзенең чыгышында авылларда бал... лар җинаяте арту хакында сөйләде. 1992 елда б... лигъ булмаган, тәрбиягә авыр бирелүче балалар н... бары 10—15 булса, бу сан 31, 38 һәм быел 49 г... җиткән. Җинаятьчелек яшәрә бара, иң яшь хоку... бозучыга нибары тугыз яшь. Милиция начальнигы... фикеренчә, 49 баланың 25енә суд эше кузгатырга мөмкин.

Кыскасы, интеллектуаль кризис мәктәпләрдән б... шлана, ул баланың яшәеш шартларына, конкуре... нә, әти-әнисе эшләп тапкан акчага, укытучыларны... кәефенә, хәтта алар асраган сыер-сарыкларның п... чәнә барлыгына-юклыгына, әтиләренең бүген ... аек кайту-кайтмавына да бәйле. Бәлкейләрнең ... ни проблемасы да хөкүмәт хәл итәргә тиешле җит... мәсьәләгә әйләнсен иде.

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА,
махсус хәбәрчебез

Кабатлана тарих

Поэма

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

1.

Селтәп алып утка чөярләрме?
«Шашкан!» диярләрме тагын да?
Дус-дошманнар белән учак ягып,
Таң каршылыйм язмыш ярында.
Колак салам азан моңнарының
Ярдан-ярга тараласына.
Бәргәләнә хәтер канатларым
Сөембикә манарасына.
Гәүдәләнә ялкын телләрендә
Ханбикәнең гүзәл буй-сыны;
Төсле сурәтләргә төшереп ал да
Һәт түшеңә кадап куй шуны!
Табын шунда алтын сабырлыкка,
Тугрылыкка, рухи чыдамга.
Рух та, нур да кача җир йөзеннән
Милләт күзен йокы буганда.
Милли хиснең, телнең таркалуы
Кан саудыра аңга-зиһенгә...
Аяк өсте уйлап төн уздырган
Еллар онытылмый
исемдә!
Гореф-гадәт истә
йокы — зәхмәт!
Йокычыга нурын ачмас таң!!!
... Йокысы да, зәхмәте дә йокты
Безгә килмешәктән, басмачтан.
Көн-төн эшләп санга сугылмады
«Атналык» та, безнең «айлык» та
Бу дөньяны берәү саташтыра,
Берәү таң балкытып айныта.
Әүвәл көндә таңга юл ачучы
Берәүләрнең бере — мин дә бит!
Мин кычкырам
— Сөю манарасын
Күтәрегез минем иңгә! — дип. —
Өметсезме денсез, юньсезме мин
Кешедән ким минем кай ягым?..
Сөюем күк коплык, ятимлектә
Шигырьләрем — алтын айларым!
Газиз балаларым — күз нурлары
Адаштырдым сөрген юлында!..
Нинди генә кайгы, ут-сагыш юк
Эчтә дөрләп торган бу моңда?
Шагыйрь булып шушы моң дәрьясын,
Ут дәрьясын гизми кара син, —
Өммәтеңне әҗәлләргә илткән
Хыянәтнең эзләп чарасын...
Чарасыздан моңым чамасыздан
Берөзлексез язам ярсынам
Кыз-баламның сагыну-сагышында
Сөембикә аһы бар сыман!
Алсу таңнар сызылып атар сыман
Бөек хан заманын кабатлап...
Бу бөеклек бүген кемгә хаҗәт? —
Газиз чорым, шуңа җавап тап!
Уян! Уйлан, халкым, яңабаштан
Узган тарихыңа кара да
Үксү, сыкрау белән аралашып
канлы гашкын тупа арага!
Иделемә тарих чоңгылыннан
Күпер булып калка мәетләр...
«Гасыр кичү»ендә төпкә батса,
«Канлы канун» кемне гаепләр?
Кем аралар безне кан коештан
Йоклап ятсак янә таң аллый?..
Гаепсезгә гаепләрен яга,
Тик чор үз-үзеннән таналмый.
Юк, юк... Милләтпәрвәр фидаилар
Яза алмый бүген акылдан...
Иң зур хыянәтнең тәүге тубы
Татар Ватанына атылган.
Үзен-үзе сөргеннәргә сөреп,
Диванага татар сабышкан.
Ничә гасыр аша шушы хакта
Илгә хәбәр сала таныш таң!

Шул хәбәрдән дөнья яна, дөрли...
Мин дә бергә шунда..
Кан косам;
Ах, ни булыр иде, өмет таңым,
Чәчәк исе булып аңкысаң?!.

2.

... Учагыма супар сибәрләрме?
Гайбәт сөйләрләрме буш җаннар?
Юк, су гүгел, безнең кан дошманнар
Һәр җисемгә агу кушканнар.
Шушы кушымтыкны күпертканнәр,
өсти горып көндә чүперә.
Аңгыра дус, дошман сүзе белән
Кипәчәген җирнең үтерә.
Үлем ачысында этә-төртә,
йөртә тәкъдир сөем җилкәнен.
Илгә көн бирмәгән җилләр өркә
Язмышыннан Сөембикәнең.
Киләчәктә без дә көн күрмәбез
Бер өметсез өркәк җилләрдән...
... Иделдәге учак җыры белән
Таң чаршавын ачып җибәрәм.
Ялкыннан наз гукып, утлар йотып,
Тарих чоңгылларын актарам...
Шушы кадәр авыр күрәчәкне
Безгә язмыш юкка такмаган!
Юкка тарих утка ашырмаган
Көчле рухын ата-бабаның.
Уттан-утка салган елларымның
Минутына кадәр санадым.
Шул саннарны аңга урауччылар.

Юлаучылар бәлки күрерләр:
Кылыч чапкан атлы гаскәр сыман,
Таңда ауды безнең гомерләр.
Кара эчле куштан тарафыннан
Өстебезгә яуды йөз әләк...
Ходай өчен калды микән җанда
Әрнешмәгән берәр күзәнәк?!
Калды микән бала-чагага бер
Бирми калган үгет-нәсихәт?..
Сихәтлектән иртә язгангамы —
Берни күтәралмый яшь исәп.
Мәхәббәткә килеп ялганалмый
Җан тамыры таркау нәселнең.
И күрәчәк!
Затлы нәселемнең
Бәхет очын кая яшердең?
Яшьлек белән бергә бәхетебез
Биклэндеме шахта базында?
Таш күмерләр, таулар ишелүе
Еш ишетелә моңлы сазымда.
Моң-сагышым белән тирәнәйтеп
Гасырларның маңгай сырларын,
Мин шул үзәк өзгеч шахта көен
Җырладым да һәр көн еладым.
Ә гасырлар минем күңелемә
Салды Сөембикә сафлыгын...
Шушы сафлык аша күзлим таңда
Казан каласының таш юлын.

3.

«Юлга чыкма!!!» диеп сүгәрләрме?
Тибәрләрме тагын эчемә?
Мода ич ул бездә эт типкесен
Чәпәп йөртү шагыйрь кешегә.
Әрнеш-сагыш, гөнаһ, аһ-үкенеч
Безнең илдә — артык зур санда!
Күкрәгемнән чор ялкынын ургый
Ялгышып бер тамак кырсам да.
Ирек бирми гадел сүз әйтергә,
Бугазларны кыса якалар.
Күзгә күренеп торган гаделлеккә
Хәзер һәр почмактан аталар.
Һәрбер юлны кара мәгә кисә,
Үч давылы ишә ярларны.
Таң шәүләсен күреп сөенүгә
Чиксезлеккә иңә караңгы.
Кабатлана тарих,
канатлана
Җирне кара канда өстерәп.
Сугыш чукмарлары уяу, ишле,
Дошман безгә карый көчлерәк.
Икеләтә көчле үлем белән,
Дәһшәт белән янау... ал таңга!..
... Бер ярдашым сөйли: татарның, — дип,
— Баһадирлык сере — сакалда...
Ә мин исә шигъри сергә төреп
Аналарның йөрәк ялкынын,
Үз гомеремдә Ватан иңнәренә
Сузып салдым ничә чал толым.
Шуңа күрә миндәй шагыйрьләрнең
Күз яшенә кадәр чал баскан...
Чаларуның әҗере тияр иде —
Җан дусларга телен аңлатсаң.
Дошманда да туар иде, бәлки,
Бераз рәхим-шәфкать, миһербан..
Милләт телле чакта
шигъри сүзне
Мин һичкайчан җилгә очырмам
Гамьсез, ямьсез «йокы чүлмәге»нә
Әверелмәм газиз Ватанның.
Таныр тарих чал гасырлар буе
Кара сакал йөрткән татарын!
Шагыйрьләрен таныр Татарстан —
Шигъри учакларга күз салыр..
Хак сүз белән күзгә-күз килгәндә,
Җир күтәрә безне...
Җир сабыр...

ШАГЫЙРЬ НЕЧКӘЛЕК БИЛГЕСЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛА

КАЗАН СӘНГАТЬ УЧИЛИЩЕСЫНА 100 ЕЛ

Мөхмүт ВАҺАПОВ:

«Бездә авыл балалары аз укый әле»

Исеме доньяга билгеле мәшһүр Николай Фешин, Үзбәкстанда үз мәктәбен булдырган Павел Бельков, бөек рәссамыбыз Бакый Урманче, Русия сәнгать академиясенең өгъза-мөхбире Харис Якупов, Русиянең халык рәссамнары Лотфулла Фәттахов, Виктор Куделькин, Татарстанның халык рәссамы Виктор Федоров, рәссамнар Илдар Зарипов, Рәшит Имашев, Фәрит Якупов, Надир Усманов, Абрек Абзгильдин, Шамил Нигъмәтуллин һәм башка бик күп рәссамнар училищеның горурлыгы. Аларның әсәрләрен Петербургтагы урыс музеенда, Мәскәүдә Третьяков галереясында да, күп кенә чит илләрнең картиналар галереяларында да күрергә була.

Казан сәнгать училищесы кебек югары дәрәҗәле шундый уку йортлары Русиядә нибары 3-4 кенә. Ә Идел буе, Урал төбәкләре өчен Казан сәнгать училищесы — бердәнбер.

1895 елда сәнгать мәктәбе буларак ачылган бу уку йорты өчен 1903 елда махсус бина төзелә, Казандагы бу иң матур биналарның берсендә — Карл Маркс урамы, 70 нче йортта — хәзер технология университеты урнашкан. Ул чагында сәнгать мәктәбендә сынлы сәнгать, архитектура, гравюра һ.б. факультетлар булган. Гасыр башындагы зилзилә сәнгать мәктәбенең эшчәнлеген дә үзгәртә, төзәтмәләр кертә, заманга яраклаштыра.

Училище бүген нинди хыяллар белән яши соң? Бу турыда аның директоры Мөхмүт ВАҺАПОВ болай диде:

— Иң элек укучылар турында әйтер идем Безгә алар зур конкурс аша узып, кыл иләктән иләнеп килеп керәләр Хәзер училищеда 100 гә якын укучы белем ала, аларның бер өлеше 9 нчы сыйныфны тәмамлап, бер өлеше 11 нче сыйныфтан соң килгән балалар. Алар өчен ике бүлек эшли — сынлы сәнгать буенча педагоглар һәм дизайнерлар әзерләү бүлекләре. Ә инде театр рәссамнары бүлегенә 4-5 елга бер тапкыр гына укучылар кабул итәбез Укытучыларыбыз барысы да диярлек югары белемле, аларның күбесе безнең училищены тәмамлаган, димәк, сынлы сәнгать укытучылары булыр өчен махсус 14-15 ел укыган югары әзерлекле белгечләр. Татьяна Юдина. Виктор Федоров, Александр Иванцев, Геннадий Макаров, Соломон Гельман, Анатолий Сысоев, Михаил Салмин, Флера Әхмәтова-Урманче кебек тәҗрибәле өлкән буын укытучылары белән беррәттән, Айрат Хәмидуллин, Наилә Кумысникова, Тәлгать Солтанов, Әлфия Җәмилева кебек яшьләр дә укыта бездә.

— Мөхмүт әфәнде, ул чагында бик урынлы сорау туа: ни өчен бездә рәссамнар, скульпторлар әзерли торган сәнгать институты юк? Күршедәге чуваш, мордва, мари, удмурт халыклары өчен дә аның әһәмияте әйтеп бетергесез зур булыр иде бит.

— Без бу турыда уйланабыз һәм киләчәктә, бәлки, чакыру билетларына, әйтик, Бакый Урманче исемендәге Казан сәнгать институты, дип язылыр. Моның өчен материаль-техник база кирәк, урын аз — үзебезнең бинабызны кайтару турында да уйланабыз, студентларга тулай торак кирәк Хәзер читтән килгән 21 баланың 2-3 е генә тулай торакта яши Театр, хореография, сәнгать һәм музыка училищелары өчен нибары бер тулай торак бар. Казанда быел татар милли сәнгать мәктәбе ачылды һәм анда югары белемле укытучылар кирәк.

— Белгечләр дигәннән, мәктәпләрдә җыр һәм рәсем укытучысына әле дә кытлык зур. Сез, әлбәттә, бу ихтыяҗны канәгатьләндерә алмыйсыз...

— Дөрес әйтәсез. Авыл балаларының күбесе конкурстан уза алмый, чөнки анда сәнгать мәктәпләре юк. Шуның өчен киләчәктә безгә 1-2 еллык әзерлек курслары ачарга кирәк. Бу турыда район хакимиятләре белән сөйләшү бара, һәм бер районның да моңа каршы килгәне юк Чөнки киләчәктә ул белгечләр үзләренә кайтачак бит.

— Сәнгать мәктәбендә заманында бүлекләр түгел, факультетлар булган һәм аларның саны да күбрәк исәпләнгән. Бу хакта ни әйтерсез?

— Ният бар. Әйтик, күн мозаикасы, ювелир сәнгате, туку, чигү, мәчетләр бизәү — без боларны, һичшиксез, булдырырбыз дип уйлыйм. Милли колорит һәм милли графиканы яшьләр бөтенләй белми, аларны көнбатыш мәдәнияте кызыксындыра.Татарстанда яшәүче күпмилләтле халыкларның традицияләрен яңадан кайтарырга кирәк, аларның үз рәссамнары, үз белгечләре булырга тиеш.

— Сәнгать училищесының бүгенге бинасы, сүз дә юк, кысан. Рәссамнар — иҗат кешеләре, студентларга нәни генә булса да остаханәләр, иҗат мохите кирәк. Аннары читтән килгән яшьләргә яшәү көннән-көн кыенлаша бара. Укытучылар коллективы киләчәктә студентларга елына ике тапкыр вернисаж оештыру турында да уйлана. Аларга олы бәйрәмнәрендә зур уңышлар телик.

Әңгәмәне **Рәсимә ХАЛИКОВА** оештырды.

- И.Фазылов. «Каз өмесе».
- Укытучылар коллективы.

ГАЗЕТА ҺӘМ УКУЧЫ

Әлегә Әпсәләмовлар, Такташлар бирә алмыйбыз

Хөрмәтле мөхәррир Зиннур әфәнде һәм «Мәдәни җомга»лылар!

Гәзитегезне кулга алгач, бик гаҗәп булып китте. мин бит «Татарстан хәбәрләре»нә язылган идем, ә кулга «Мәдәни җомга» килеп керде Башта бу бит әдәбият-сәнгать гәзите. миңа нигә кирәге бар аның, дип уйладым Ә кулыма алгач, туктый алмадым, бер тында укып чыктым Сәнгать әһелләре өчен генә түгел икән гәзитегез, безгә дә ярый икән! Рәхмәт сезгә.

Яңа гәзит нинди тәэсир калдырды соң?

Беренчедән, гәзитегез очсыз, бу яктан бик тә отышлы

Татарстаннан читтә яшәүчеләр Казан хәбәрләрен ишетергә тилмереп яшиләр бит. гәзитләр безгә килеп җиткәнче бермә-бер кыйбатлана.

Икенчедән, басмагыз тирән эчтәлекле язмаларга бай, темалар төрле-төрле.

Өченчедән, гәзитегез йөгерек тел белән язылган, су эчкәндәй җиңел укыла.

Язучылар, шагыйрьләр, сәнгать әһелләре турында шактый мәгълүмат бирәсез. Минемчә, гәзитегезне укытучылар, тәрбиячеләр дә яратып укыр, чөнки тарих, татар әдәбияты буенча өстәмә материал булырдай язмалар, тәрбия сәгатьләре өчен рухи азык шактый.

Беренче санда Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов белән әңгәмә урнаштырылган. Аның төп фикере — яңа Әпсәләмовларны эзләп, яңа Такташларны әдәбият түренә утырту теләге Килешәм, бу бик мөһим нәрсә Әмма төрле төбәкләрдә яшәүче татарлар язмышы да гәзитнең күз уңында торырга тиеш Без бит туган телебезне дә онытып барабыз, җәмәгать! Болай булса, яңа Әпсәләмовлар, яңа Такташлар каян гына үсеп чыгар соң?

Менә без — Чайковский шәһәрендә яшәүчеләр, балаларыбыз туган телләрен, гореф-гадәтләрен онытмасын дип җан атып яшибез.

Сез, нәрсәләр эшлисез, язып җибәрегез, дип әйтергә хаклысыз Мактанырлык булмаса да, башкарган эшләребез күп. Татар-башкорт иҗтимагый үзәге 1989 елдан бирле эшләп килә Дини оешмабыз эшли, Ураза, Корбан бәйрәмнәрендә намазлар укыла, указлы муллабыз бар. Күп еллардан бирле «Дуслык» ансамбле эшләп килә, атна саен концертлар куеп, милләттәшләребезне куандырабыз. Фольклор ансамбле, аның каршында шигърият түгәрәге эшләп килә. Җәй саен Сабан туйлары уздырабыз. Мәчет төзергә ниятлибез, нигез ташлары салынды инде. Шунысы куандыра: Чайковский шәһәре хакимияте татар-башкорт иҗтимагый үзәгенә һәртөрле булышлык күрсәтә. Бүгенге максатыбыз — татар балаларын татарча укыту Бу эшебезне дә хакимият хуплап каршы алды, 13 урта мәктәпнең 7сендә факультатив рәвештә татар теле дәресләре укытыла башлады Элек ата-аналар һич кенә дә риза түгел иде, хәзер үзләре сорап киләләр. Быел 70ләп бала факультатив дәресләрне уңышлы тәмамлады. Тик укытучылар, методик әсбаплар, дәреслекләр җитми Без Татарстаннан шушы мәсьәләләрдә ярдәм көтәбез, туганнар Бүгенүк коеп куйган Әпсәләмовлар, Такташлар бирә алмыйбыз, бигайбә Татар телебезне аякка бастыра алсак, алар сезгә үзләре йөгереп килер.

Шул уңайдан минем теләк — гәзитегезнең бер бите (сан саен димим) төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең мәдәни тормышын, андагы мәшһүр татарларны яктыртып барсын иде.

Ихтирам белән, Көнбатыш Уралдагы укучыгыз

Фәнәис ЗАҺИТОВ.

Язучы Мәгъсүм Насыйбуллинга 70 яшь

Караңгы юлларны яктырта

Нәкъ менә без татар баласының өлешенә туры килә торган кара язмыш микән инде бу — Казан университетын тәмамлагач, мине дә Ерак Көнчыгышка сөрделәр. Әмма шунысы бик гаҗәп иде миннән яшьрәк һәм әле гаиләсе дә булмаган менә диган егетләр Казанда калды, ә мине — гаиләсе һәм алты айлык яшь баласы булган, минус тугызлы калын күзлек киеп йөргән кешене — тоттылар да офицер итеп алып киттеләр Дусларымның. «Университетта яшь татар журналистларыннан «Яңа-ваз» берләшмәсе оештырып, анда укытучыларга баш бирмичә әллә нинди үткен-үткен бәхәсләр үткәреп йөргәнең өчен бу синә» — дигән сүзенә ирексездән ышанырлык иде шул!

Ярый, Тын океан яры буендагы сопка араларында офицер шинеле киеп йөреп, ике ел гомер кәч-хәл белән үтеп тә китте Сагынып, җирсеп, атлыгып Казаныма кайттым Ә анда кайтсам... Казан шәһәренең паспортлар бүлегендә утыручы бер зур гына түрә миңа:

— Ерак Көнчыгышны калдырып ни өчен нәкъ менә безнең Казан шәһәренә кайтырга булдыгыз әле сез? — димәсенме!

Мин — офицер киемендә йөрсәм дә, җаным белән гел Казанга атлыгып яшәгән яшь татар журналисты — бу сүзләрне ишеткәч, ачудан нишләргә дә белмичә, бер мәлгә тораташ кебек катып калдым. Шушында укып, шушыннан сөрелгән яшь татар журналистына әлеге бик сәер сүзләрне әйтсеннәр әле!

Хәзер инде бераз аңлыйм: рәсми яктан карагандa, әлеге түрәнең миңа бәйләнер урыны да булган икән. Безнең Казанга кемнәр генә һәм каян гына килми бит! Җитмәсә әле мине үзенең кысан фатирына сыендырырга теләгән журналист Габделбәр Ризвановның да торак мәйданы 11 генә кв. метр...

Казан каласы үзенә кабул итәргә теләмәгән менә шушындый бик тә кыен чакта миңа юрист язучыбыз Мәгъсүм ага Насыйбуллин ярдәм итте. Тора-бара әдәби тәнкыйть өлкәсенә кереп китеп, язучылар һәм гомумән зыялылар белән киңрәк аралаша башлагач, мин аның әнә шундый авыр чакларда күп кешеләргә ярдәм иткәнлеген белдем...

Әмма, иҗат турында сөйләшүгә күчкәнче, үземә дә катнашырга туры килгән тагын бер очрак турында әйтми китә алмыйм. Бер мәлне район җирендә яшәүче язучыбызны хәләл көчә белән үзе салып кергән йортыннан колак кактырырга теләүләре мәгълүм булды. Моның өчен җаен да, хәйләсен дә тапканнар, әлбәттә... Ә безнең язучы үзе моның ише пычрак эшләргә катнашырга телми һәм аның рәтен дә белми бит инде ул! Кыскасы, чын иҗат кешесе ул еш кына чынбарлыкның мондый мәсьәләләре каршында бик тә мескен хәлдә кала. Әлеге язучыбыз да шундый хәлдә иде.

Бу хакта без Мәгъсүм ага белән киңәшергә булдык Ә ул исә эшнең әлеге язучы өчен үтә дә җитди икәнлеген шундук аңлап алды һәм безнең әдибебезне яклау эшенә иң югары оешмаларны тиз арада җәлеп тә итте. Вакытын да, нервларын да һич кызганып тормады!

Әйе, безнең арабызда әнә шундый ярдәмчел булган Мәгъсүм ага Насыйбуллин исемле юрист язучы бар.

Аның күпсанлы китаплары татар укучысына үтә дә яхшы таныш. Мәгъсүм аганың китаплары ел саен үткәрелә торган бәйгеләрдә иң күп укыла торган булып чыга Шуңа күрә китапханәләрдән аның китапларын таба алмыйсың, яисә инде алар кулдан-кулга йөри-йөри тузып, таушалып беткән була. Язучы кешә өчен гаять тә шатлыклы күренеш!

Мәгъсүм ага Насыйбуллин иҗатының төп хикмәте нәрсәдә соң?

Дөрес, анысы бар детектив әдәбият байтак кына халыкларда шулай ук күп укыла, яратып укыла. Бирeдә кеше психологиясенең үзенчәлеге дә үз сүзен әйтми калмый торгандыр инде, әлбәттә

Әмма, шулай да, бу язучы әсәрләрен укыган вакытта күңелне җәлеп иткән башка уңай сыйфатлар да байтак күзгә ташлана

Менә минем кулымда Татарстан китап нәшрияты 1985 елда бастырып чыгарган «Алтын алка» дигән җыентык Аңа язучының «Телсез шаһитлар» «Яшерен касса» «Капкын» һәм «Алтын алка» дип исемләнгән дүрт хикәяте кергән Сүз уңаенда гына булса да шунысын искәртеп үтик, әлеге китапның тиражы 50000 данә дип куелган Бу инде — безнең бик күп язучыларыбыз хыялланa торган зур тираж иде ул елларда!

Җыентыкка исем биргән хикәятне ачып, таныш әсәр битләре буйлап янадан сәяхәт итәм һәм шунысы сөенечле: кабат кайтып укыган чагында да бирeдә мажара эзләп кенә бармыйсың, үз алдыңда әдәби әсәр икәнлегенә тагын бер мәртәбә төшенәсең. Әсәрдәге күп образлар, күренешләр сине әнә шуңа ышандыра.

«Алтын алка»ның беренче бүлеге «Казан» ресторанын, аның да бер затлы залын сурәтләүдән башлана. Бер өстәл артында дүрт егет утыра, алларында мул ризык, аракы тулы графин һәм нечкә билле рюмкалар. Әмма болар эчеп исерергә бик ашыкмыйлар — талау операциясенең чираттагысына әзерләнеп, киңәшеп, план корып утыралар. Бер-берсенә исемләп эндәшү дә юк — бары тик кушаматлар гына.

Ә инде бу әсәрнең икенче бүлегендә тикшерүче Искәндәр Бәхтияров белән танышабыз. Күрү белән аның менә мондый сыйфатларына игътибар итәбез «Бу юаш булып күренгән, һәрвакыт ияк-яңаклары чиста итеп кырылган пөхтә киенгән кеше бала чактагы сыман чирәмгә ятып аунарга әзер » «Кар эреде чаңгы белән йөреп булмый дип өйдә утырмаган, гадәттәгечә ял көннәрендә дачага бару юлын тапкан Кайтырга чыкканда, улының аркасына эленгән биштәре варенье тозлаган помидор, кыяр банкалары белән кабарып тулган иде»

Күрәсезме, игътибар иттегезме берәүләр ресторанда кеше талаугa план корып утыра, икенчеләр табигать кочагында эшли-эшли ял итә Тормышта ике төрле яшәүнең ике төрле нигезе менә шулар түгелме соң инде?! Кичә дә, бүген дә иртәгә дә менә шушы ике төрле туфрак, ике төрле нигез үзләренең җимешләре итеп ике төрле кешеләрне үстереп торачак бит! Язучы М Насыйбуллин каләме сурәтләгән әнә шундый ике төрле нигез безнең өчен тирән мәгънә ала, әсәр башында ук укучы хәтерендә сеңеп кала

Алга таба вакыйгалар куера, шуңа бәйле рәвештә яңа кешеләр күз алдына килеп баса Ләкин шунысы куанычлы әсәрдә артык персонажлар кирәкмәгән каһарманнар юк Кайсыбер китапны укыган чагында кемнең кем булуын да оныта башлыйсың бит — алар шулкадәр күп була!

Мәгъсүм ага Насыйбуллин хикәятләрендә тагын шунысы күзгә ташлана әсәрнең идеясе һәм эчтәлеге туп-туры сызык буенча гына үсеп бармый Повесть нигезен тәшкил иткән бер яисә берничә җинаятькә бәйле рәвештә анда киң тормыш чынбарлыгы ачыла, сурәтләнгән еллардагы реаль күренешләр укучы күз алдына килеп баса Без искә алган повестьтагы төп каһарман Бәхтияровның әтисе дә азылның хөрмәтле кешесе. балта остасы итеп бирелә «Яңа өй саласы булса, иң беренче итеп Гафиятулла Бәхтиярын искә төшерәләр. эшкә чакыралар Авылларны матурлап, әллә каян ук балкып торучы челтәрләп бизәлгән, төрле төсләргә буялган, юан, таза бүрәнәләрдән салынган чардаклы йортларның һәммәсенә диярлек Бәхтиярның да гире тамган »

Менә шушындый нәсел, шушындый уңган атаның баласы итеп бирелә уңай образ Әмма яхшы нәселдән, әйбәт гаиләдән чыккан булу һәрчакта да бәхет нигезе итеп каралмый язучының әсәрләрендә Чөнки тормышыбыз чынбарлыгы шундый, кешеләрнең язмыш юллары шундый «Алтын алка»да да, бүтән әсәрләрдә дә без матур гаиләдә гуып, яши-яши сынган, бирешкән һәм җинаять юлына баскан адәмнәрне да очратабыз. Бу — тормышны дөрес яктырту билгесе

Мәгъсүм ага Насыйбуллин әсәрләрен укып чыккач бик күп нәрсәләргә күзең ачыла. Иң беренче чиратта, әлбәттә, закон сагында торучылар тормышын үзең өчен ачасың, алар белән якыннан танышасың. Аларның авыр һәм җаваплы хезмәтләрен, ул шәхесләрнең фидакарьлекләрен күрәсең. Чын егетлек үрнәкләре белән рухи байыйсың, әхлакый яктан нык төшәсең. 1987 елда басылып чыккан «Син — тикшерүче бит » дигән хикәяләр һәм повесть китабы бу яктан бигрәк тә истә кала. Бирeдәге каһарманнар чын мәгънәсендә җиде кат үлчәп кенә билгеле бер карарга килә торган кешеләр Алар үз күңелләрендә туган шик-шөбһәгә таянып түгел, ә дәлилләр табып, шулар нәтиҗәсендә генә теге яки бу кешенең җинаятьче икәнен распыйлар

Ә шулай да, минемчә, Мәгъсүм ага Насыйбуллин повестьларының зуррак әһәмияте — җинаятьчеләрнең ничек, ни сәбәпле барлыкка килүләрен ачыклау Әсәрләрдә укучыга, халыкка әнә шуны күрсәтеп, аңлатып бирү Бирeдә кешенең кечкенәдән үк иркәләнеп үсүе, эшләмичә генә тәмле ашарга, җиңел яшәргә өйрәнүе кебек сәбәпләр төп урынны алып тора. Повестьларда сурәтләнгән тискәре персонажларның байтагы әнә шундыйлар

Әмма бу язучының әсәрләрен укыганда мин тагын бер нәрсәгә игътибар иттем. җинаять кылучыларның байтак өлешен безнең якта тамыр җибәрмәгән, тегеннән-моннан килгән адәмнәр тәшкил итә

Повестьларда әнә шундыйлар шактый очрый. Бу күренеш шулай ук язучы иҗатының нык лы һәм тирән фәлсәфәгә нигезләнгән булуы, олы хакыйкатькә таянуы турында сөйли Ягъни, «тирән тамыры булмаган агачның кәүсәсе дә биек, мәһабәт була алмый!» — дип әйтә төсле безгә язучы Җилләр, гарасатлар андый агачны бик тиз аударып ташлый!

Мавыгып укылып та, шуның белән онытылса, андый әсәрләр әдәбиятта әллә ни озак яши алмаслар иде. Чын әдәби әсәрләрнең бит аларның тәрбияви яклары да бик көчле була. Эстетик ләззәт бирү, тормышны танып-белергә булышу һәм тәрбияви яктан әһәмият — менә бу өч сыйфат инде күптәннән бирле чын әдәби әсәрләр өчен төп таләп итеп куела килә. Ләкин кызганыч, соңгы елларда бездә эстетик як белән тәрбияви әһәмият еш онытыла. Шушы ике мәсьәләдә безнең әсәрләр соңгы елларда нык кына аксый башлады.

Ә менә Мәгъсүм аганың хикәят һәм хикәяләрендә

(Ахыры 11 нче биттә).



● Татарстанның халык рәссамы Харис Якупов, язучылар Мәгъсүм Насыйбуллин һәм Әхсән Баян.

В.ЗОТОВ фотосы.

ТЕЛЕ БАРНЫҢ ИЛЕ БАР

Мәгъсүм НАСЫЙБУЛЛИН

Кансыз булма,

Анам биргән туган тел,
Атам биргән кылыч тел.
Татар халык мәкале.

Төрки халыклар, шул исәптән татар халкы да, борын-борыннан ук үз теленең кадерен белгән, ана телен туган илләре-ватаннары белән тиң күргән. Борынгы татар бабаларыбыздан калган «Телеңне сакла, дәүләт күрерсең» дигән мәкаль моңа ышанычлы мисал. Ф.Достоевский да. «Тел — халык ул», дип, тикмәгә генә искәртмәгәндер.

Мең ел элек Даниянең Фарер утрауларына викинглар килеп утырган була. Даниялеләр үз ана телләрен ничек нык сакласалар, фарерлар да үз телләрен югалтмас өчен нык көрәшәләр. Даими көрәш эзсез калмый: 1822 елда фарерлар үзләренең ана телләрендә беренче китап бастырып чыгаралар. Шулай булуга карамастан, утыз өч мең кешедән торган халкы булган фарерлар тик йөз елдан соң гына мәктәптә үз ана телләрендә уку хокукын яулап алалар. Дания корольлегендә аларга әчке автономияле дәүләт статусы бирелә. Һәм фарерларның ана теле дәүләт теле дигән дәрәҗәгә яулап ала. Европада иң «кечкенә» телләрдән саналса да, фарерлар 1955 елда үз утрауларында академия ачканнар. Аның төп бурычы — милли телне, әдәбиятны саклау һәм үстерүдән гыйбарәт. Нибары бер ел эчендә анда йөздән артык әсәр бастырып чыгарылган. Авторларның яртысыннан күбрәге — фарерлар милләтеннән. Хәзер фарерларда җиде газета, алтмыш дүрт журнал чыга.

Безнең илдә тупас рәвештә бозып гадиләштерелгән вульгар социологизм тәгълиматында шундый бер хыянәтчел «фикер» хөкем сөрде янәсе, халыклар, милләтләр берләшәчәк, милли телләр дә бетәчәк... Хәлбуки, тормышта, чынбарлыкта алай түгел. Адәми зат, кеше — табигать баласы, табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Шунлыктан, аның туган халкы, милләте дә шундый ук табигый хәл булып санала.

Табигать үзе үк күпкырлы булган шикелле, анда яшәү рәвешләре дә, хуҗалык итү шартлары да бихисап. Халык, милләтләр дә (этнослар), шулай ук милли телләр дә күп төрле. 1983 елда Германиядә чыгарылган белешмәдә Җир шарындагы барлык халыкларның 5651 телдә сөйләшүләре турында язылган.

Нинди генә икътисади формация шартларында булмасын, кагыйдә буларак, Җир шарында көн күрүче халыклар белән бергә аларның ана телләре дә яши. Шуңа күрә, элекке СССРда яшәүче халыкларның милли телләре арасында коллык җәмгыятен, феодализм, капитализм дәверләрен кичеп, катлаулы юллар, дәһшәтле еллар үткән, шуннан соң да исән-имин калган тарихи телләр аз түгел. Алар арасында татар теле дә бар.

Тарихка күз салсак, бу яшәеш җиңел бирелмәгән. Мәсәлән, Ленин «халыклар төрмәсе» булган Русия патшалыгына, аның милли изүләргә нигезләнгән бөек державачыл-шовинистик сәясәтенә каршы гомере буе аяусыз көрәш алып барган, диләр; һәрбер милли телнең бер үк дәрәҗәдә тигез хокуклы булуын искәртеп, шушы тигезлекне тәэмин итәргә чакырганлыгын да әйтәләр. Мисал өчен аның 1914 елның декабрендә язылган әсәреннән өзек китерәләр: «Чит халыкларны изүче халык азат була алмый»... Революцион пролетариатның остазлары — Маркс һәм Энгельс әнә шулай диделәр... һәм без... кешелекле тигезлек принцибына корылган Великороссияне телибез... Великороссылар тарафыннан изелгән милләтләрнең барысына да тулы тигез хокук һәм үзбилгеләнү хокукы бирүне иң кискен, эзлекле, кыю, революцион яклау мәгънәсендә массаларны озак вакытлар тәрбияләү кирәк...»

Дәвам итсәк (ә бу очракта без моны эшләргә тиешбез), Ленинның милли мәсьәлә буенча таләпләре тәрбиягә генә кайтып калмаган. «Социаль демократия, дәүләтнең нинди генә урынында булмасын, һәрбер азчылык милләтнең хокукларын саклый торган гомумдәүләт законы чыгаруны таләп итә. Бу закон буенча, күпчелек милләт үзенә милли өстенлек тудыруга яки азчылык милләтнең (уку-укыту эшләре, теге яки бу телне куллану өлкәсендә, бюджет һ.б. эшләрендә) хокукларын кимсетүгә юнәлдерелгән һәрбер чара гамәлдән чыккан дип игълан ителергә, ә мондый чараны үткәрү, җәза бирелү куркынычы астында, тыелырга тиеш», — дигән катгый таләп тә куя ул.

Элекке совет империясенең нигез ташы булып саналган марксизм-ленинизмның милли телләр хакындагы тәгълиматлары элекке КПСС карарларында да ниндидер күләмдә чагылыш тапкан. «Туган телләрнең ирекле үсеше һәм СССРдагы барлык гражданнарның алардан тигез хокук белән файдалануы киләчәктә тәэмин ителәчәк», — диелә XXII съездда кабул ителгән КПСС Программасында. Болар бар да мәсьәләнең җитдилеген күрсәтеп торган кырыс та, таләпчән дә карарлар.

Элекке Төп законны ачсак, анда да бер үк хәлгә тап булабыз: «СССРның төрле расадан һәм милләттән булган гражданнары тигез хокукларга ия... туган телне һәм СССРдагы башка халыклар телләрен куллану мөмкинлеге белән тәэмин ителә.

Нинди расадан һәм милләттән булуларына карап, гражданнарның хокукларына турыдан-туры яки читләтеп нинди дә булса чикләү, аларга турыдан-туры яки читләтеп өстенлекләр бирүгә, дошманлык күрсәтүгә яки аны кимсетүгә һәртөрле өндәү закон нигезендә җәзалана» (36 нчы маддә).

Әлеге кисәтү тормышка ашырылмаса да, РСФСРның җинаять кодексында (74 нче маддә) да урын алган иде.

Элекке СССРның Төп законында игълан ителгән барлык раса, милләтләрнең тигез хокуклы булулары РСФСР Конституциясендә дә (32 нче маддә), Татарстан АССРның Конституциясендә дә (29 нчы маддә) әйтелгән булган. Әүвәлгә СССР, РСФСР, Татарстан АССР Конституцияләре шулай ук СССР гражданнарына белем алу хокукы турында игълан итеп кенә чикләнмичә, мәктәпләрдә үзләренең ана телләрендә уку мөмкинлеге хакында да раслыйлар иде.

Элекке кануннарның, хокук кагыйдәләренең кайсын гына алма, аларның һәммәсендә дә СССРда яшәүче барлык халык, милләтләрнең, ана телләренең тип-тигез хокуклы булулары хакында ассызыклап әйтелә. Тирә-як мохитне, табигатьне саклаган кебек үк, совет законы шундый ук табигать байлыгы булган барлык халыкларга, барлык милләтләргә, аларның ана телләренә бертигез карый, аларның берсенә дә, берниндн шартларда да өстенлек бирми. Хезмәттә, укуда дисеңме, хөкем вакытында дисеңме, совет милләтләре, аларның ана телләре бертигез хокуклы саналган.

Күргәнегезчә, элекке СССРдагы барлык милләтләрне, аларның ана телләрен какшамас дәрәҗәдә нык саклый торган, менә дигән, укып туймаслык байтак камил канун, дистәләгән законнар язылган икән. Мондый исемлекне тагын дәвам итәргә булыр иде.

Халык белән очрашканда бездән еш кына: «Шундый үрнәк, шундый камил законнар була торып, нишләп 1917 елның октябреннән бирле Русия империясендәге милләтләрнең, туган телләренең тигезлегенә хыянәт кылынды соң? Нишләп элекке СССРда тик бер тел — урыс теле генә күккә чөеп макталды, ә башка милли телләр онытылды? Нишләп үз халкын, үзенең ана телен яклап сүз әйткән кешеләргә сталинизм иярченнәре әүвәлгечә «милләтче» дигән тамга сугып утыра? Бу социаль чир кайчан, нәрсәдән башланды соң?..» — дип сорыйлар.

Сораулар күп, әмма бүген дә аларга туп-тулы һәм дөп-дөрес җавап биреп булмый әле. Чөнки тарих битләренең, дәүләт архивының байтагы әле һаман ябык хәлдә кала бирә. Ярый әле 1985 елда хәбәрдарлыкка бераз юл ачылды.

РКП(б)ның 1921 елда үткәрелгән XI съезды «Партиянең милли мәсьәлә буенча чираттагы бурычлары» дигән махсус карар кабул итә. Анда «Совет төзелеше һәм милли азатлык»дигән аерым бүлек тә була. Большевиклар партиясенең бу карарында ул елларда киң тарала башлаган бөекдержавачылык, колонизаторлык, шовинизмга тайпылуларның бик тә куркыныч, гаять зарарлы икәнлеге кисәтеп әйтелә. Мондый юнәлеш, күрсәң, Ленинны да борчый. Шуңа күрә, 1922 елның 30-31 декабрендә ул партиянең булачак XII съезды өчен «Милләтләр яисә «автономизация» мәсьәләсенә» дигән хезмәтен әйтеп яздыра. Анда мондый сүзләр бар: «... без инородецлар турында җитәрлек кайгыртып, аларны чын урыс держимордасыннан чынлап торып якларлык чаралар күрдекме? Минемчә, без мондый чараларны күрмәдек, ә без аларны күрә ала идек һәм күрергә тиеш идек».

Сталинның ашыгуын, административ мавыгуларын, аның социаль-национализмга каршы усаллануын да кисәтә ул. Сталин — Бөекдержавачыларның холыксызлыгы милли мәсьәләдә артканнан-арта бара. Милләтләрнең үзенчәлеге белән исәпләшәсе урынга, алар шәхси, команда-административ ысулларга күчәләр, тәрбияви эшне җәзалау, тоташ кан коюу кебек җәбер-золымга алыштыралар. Шуның аркасында кыска гына вакыт (якынча унбиш ел) эчендә милләтара мөнәсәбәтләрдә 1917 елгы революция заманындагы тәгълиматлардан бары тик коры өндәмә-шигарьләр генә кала. 30 нчы еллар азагында партиянең күпмилләтле үзәк комитеты, байтак милли компартияләр, Коминтернның күренекле җитәкчеләре тар-мар ителә, «милләтчеләр»гә каршы аяусыз көрәш тагын да киң җәелә. Милләтләрне тар-мар итү сәясәте кырыгынчы елларда моңарчы булмаганча җинаятьчел геноцидка тиң вакыйгаларга — карачай, калмык, чечен, ингуш, балкар, Кырым татарлары, Идел буе немецлары кебек халыкларны туган җирләреннән сөргүгә, Балтыйк буе халыкларын Себергә күчерүгә китереп җиткерә. Мондый көч куллану, фаҗигале җәзалау дулкыннарын сугыш вакытының үзенчәлекләре белән дә, сыйнфый көрәш белән дә аклап булмый, чөнки кешелек тарихында мондый вәхшилекнең үзе түгел, эзе дә юк. Шуңа күрә, коммунистлар тарафыннан үткәрелгән геноцидка тиң вәхшилек халыклар хәтерендә, халыклар тарихында һич уелмас тирән нәфрәт эзе калдырды. Хәзер аларны истән чыгару, әйтмичә, яшереп калдыру берничек тә мөмкин түгел инде.

Сталинчыларның җәбер-золымнарыннан илнең барлык халыклары да, шул исәптән урыслар үзләре дә җәфа чикте. Ләкин азрак санлы, славян булмаган халыкларның хәле бигрәк авыр иде, чөнки аларга карата ышанмау, шикләнеп карау кебек үзенчәлекле, аерата куркыныч шовинистик караш хөкем сөрде. Милли республикаларда, коммунистик партия оешмаларында җитәкчеләрнең күпчелеген җирле халык булмаган, Мәскәүдән җибәрелгән ВКП(б) — КПСС вәкилләре тәшкил итте. Идарә кылу, хакимлек итүнең төп тоткалары каян килгәнен белеп бетергесез «варяглар», аппаратчы түрәләр кулына күчте. ВКП(б) — КПССның сталинчыл Политбюросы шуңа охшаш милләтләр белән җирле халыкны идарә итүдән аера, милләтләрнең сәяси яктан тигез булмауларын раслый, милләтара мөнәсәбәтләрне катлауландыру өчен «төпле сабак» бирә. Октябрь революциясе һәм социализм принципларына төкереп карау өстенлек ала. Болар бер үк вакытта В.И.Ленинның тел сәясәтендәге тәгълиматларын бозуга, бихисап тайпылыш, канун бозуларга этәргеч сәбәп була.

Партия, комсомол, профсоюз оешмаларына, совет органнарына да җирле халыкның ана телен, рухи дөньясын санга сукмый торган урын биләүче карьеристлар үтеп керде. Ана теленә игътибар бирелмәде, аңа иң соңгы дәрәҗәдәге эш итеп, түбәнсетеп карау өстенлек алды. Һәрбер җирдә, идарә итүче оешмаларда эш фәкать урыс телендә генә алып барылды. Урам, мәйдан, фабрика-завод, колхоз-совхоз, кибет, мәктәпләрнең, мәдәният, транспорт оешмаларының исемнәре, игълан-мөрәҗәгатьләр бары урысча гына язылды, игъланнар тик урысча гына әйтелә башлады. Совет татарлары үзләренең туган телендә үз фикерен ана телендә әйтүдән, үз хокукларын, законда каралган мәнфәгатьләрен үз телендә таләп

канунлы бул

итүдән мәхрүм булдылар.

Татарлар өчен шундый аяныч хәл бүген дә дәвам итсә, милли әдәбиятның, музыка, рәсем һәм башка сәнгать әсәрләре иҗат итүнең хаҗәте дә калмаган булыр иде инде. Сергей Михалков бу хакта элекке СССР Язучылар берлеге пленумында да әйтергә мәҗбүр булды. «Әгәр дә без милли әдәбиятларны сакларга телибез икән, бик тиз арада мәктәпләрдә ике телне — урыс һәм ана телләрен өйрәнү буенча җитди чаралар күрергә тиешбез, — диде ул. — Беренче тел булып кешенең үз, ана теле, икенче буларак, урыс теле саналырга тиеш» («Дружба народов» журналы, 1988 ел, №6, 233 б.).

Мең ел буена үзебезгә гыйлем биргән гарәп, латин алфавитларын, татар милли хәрефләребезне югалттык. Укучысыз калган борынгы татар әдәбияты китап киштәләрендә саргаерга дучар ителгән иде. Матур гореф-гадәтләрдән, йолалардан, тарихи һәйкәлләребездән, әдәбият-сәнгатебездән, хәтта туган телебездән читләшә бардык. Икътисадта, мәдәнияттә байтак отышлы казанышларыбыз булуга карамастан, милли җөмһүриятебездә татар теле дистәләгән еллар буе дәүләт теле булып китә алмады.

Татарстанның күпчелек югары һәм урта уку йортларында дәресләр әле хәзер дә милли телдә алып барылмый. Республикадан читтә яшәүче биш миллионнан артык татарларның рухи тормышы, яшь буынны туган телгә, милли мәдәният-сәнгатькә якынайту мохтаҗлыгы түзә алмаслык хәлгә килеп җитте.

Кешеләрнең яшәү шартларын икътисади бурычлардан түбән кую, Татарстанның табигый байлыкларын әрәм-шәрәм итү, җир-суларны вәхшиләрчә пычрату, бер төбәктә чамадан тыш күп химзавод-комбинатлар, зарарлы предприятиеләр, су һәм атом электр станцияләре төзү, уңдырышлы җирләрне су астында калдыру — болар халык мәнфәгатьләреннән, иҗтимагый гаделлектән ерак тора.

Күп очракта шундый вәхшилеккә без үзебез дә гаепле, чөнки милләтебез язмышына битараф карыйбыз, канун, тәртип бозучыларны хөкемгә тартуны таләп итмибез. Үз халкын, үз табигатен, мәдәниятен, тарихын, ана телен хөрмәт итмәгән кеше башка халыкларга да миһербанлы булмый. Үз йортындагы байлыкны, җөмһүрият табигатен сакламау рухи хәерчелек, хәтерсезлек тәрбияләү белән бер бит ул.

Бай табигате, мең еллык язма әдәбияты, фәне, мәдәнияте, меңләгән каһарман геройлары булган, ил өчен кан түккән, биниһая көч салган татар халкы да, кызганыч ки, тора-бара шактый авыр һәм катлаулы хәлдә калды.

Кичә шулай иде, бүген дә шулай, ә иртәгә нәрсә булыр? Киләчәгебезнең нинди буласы безнең үзебездән, бөтен татар халкыннан, безнең бердәмлектән тора. Торгынлык елларыннан мирас итеп калдырылган яман шешне бергәләп җиңү, халыкны коткару, аның киләчәге турында кайгырту — барыбызның да изге бурычы Әйтик, татар телен яңадан дәүләт теле итеп торгызу башланган икән, бу һич тә гаҗәп түгел. «Яңадан» дип әйтүебез дә очраклы түгел, чөнки 1921 елның 21 июлендә Татарстан АССР дәүләте татар телен дәүләт теле дип игълан иткән, гамәлгә керткән булган. 1922 елның 8 маендагы декрет буенча Татарстандагы барлык мәктәпләрдә, һөнәрчелек уку йортларында татар теле укыту кертелә Бу мөһим таләпләр республиканың шул еллардагы Төп канунында да ныгытыла. Оренбургта татар телендә институт, Мәскәү, Свердловск, Ташкент һәм күп кенә башка шәһәрләрдә татарча техникум, педагогия училищелары эшли, илдәге татар мәктәпләре укымышлы милли кадрлар белән тәэмин ителә. Бу кадрлар юкка чыгарылмаган булса да, шәхес культы, торгынлык елларында алар «онытылган» Димәк, Татарстанда да халкыбызның ана теле, һичшиксез, дәүләт теле булырга тиешлеге көн кебек ачык иде. Бу — татар теленең гасырлардан гасырларга өзлексез дәвам итеп килә торган табигый хокукы да, хакы да!

Яшерен-батырын түгел, татар халкы күздә тоткан программ таләпләргә ышанып бетмәүчеләр, икеләнүчеләр, хәтта шовинистларча күсәк күтәреп каршы чыгучылар да очраштыргалый Мәшһүр мәгърифәтчебез Риза Фәхретдинов та заманында шундый җебегәнлеккә, гамьсезлеккә игътибар иткән. «Гарәп мәдәниятенең таҗыннан алмаслык, кыйммәтле таштай ялтыраган Ибн-Сина, Фарабиларның исемнәрен ишеткәндә никадәр шатлансак та, үзебезнең тарихыбызны, телебезне, милләтебезне тикшерүебезне, язуыбызны бер кимчелек санауларын күргәч, әрнеп кайгырмыйча һәм көенмичә калып булмый», — дип ачынып язган ул.

Әйдәгез, татарларга кемнәр, нәрсә дип каршы чыкканын күзаллыйк. Мәсәлән, «Үзеңне генә хөрмәт итмәскә» («Вечерняя Казань», 15 февраль, 1989 ел) дигән мәкаләсендә А.Кәримов, филологиядән бик ерак торса да, татар милли мәдәниятен саклап калу, арытабан камилләштерү хакында кайгыртучы зыялыларның изге хезмәтенә тап төшермәкче була. Әүвәл-әүвәлдән тәрәккый карашлы татар зыялылары үзләренең мәдәнияте, ана теле, әдәбияты, сәнгате турында берәр сүз әйтсә-нитсә, аларга каршы таш атучы ялагай затлар табыла торган. Бу бигрәк тә Русиядә 1905 елгы революциядән соң киң таралган, күзгә нык ташланган. «Ак патша» «бүләк» иткән Дәүләт Думасында изелгән милләтләрнең депутатлары, мөстәкыйльлек, азатлык яисә милли мәсьәлә хакында берәр сүз әйтте исә шундук аларга каршы шовинистик акырыш-бакырыш күтәрелгән Янәсе, «инородецлар милли эгоистлык, милли минминлек юлына баса. Ничек оялмыйлар!» Карагруһчылар уйлавынча, «халыклар төрмәсе» дип аталган Русиядә азчылык милләтләр коллык богҗрасында мәңге интегергә тиеш

Бу — үткән көн Кызганыч, аерым затлар әле хәзер дә тарихның әнә шундый таушалган «кара» битләрен сагына. Шәхес культы, торгынлык елларында андыйлар ватандашларына «халык дошманы», «милләтче» дигән тамга сугып, яла ягудан да тартынмаганнар Әле дә берәр татар үз халкының, татар теленең уртак ватаныбызда бертигез хокуклы булуын таләп итә башлады исә, коллык психологиясеннән арына алмыйча җәфа чигә торган икенче татарның тез буыны калтырый башлый. Янәсе, моңа күрше хатын Евдокия Петровна ничек карар, мәскәүләр нәрсә әйтер Бу җәһәттән үз теленә каршы чыккан кешенең тел төбен ачыклыйсы килә Татарстанның язмышы, киләчәге. дәүләт дәрәҗәсе, мәдәнияте, телләре хакында татар халкы, аның зыялылары үзләре кайгыртмаса, кем кайгыртыр. кем борчылыр соң? Дөнья халыклары, элекке СССР милләтләре дә үзләре өчен иң беренче нәүбәттә үзләре кайгырта түгелме соң? Һәм байтак кына нәтиҗәле уңышларга да ирешә! Низагка өндәүчеләргә сорау белән мөрәҗәгать итәсе килә башкаларны хөрмәт итә-итә, татар халкы үз дөньясын онытып, үзенең икътисадына, табигатенә, дәүләт гамәленә, мәдәниятенә, ана теленә игътибарны бермә-бер киметте, бер хәлдә катып, артта кала түгелме соң?

Каләм алып, туган халкын башка телдә «фаш итәргә» тотынганчы, аерым авторларга, һич югында, җөмһүриятебезнең, халкыбызның, туган телебезнең бүгенге халәтен Җир шарындагы башка милләтләр белән чагыштырып карарга кирәк иде. Чөнки, борынгы фәйләсуфлар әйтмешли, бар нәрсә дә чагыштырып караганда гына ачыклана. Бездән дә әнә шундый чагыштыру, ашыкмыйча а[illegible]клау, татар халкының туг[illegible]елен тулысынча торгызу һәм үстерү сорала.

Бүгенге хәлиткеч яңарыш-үзгәрешләр бар халыкларга да, һәр милләткә дә зур мөмкинлекләр бирә. Татар халкы да искечә кала алмый. Үз тормышыбызны без үзебез үзгәртергә, аңа үзебез хуҗа булырга тиеш Телебезгә дә, табигатебезгә дә, эшләп тапкан байлыкларыбызга да!

КАРАҢГЫ ЮЛЛАРНЫ ЯКТЫРТА

(Ахыры. Башы 9 нчы биттә).

тәрбияви як иң төп максатларының берсен тәшкил итә Аларда тәрбия начар мисалларны күрсәтеп, гыйбрәт бирү аша да, намуслы һәм тырыш җаннарны тасвирлап, якты үрнәк күрсәтү юлы белән дә башкарыла. Һәр ике ысул да тәэсирле нәтиҗәле килеп чыга Әсәрләрне укыган чагында әле генә күз алдыннан үткән вакыйгалар турында туктап-туктап уйга каласың.

Юрист язучыбыз иҗатының тагын бер мөһим ягы — алар бүгенге укучының хокук һәм кануннар буенча аң-белемен дә арттыра. Җәмгыятьтәге һәр кешенең үз адымнарын уйлап һәм үлчәп ясарга тиешлеген искәртә алар

Мәгъсүм ага Насыйбуллин иҗатының көчле яклары турында матбугатта матур гына фикерләр дә әйтелә килә Аларның кайберләрен бирәдә дә китерик Хәсән Сарьян. «М.Насыйбуллин тормыш фактын, хакыйкатьне аңга төртеп укымый, ә бәлки һәммәсен йөрәк аша үткәреп, күңелләрне тибрәтеп уздырырга тырыша» («Казан утлары» 1972 ел, 9 нчы сан) Мөхәммәт Мәһдиев «М.Насыйбуллин күп яза, үз жанрында актив эшли Аның бөтен иҗаты өчен төп сыйфат — әсәрләренең бөтен буена сузылган бер идея бар совет җәмгыятендә бер генә җинаять тә җәзасыз калырга тиеш түгел» («Казан утлары» 1975 ел, 9 нчы сан) Фәрваз Миңнуллин «Бүгенге көндә М.Насыйбуллин шушы өлкәдә — детектив жанрда — иң күп, иң нәтиҗәле эшләүче язучыларыбызның берсе Аның елдан-ел каләме чарлана, иҗади колачы киңәя бара» («Социалистик Татарстан» 1981 ел, 9 апрель саны) Фоат Галимуллин. «М.Насыйбуллин китабы теләсә кайсы яшьтәге укучыны да кызыксындырырлык. Шулай да ул күбрәк яшьләр кулына төшсә иде Ник дигәндә. тормыш юлына яңа аяк басучы биредә сурәтләнгән гыйбрәтләргә үз вакытында юлыкса, алардан үзенә тиешле нәтиҗәләрне күпме иртәрәк ясаса, шулкадәр әйбәтрәк булачак» («Социалистик Татарстан» 1988 ел, 11 август саны)

Әйе, Мәгъсүм аганың чын-чыннан мактана алырлык зур иҗаты бар Ул — татар укучысының иң яраткан язучыларыннан берсе Алай гына да түгел. аның әсәрләре бик күп чит телләргә дә тәрҗемә ителгән Күрше башкорт һәм урыс теленнән тыш, алар тагын үзбәк, казакъ, каракалпак, чуваш якут, удмурт кыргыз телләрендә дә басылган Иң отышлы әсәрләре исә кытай һәм төрек телләренә дә тәрҗемә ителгән, чит илләрдә дөнья күргән

Бүген республикабызда нәшер ителә торган газит һәм журналларны ачсак та, аның исемен еш күрәбез. Мәгъсүм ага үзен борчыган уй-фикерләрен халкыбыз белән уртаклаша, үткен-үткен мәсьәләләрнең уңай хәл ителүе өчен янып-көеп яши. Ул татар милләтенең киләчәген һәм бүгенге яшь буын язмышын кайгыртып кызыклы, мәгънәле мәкаләләр яза.

Әле бит без Мәгъсүм аганың 1943 елдан башлап Бөек Ватан сугышы мәхшәрендә катнашуын әйтмәдек Япь-яшь килеш сугыш утына барып керү — кеше өчен үзе бер зур һәм гаять мәкерле сынау бит әле ул! Мәгъсүм ага әнә шул олы сынауны исән-сау үтеп кайткан! Аннан соң да озак еллар хокук саклау буенча һәм иҗатта тир түгеп эшләгән 1975 елда ук аңа «Юстициянең өлкән киңәшчесе» дигән югары дәрәҗә бирелү үзе үк күп нәрсә турында сөйли булса кирәк! Хөрмәтле язучыбызның «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исеме дә бар

...«Аккош күле» дигән бик ямьле урында татар язучыларының иҗат йорты бар Шунда барып, капканы ачып керү белән, мин иң башта Мәгъсүм аганы күрәм әнә ул үзенең бакчасында алмагачлар, карлыганнар арасында йөри Һаман нәрсәдер эшли, тик тормый. Аның акыллы. уйчан йөзендә үзенең тынгысыз эчке дөньясы. рухы гына түгел. ә дөньяның бик күп борчулары, гамьнәре дә чагыла тосле. Әмма язучының үзенә һич кенә дә 70 яшьне бирәсе килми Юк, килми! Күз генә тимәсен!

Мансур ВӘЛИ.

Үткәнебезгә яңача бер караш

Заманалар үзгәрә. Хәзер күп кенә урыс тарихчылары да татар-монгол изүе булганлыгына шик белдерәләр. Алай гына да түгел, Алтын Урда империясе булмаса, Русия дә үз дәүләтен төзи алмас иде, дигән фикерне алга сөрүчеләр саны да арта бара. Ләкин, ни кызганыч, тарихи хакыйкатькә каршы торып булмасын аңлый башлаган кайбер шовинист тарихчылар аңа җайлашу юлын да эзләргә керештеләр инде. Мәгълүм ки, бу җайлашуның төп максаты һаман да урысны башка халыклардан өстенрәк итеп күрсәтүдән гыйбарәт. Мәскәүдә чыга торган «Россия» гәзитендә дөнья күргән «Новая версия нашего прошлого» дигән язмада да шундый омтылышларның чагылышы ярылып ятә. Әлеге язманы кыскартусыз һәм үзгәртүсез сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. Укыгыз һәм уйланыгыз. Аннары нәтиҗәне үзегез ясарсыз.

Урыс илендә татар-монгол изүе булганмы? Бөек Новгород һәм «Куликово кыры» — алар кайда? Нәрсә ул Литва һәм Себер кайда урнашкан? Бу һәм тагын бик күп сорауларга гадәттиддән үзгә булган җаваплар да бар икән. Ул җавапларны — ни гаҗәп! — тарихчылар түгел, ә төгәл фәннәр белгечләре бирә. Алар — Русия Фәннәр академиясе академигы, Мәскәү дәүләт университетының дифференциаль геометрия кафедрасы мөдире Анатолий Фоменко һәм физика-математика фәннәре кандидаты Глеб Носовский. Бу галимнәрнең фикеренчә, борынгы урыс тарихы патшаларыбыз тарафыннан бик тә аңлы рәвештә бозылып күрсәтелә башлаган икән. Ни өчен? Бу хакта әлеге авторларның «Новая хронология и концепция древней истории Руси, Англии и Рима» дигән ике томлык хезмәтләрен укыгач, белеп була.

Шундый сәер бер сорау алга килеп баса. Әгәр Русия берәр як тарафыннан (Иделдәнме ул, Көнбатыштанмы) яулап алынган һәм колонияләштерелгән булса, Русиянең көнбатышында, йә булмаса, Дон елгасы яисә Иделнең түбән агымында яшәгән казакларның басып алучылар белән бәрелешүе хакында бер-ике генә булса да хәбәр калган булырга тиеш иде. Шуны билгеләп үтәсе килә Русия тарихы дәреслекләрендә безне, казак гаскәрләре бары тик XYII гасырда гына килеп чыкканнар, дип (имеш, холоплар Дон буена чыгып качканнар) ышандырмакчы булалар Әмма тарихчыларның үзләренә, мәсәлән, Донда казак «дәүләте»нең XYI гасырда ук булганлыгы билгеле (тик бу хакта алар никтер дәреслекләрдә бер сүз дә әйтмиләр).

Шулай итеп, урда (каян гына килеп чыккан булса да), үзенең юлында (Идел буйлап өскә таба) казак «дәүләтләре» белән котылгысыз рәвештә низагка керергә тиеш булып чыга Ә моны раслаучы бер генә мәгълүмат та юк. Хикмәт нәрсәдә соң? Әйтелгәннәрдән чыгып, монда табигый бер фараз барлыкка килә урда гаскәрләре казаклар белән алар аның аерылгысыз бер өлеше булганга күрә сугышмаган, ахры.

Икенче төрлерәк әйтсәк, урда — ул регуляр урыс гаскәре булган...

Нәрсә ул Монголия һәм татар-монгол явы? Казаклар һәм Алтын Урда

Хәзер инде «Монголия» дигән сүзнең килеп чыгышы турында уйланып карыйк. Без (Морозовтан соң) аны «БӨЕК» дигән мәгънәдәге «Мегалион» сүзеннән килеп чыккан, дип исәплибез. Көнчыгыш Русия шушы көнгә тикле Великороссия дип йөртелә Шуның өчен дә «Монгол империясе» — ул «Бөек империя», ягъни, — урта гасыр Русия империясе.

Көнбатышның урта гасыр чыганаклары татар-монгол яулары турында нәрсә әйтәләр соң?

Венгрия короле язмаларында һәм аның Рим Папасына язган хатларында Батый хан гаскәрләрендә урыс гаскәрләре булуы турында хәбәр ителә

«Алтын Урданың төп кораллы, хезмәт күрсәтүче һәм эшче көчләре урыслардан тора...»

Гаҗәп бит бу! Урта гасыр чыганаклары татар-монгол гаскәрләре дип йөртелә торган гаскәрләрдә асылда урыс кешеләре генә булган, дип тәкрарлыйлар Хәзерге тарихчыларга бу, әлбәттә, ошамый һәм алар болайрак итеп боргаланалар «урыслар сан ягыннан күбрәк булган булсалар да, алар анда кимсетелгән хәлдә яшәгәннәр» һ.б.

Тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк «Русия Монголия империясенең бер улысына әйләндерелеп, Татар-монгол иле дип атала башлаган», икән.

Алайса, бәлки, Русия инде әүвәлгедән үк Татар-монгол иле, ягъни «Бөек империя» — Монголия булгандыр Табигый ки, аның халкы составында татарлар да булган.

«Куликово кыры» кайда соң ул?

«Куликово кыры»нда булган «мәшһүр» сугыш вакыйгасына килик (1380 ел) Гадәттә, ошбу «Куликово поле» Тула өлкәсендә — Дон белән Непрядва сулары кушылган җирдә булырга тиеш, дип исәпләнә.

Икенче яктан карасаң, бу җирләрдә «мәшһүр» сугыш булганлыгын раслардай бер генә эз дә юк, диләр тарихчылар. Каберлекләр дә юк (ә, имеш, дистәләрчә, хәтта берничә йөз мең кеше монда башын салган), берничә корал-маздар калдыклары да. Аннары шундый зур сугыш өчен бу «кырның» киңлекләре бөтенләй тар. Моңа күп тарихчылар игътибар иткән иде инде Шундый бәләкәй аланга сугышырга дип ике яктан да шулкадәр гаскәр нишләп җыелды икән?. Сорау туа да туа инде чын «Куликово кыры»н без дөрес эзлибезме икән соң?

Әйтеп үтик әле (күп кеше моны белми) Мамай — ул носари (христиан) исеме, аны әле дә безнең догалыкларда (святцы) «мамий» рәвешендә очратып була Билгеле инде, бу аз гына үзгәртелгән «мама», «мамин», ягъни «сын матери» («ана баласы») килеп чыга Шул рәвешле борынгыдан килгән «Батий» исеме — «батька», ә Мамай (мамий) — әни дигән мәгънәне аңлата икән.

Менә сиңа мә! Дмитрий носари (христиан) исемен йөрткән хәрби җитәкче белән сугышып йөргән икән! Бәрелеш Дмитрий Донскойның Мамай ханны (Мамай беркайчан да хан булмаган. — Ред.) зур җиңүе белән тәмамлана Хәлбуки, шул ук (1380 яисә 1381) елны Мамай тагын бер тапкыр «Калка»да Туктамыш хан тарафыннан тар-мар ителә вә үтерелә Кайчан, кайда җыеп өлгергәндер Мамай шулкадәр гаскәрне! Хәзерге китаплардан без, «Калка елгасы»нда, дип укыйбыз Әмма әүвәлге урыс елъязмаларында беркайчан да алай дип язылмаган! «На Калках» дигәннәр Аерма бик зур да түгел сыман, ләкин «на Калках» дигән сүз инде аның «елга», «су буе» икәнлеген шик астына куя Алай гына да түгел, «Куликово кыры»н искә төшерә бу — «на Калке» — «на Куликовом».

Әлеге ике вакыйганы чагыштырып карагач, тагын да яманрак ассоциация туа. Бу ике «сугыш» бер үк «орыш»ның чагылышы түгелме икән? Алай булса, Дмитрий Донской гади генә итеп Туктамыш хан белән алыштырыла да куела.

.. Урыс тарихындагы мәгълүм вакыйгага тукталып үтик. Ул — Аксак Тимер чирүе килүдән куркып, Владимирдан Мәскәүгә Владимирның Ходай анасы рәсемен (иконасын) күчерү вакыйгасы Бу турыда урыс чыганакларында күп сөйләнә. Әлеге рәсемне (иконаны) каршылау хөрмәтенә Сретения («Встретенье» — каршылау) дигән бәйрәм урынлаштырыла. Шул урында (Мәскәүдә) бүген дә «Сретенка» урамы һәм «Сретенский бульвар» бар.

Инде елъязмадагы текстның ахырына күз салыйк. «Архангелогородский летописец»ны кулга алабыз (Урыс елъязмаларының тулы мәҗмугасы, 37 нче том, 81 нче бит). Укыйбыз: «И принесоша икону и сретоша Киприян митрополит со множеством народу, НА ПОЛЕ КУЛИЧКОВЕ, иде же ныне церкви каменна стоит во имя Сретенья Пречистыя, месяца августа, в 26 день».

Шулай итеп, искитмәле һәм бик тә табигый фараз килеп туа: КУЛИКОВО КЫРЫ МӘСКӘҮДӘ ИКӘН ҺӘМ АНДА СРЕТЕНКА УРНАШКАН, имеш

Иван Грозный дәвере

.. Безнең ил тарихында бик зур бер ак тап бар Ул — Иван Грозныйның патшалык итүе Хәзер укучыбызның бик нык исе китүе ихтимал: ничек инде ул, янәсе, без бит Грозный турында бик аз белмибез ләбаса Кинофильмнарга чаклы төшереп бетерделәр бит инде Хәлбуки, Грозный заманнарыннан асылда берничә дә чын документ калмаган. Бу факт белгечләргә бик тә мәгълүм (ләкин дәреслекләрдә генә алар бу хакта ни өчендер язмыйлар).

Бик күп тарихчылар (бу хакта укучылар да, шиксез, хәбәрдар булыр) Грозныйны исәр бер шизофреник бупарак беләләр Аның кылган гамәлләрен аңлатуы чыннан да бик кыен Иван Грозныйның патшалык итүе хакында гомуми тәэсир шундый Урыс иленә һәр тарафтан дошманнар ябырылган бер мәлдә, безнең падишабыз үз илен үзе яулап йөри Өстәвенә әле генә сугышларда дан алган хәрби җитәкчеләрен дә җәзалап үтерә бара. Әлбәттә, теләгең булганда, бөтен нәрсәгә дә шәрех табып була. Хәтта традицион тарихчылар да ниндидер сәер шизофрения турында әллә нинди фаразлар уйлап чыгару белән мәшгуль. Илендә чикләнмәгән хаким булуына да карамастан, Грозный вакыты-вакыты белән боярларның үзенә ант яңартуларын таләп итә, Константинопольдән хакимлеген тәсдыйк итүләрен сорый, хәтта 1576 елда кабаттан бик купшы итеп үзенә таҗ кигертү тантанасы уздыра. Ни өчен? Тарихчылар моңа җавап бирми. Алай гынамы соң әле! Ул олы башы белән үзенә карачылар мәҗлесе (опекунский совет) оештыра һәм һәртөрле эшләрдән читләшә. Аннары, опричнинаның коточкыч дәверендә үзенә каршы чыгардай бөтен кешеләрен кырып чыккач, Грозный Думаны кулда тота алмаслыгын сизә. Һәм тәхеткә Казан ханнарының бер чыбык очы булган Симеон Бекбулатович дигән җәбаһаир генә Касим шаһзадәсен утыртып куя, үзе гадирәк кенә бер йортка күчеп утыра. Сәер, бик сәер! Шул ук вакытта шаһзадә Мәскәү буйлап бик купшы гына кыяфәттә типтереп йөри...

Шушылардан гади генә бер фараз оештырырга була.

Безнең фикеребезчә, «Грозный» ул берничә патшаның гомумиләштерелгән, җыелма образы булырга тиеш.

Бу үзе болай яңа фикер түгел. Чит ил чыганакларында Грозныйның вакыт-вакыт кыяфәтен нык үзгәрткәнлеге турында языла. Грозныйның кыяфәте шактый җентекле сурәтләнә. Аларны укыгач, төрле кешеләр тасвирланганына шик калмый. Моның стандарт шәрехе болай патшаның кыяфәте ниндидер авыру нәтиҗәсендә үзгәргән булырга тиеш. Ләкин башка аңлатмалар да бар. Аларның асылы — тәхеткә башка кеше утырган дигән фикердән гыйбарәт Хәлбуки, традицион кысаларда калырга мәҗбүр ителгән тарихчылар бу алмашынуның мәгънәсенә һәм дә ул алмашынуларның берничә тапкыр булганлыгына төшенә алмыйлар...

(Ахыры 23 нче биттә).

УНӨЧЕНЧЕ БИТ

Әйбәт эшлим үзем, чөнки тракторым үзем кебек әйбәт Кырга да чабам, район үзәгенә дә барып, ярышып, бүләк алып кайтам

— Яхшы-яхшы, афәрин-афәрин, булдыра-булдыра! — дип, кулымны кысып, хәтта мактау язулары белән күмәләр кайчакта.

Тик менә бик яманы яшем егерме тугызынчыга авышса да, авылыбыз кызларына ярты авыз сүз әйтә алганым юк Өстәвенә, әле миңа шомырт күзле, сызма кашлы, бәтермә иренле кыз кирәк Андый кыз күрше авылда бар икән дип ишеттем.

Кайчакта Мисхәт кордаш хәлемә керә. кәтойдым үземне. Әле аңга да килә алмас идем Күрәм ике кыз култыклап торгызалар мине Танышып киттек Берсе — Гөлнара исемлесе — шушы кәҗәле йорт хуҗасы икән Бакча артларындагы су буенда бераз гөрләшеп йөрдек аның белән. Икенче кичкә дә очрашырга вәгъдә куештык

Миңа кайтырга кирәк Кызга матай сездә дип әйтеп тормадым Аны әйләренә кертеп җибәргәч, сагаеп кына карыйм капкадан Күрәм кәҗә, матайның утыргычына ук менеп йокларга яткан Килеп кенә җиттем дигәндә, сакалбай... ярты метрлы мөгезләрен миңа тө-

Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ

Акыллы эт белән усал кәҗә

җә-матаен биреп тора. Беркөнне шулай, караңгы төшеп җитте дигәндә. мин дә теге кызлар авылына полный хутка киттем Матайны куярга беренче йортка ук тукталдым. Сул як капкага күз атсам — «Монда акыллы эт тора» дигән язуны укыйм. Капканы ачам. Күрәм: тана кадәр йонлач эт белән аңардан кечерәк һәм олы сакаллы кәҗә тын гына җим ашап торалар. Сөйләшмиләр дә, көлмиләр дә. Шул исәптән, исәнмесез, дигән сүземә җавап та кайтармадылар хәтта. Акыллылар дип уйладым да матайны кертә башладым. Кинәт теге кәҗә сакалларын җыйнап, олы мөгезләрен миңа төбәде. Аннары... аңыма килгәндә генә бәп каршыма килмәсенме! Артка да карамый ычкындым, ун чакрымны җәяү йөгердем.

Икенче көнне велосипед белән киттем. Транспортны кая куярга дип баш ватканда, карыйм йортта теге кәҗә күренми, тик акыллы эт кенә Эт тими, велосипедны куям. Матайны алып чыгыйм дисәм — тагын теге кәҗә атылып каршыга килде Әлеп ташларга әзерләнгәндә генә Гөлнара тавышы бүлде

— Бу юлга калды-ы-ыр! Бу юлга гына-а-а!

...Озакка сузмадым — кәҗәле йортның кияве булдым. Бераз үткәч, «Шул кәҗәне «к-х» итикме әллә?», дип эндәштем хатынга.

— И, җүләр. этне саклый бит ул, — дип ачуланып әйтте ул, бер дә ошатмыйча.

Касыйм ТӘХАУ

Гыйбрәтле гыйбарәләр

Намуслы тир түгеп алдыра,
Карак баштан бүрек салдыра

* * *

Югына үкенмә, барына шатлан,
Җае чыкканда тулпарга атлан.

* * *

Суда — агу, һаваларга газ чыга,
Җирдә кеше, суда балык гончыга

* * *

Кеше тормышы гомер белән үлчәнә,
Ә гомере үлем белән чикләнә

* * *

Әзергә бәзер булып ыргылма,
Кеше өлешенә тыгылма.

* * *

Телдәрнең теле - бездер,
Нәфесле туймас күздер

* * *

Комсызның комсызлыгы йөзендә,
Чагкы булып уйный күзендә

* * *

Ачкүз күнеле юмартлыкка тартмас,
Кышын анардан кар да артмас.

* * *

Яманның шәфкатьлелеге
Булыр кылган этлеге

* * *

Мулланы күрсә -- укына,
Попны очратса — чукына.

* * *

Бай налогтан курыкмый — кесәсе калын,
Ярлы салым түли, сатып бар малын.

* * *

Телчәннең телен тилчә тоткыры,
Сөйләгәндә шул телен йоткыры.

* * *

Әшнә әшнәсез тормас,
Читкә барып баш ормас.

Сәләви белән Мәләви

Аларны тамашачы күптән инде яратып өлгерде. Әллә исемнәрен әйтү бик җиңел булганга, әллә инде матур итеп көлдерә белгәнгә. Аларны без сәхнәдә дә, телеэкранда да күрдек, радио аша да еш ишеттек.

Ә менә бүген Сәләви белән Мәләви — «Мәдәни җомга»ның кунаклары.

— Программабызда — скетчлар, мәзәкләр, пародияләр һәм дә башкалар, - диделәр алар, уен-көлкегә һич тә урын калдырмыйча. — Бу дөньяда юморсыз яшәү гомерсез яшәү белән бер дип уйлыйбыз...

Сәләви белән Мәләвинең репертуарында Фаил Шәфигуллин, Камил Кәримов кебек язучыларның әсәрләре урын алган. Ә инде соңгы вакытта Мансур Хәйертдиновның (ягъни Сәләвинең) үз язмалары өстенлек итә икән. Алар үз гастрольләре белән Русиянең күп кенә төбәкләрендә, Башкортстанның һәм, әлбәттә, Татарстанның бик күп районнарында булып чыкканнар. «Сәләви белән Мәләви» исемле программада әле тагын җырчылар Эльза Гатауллина, Флера Газизова һәм дә музыкант Нәҗип Закиров катнаша.

Без бүген Сәләви-Мәләвинең кайбер мәзәкләрен тәкъдим итәбез. Һәм, «Карт сыер белән яшь сыер» скетчыннан бер сурәт биреп, Сәләвинең – Мансур Хәйертдинов, Мәләвинең Камил Исмәгыйлев икәнлеген исегезгә төшерәбез.

У Б. (укып бетер) 17 октябрьдә Казанның «Юность» мәдәният сараенда Сәләви белән Мәләви катнашында зур тамаша була.

Нияз АКМАЛ.

Америкада

Булганмы, юкмы бу хәл, без белмибез. Имеш, Мәләви Америкадагы бер кибеткә эләккән. Андагы байлыкка шаккатып, сатучыдан сорый икән:

— Сатучы әфәнде, әйтегез әле, сезнең кибеттә хатынга бүләккә нәрсә булса да бармы?

Сатучы. Менә сезгә ассортимент, сайлагыз.

Мәләви. О, нәрсә генә юк бит монда... Әйтегез әле, бу нәрсә?

Сатучы. Бумы? Бу – колготкилар...

Мәләви. Бирегез, алам, алам... Ә монысы нәрсә?

Сатучы. Монысымы? Монысы хатын-кызлар өчен комбинация...

Мәләви. Монысын да алам Әнә тегесе ни тагын, әйтегез әле?

Сатучы. Соң шуны да белмисезме?

Мәләви. Каян белим инде, мин бит авылдан килгән кеше...

Сатучы. Бу була бюстгальтер!

Мәләви. Ә нәрсә ул?

Сатучы. Бюстгальтер — хатын-кызның имиен тота торган нәрсә ул.

Мәләви. Юк, барысына да акчам житмәс бугай, монысы кирәкми, үзем тотармын.

Сәләви мәхәббәте

Сәләви Казан вокзалында бер кыз белән танышырга тели Исемен сорый Кыз эндәшми

Сәләви. Исемеңне әйтергә теләмисең икән, матурым, исемеңнең беренче хәрефен генә булса да әйт, мин үзем уйлап табармын Исемең нинди хәрефтән башлана?

Кыз. «Ш»

Сәләви. Шәрифәме?

Кыз. ?!

Сәләви. Шәмсенур? Шәмсекамал?

Кыз. ?!

Сәләви. Ничек соң исемең, әйт инде!

Кыз. Шәрия!

Шулай итеп болар танышып китәләр Сәләви кызны ресторанга чакыра

Сәләви. Чибәрем, нәрсә ашыйбыз?

Кыз. «М», ди.

Сәләви. Макаронмы?

Кыз. ?!

Сәләви. Морожный, мармелад?

Кыз. ?!

Сәләви. Әйт инде, жаныем,нәрсә ашыйсың килә?

Кыз. Мермишель!

Сәләви. Ә нәрсә эчәбез?

Кыз. «Ш»

Сәләви. Шампанскиймы?

Кыз. ?!

Сәләви (түземлеге бетеп). Соң, «ш» хәрефенә нинди эчемлек бар соң, белмим дә бит мин, әйт инде, жаныем, нәрсә эчәбез?

Кыз. Шамагон!

Шулай итеп, шамагон эчеп мермишель белән капкалагач, Сәләви кызны биергә чакыра. Биегәндә кагырак кочаклап ала да кызның колагына пышылдый:

Беләсеңме, мин нәрсә телим хәзер, ә? Ә син ни телисең?

Кыз. «М»

Сәләви. Мәхәббәтме?!

Кыз. Юк ла инде, мермишель кире чыга

Мәзәкчеләр барысы да

Мәләви. Карале, Сәләви, син генә түгел, синең хатынын да мәзәкне бик кызык итеп сөйли белә икән бит..

Сәләви. Шулаймыни?

Мәләви. Беркөн мин аны трамвайда очраткан идем, ул миңа шундый кызык мәзәк сөйләде -- көлә-көлә эчем катып караваттан чак егылып төшмәдем

Әкрам ШӘФИГУЛЛИН фотосы

Җиде бабаңның

Әйдәгез, Хәтер көне алдыннан тарихи әдәбиятта исемнәре язылып калган шәхесләребезнең кайберләрен яд итеп искә алыйк, мөхтәрәм милләттәшләр. Исемнәр янында шәхесләрнең тоткан урыны, дәрәҗәсе дә бирелде.

Сәйед — дин башлыгы; нәселе Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташкан кеше гене бу дәрәҗәне йөртә алган. Абруй-дәрәҗәсе белән ханнан да өстен саналган. Каршысына сәед очраса, хан ияреннән төшеп, сәеднең чабуын үбеп, сәламләргә тиеш булган.

Хан — мөстәкыйль дәүләт — ханлыкның иң олы түрәсе.

Бәкләр бәге (бәкләрибәк) — ханнан кала иң олы дәрәҗә, дүрт вәзир-карачының башлыгы.

Карачы — хан янындагы дүрт олы бәкнең берсе.

Бәк, би, бәй — карачыдан кала иң олы дәрәҗә.

Мирза (әмирзадә) — бәк углы, әмир углы.

Ханзадә — хан углы.

Шаһзадә — солтан, хан-шаһ углы.

Углан — махсус әзерлек мәктәбе узган яшь сугышчы.

Әмир — дәүләт башлыгы, яу башы.

Бахшы — елъязмачы, сәркатиб.

Хаҗи — Хаҗда булган кеше, гадәттә, дин башлыгы.

Солтан — хан нәселеннән булган хатын-кыз исеменә ияреп йөрүче сүз, титул.

Бикә — бәк-би хатыны.

Тутай — туташ, затлы нәсел кызы.

XIII йөздән алып XYI йөз еллыкта яшәгән асыл затларыбыз белән дә танышыйк. Тыңлагыз, тарих төпкеленнән борынгылар эндәшә.

Адың кем?

Саин хан — Бату ханның кушаматы, дәрәҗәсе.

Лөханә — манголларга каршы баш күтәрүчеләр җитәкчесе.

Чалубәй батыр — 1380 елның 8 сентябрендә яу кырында һәлак була.

Гыясетдин — Казан ханы.

Бикчура — хан.

Габдулла — хан.

Алтынбәк — шаһзадә.

Галибәк — хан.

Рабига — хан кызы.

Сөенбәк — шаһзадә.

Хөсәен солтан — Казан түрәсе.

Мөхәммәт солтан — Казан түрәсе.

Җантык — шаһзадә.

Җанбакты — ыру башлыгы, мирза.

Мөслим баба — ыру башлыгы, Мөслимгә нигез салучы.

Тәтеш баба — ыру башлыгы, Тәтешкә нигез салучы.

Мамадыш баба — ыру башлыгы, Мамадышка нигез салучы.

Олуг Мөхәммәд — хан.

Айдар — бәк.

Идегәй — әмир.

Ширин Тикинә — бәк, атаклы Шириннәр (Шырыннар) нәселенең башы.

Миңле Булат — мирза.

Хөсәен — хан түшәкчесе.

Кечек Мөхәммәд — хан.

Мансур — углан, Мәскәүдә илче.

Галибирде — бәк, Олуг Мөхәммәднең киявe, Беләү сугышында шәһит киткән.

Хәсән Хуҗа — бәк.

Хаҗи Хөсәен — илче, батыр.

Бигеч — Олуг Мөхәммәд илчесе.

Сәед Хөсәен — баш илче.

Үтәш — бәк, илче.

Кораеш — бәк, илче.

Дилхуҗа — бәк, илче.

Бәрак — хан.

Мәхмүд — хан, Олуг Мөхәммәд углы.

Касыйм хан — Олуг Мөхәммәд углы.

Якуб — шаһзадә, Олуг Мөхәммәд углы.

Йосыф — шаһзадә, Олуг Мөхәммәднең төпчеге.

Мәүланбирде — углан.

Сәет Әхмәд — хан.

Хәлил — хан.

Котлыкыя — бәк.

Ибраһим — хан.

Нурсолтан — Нугай падишаһының кызы, Хәлил ханның хатыны, ул үлгәч (үтерелгәч), Ибраһим хан хатыны, Ибраһим үлгәч (үтерелгәч), Кырым ханы Миңле Гәрәй хатыны.

Фатыйма солтан — Ибраһим ханның олы хатыны, ханша.

Маһи солтан — Касыйм ханшасы.

Хан Солтан — Касыйм ханшасы.

Тәкыйль солтан бикә — Касыйм ханшасы.

Колбә — баһадир.

Габдел Мөэмин — Касыйм хан яклы Казан бәге.

Толәзи — бәк, урыска әсир төшә.

Бирдеш — бәк, әсир.

Колынбай — бәк, батыр.

Хуҗабирде — бәк, әсир.

Мортаза — Мостафа углы, шаһзадә.

Әлмәш — мирза, әсир.

Хаҗибирде — мирза, әсир.

Мөхәммәд Әмин (Әҗем) — хан, Ибраһим хан углы, Нурсолтан углы.

Габдел Латиф — хан, Ибраһим хан белән Нурсолтан углы.

Илһам — хан, Ибраһим хан белән Фатыйма солтан углы.

Миңле Таһир — шаһзадә, Ибраһим хан белән Фатыйма солтан углы.

Әлгазый — батыр.

Мамык Шәйбан — хан.

Колмәт — бәк.

Урак — бәк.

Садыйр — бәк.

Агиш — бәк.

Уфалы — бәк, илче, Мөхәммәд Әмин кешесе.

Нурдәүләт — шаһзадә.

Аппак — мирза, Мәскәүдәге Кырым илчесе.

Колдәрвиш — сәедзадә, илче.

Карачәй Ичүк — бәк, илче.

Муллан — мирза, илче.

Хаҗи Дәүләт — бәк.

Туктамыш — хан.

Абыш — углан, гаскәр башлыгы.

Бораш — сәйед, гаскәр башлыгы, илче.

Агалак — хан, Себер кешесе, Мамыкның туганы.

Шаһкол — бәк.

Аргын — карачы.

Кадыйрбирде — ханзадә.

Муса — бәк, әмир, Нугай түрәсе, Йосыфның атасы, Сөембикәнең бабасы.

Ягмурчы — мирза, Нугай иленнән.

Йосыф — солтан, шаһзадә, әмир. Сөембикәнең атасы.

Шәех Әүлияр — шаһзадә, Шаһгалинең атасы.

Габдулла — бәк, Мөхәммәд Әмин хан илчесе.

Бүзак — бахшы (сәркатиб, елъязмачы), илчелек сәркатибе.

Миңле Гәрәй — хан, Кырым тәхетендә.

Мөхәммәдшаһ Мәмәшев — илче.

Габдулла углы Шәехзадә — илче.

Шәех Габделхәер углы — илче.

Касыйм — Хуҗа Мөхәммәд углы, бахшы сәркатиб.

Шаһ Хөсәен — илче.

Әхмәт Гәрәй — шаһзадә, Кырым ханы Миңле Гәрәй углы.

Асылхуҗа Маҗанов — тархан.

Хәсән — Асылхуҗа тархан углы.

Колдәрвиш — сәйед.

Хәбиб Хаҗи — илче.

Булат Ширин — карачы.

Шаһ Йосыф — бәк, илче.

Моллан — шаһзадә, илче.

Дәүләт Гәрәй — шаһзадә, Кырым кешесе.

Хаҗи Гәрәй — хан, Кырым тәхетендә.

Дәүләтьяр — шаһзадә, Кырым.

Хызыр — шаһзадә, Кырым.

Котлызаман — шаһзадә, Кырым.

Килдәш — шаһзадә, Кырым.

Ямгырчы — шаһзадә, Кырым.

Үзтимер — шаһзадә, Кырым.

Мөхәммәд Гәрәй — хан, Кырым.

Борнаш — шаһзадә, Кырым.

Фатих Гәрәй — шаһзадә, Кырым.

Сәгадәт Гәрәй — шаһзадә, Кырым.

Мөбарәк Гәрәй — шаһзадә, Кырым.

Аккүбек — хан, Әстерхан.

Аталык — бәк, батыр, 1530 елгы сугышта



шәһит китә.

Ватучы Кочле — батыр, гаскәр башлыгы, Казан

Аппак — углан, илче.

Бәхеткилде — бәк, илче.

Терегол (Терек угыл) — бәк, атаклы Терегуловларның нәсел башы.

Тагай — бәк, илче.

Төүгил — бәк, илче.

Ибраһим — бәк, илче.

Танай — бәк, илче.

Данай — бәк, илче.

Ибраһим — бахшы, илчелек сәркатибе.

Табай — бәк, илче.

Апай Углан — илче.

Тукыл — бәк, илче.

Багыш — илче.

Гали Шөгыйль углы Раст — бәк.

Колчура — бәк, илче.

Фируззат — илче.

Шаһ солтан — ханша, Шәех Әүлиярның хатыны, Шаһгалинең, Җангалинең анасы.

Бибай — бәк, Җангали илчесе.

Борнак — бәк, Җангали илчесе.

Ислам Гәрәй — шаһзадә, Кырым.

Ходаяр — шаһзадә.

Хуҗа Хөсәен — Бабур солтанның Василийга илчесе.

Урак — Булат углы, илче.

Чабык — бәк, илче.

Хаҗи Фәрһад — илче.

Бекка — бәк.

Исәнкилде — илче.

Габдрахман — бәк.

Ишми — бәк.

Бараш — илче.

Төүкил — Мортаза углы, батыр.

Хәмәт Шәех — илче.

Боерган — сәйед.

Габдулла — бахшы.

Илзаман — бәк.

Хөсрәү — бәк.

Җуҗа Бирде — бәк.

Мәмәш Хафиз — бәк.

Адаш Галикәй — мирза.

Колчура Чапкын.

Борнаш Чапкын.

Кәбәк — бәк.

Ислам — мирза.

Әбәкче — мирза.

Ханкилде — мирза.

Шаһчура — мирза.

Бикчура — мирза.

Колыш — бәк.

Байтул — мирза.

Ватай — мирза.

...атын бел

Агиш — бәк, Җангали илчесе.

Ялтәк — бахшы.

Кодай углан — илче.

Хуҗахмәт — бахшы.

Шайдак — мирза.

Дәрвиш Гали — бәк, илче.

Баем — мирза, илче.

Колехмәт — илче.

Гәүһәршад (Хөршидә) — хан кызы, Булат бәк Ширинның хатыны, карачы. Нургалинең анасы.

● Кол Шәриф.
Рушан ШӘМСЕТДИНОВ рәсеме.

Чура Кадыш — илче.

Дивай — мирза, илче, Сәхип Гәрәйнең Иванга илчесе.

Бакый — илче.

Бахшанды — илче.

Аллабирде — илче, Апай углан углы.

Хуҗан — илче.

Мамай — бәк.

Конырчы — бәк.

Уразлы — илче, бәк.

Ындырчы Хафиз — илче.

Мансур — сәед.

Байсоңгар — Юныс мирзаның Дүртенче Иванга илчесе.

Руби — Булат бәк углы.

Расыф — бәк.

Хастүрә — бәк.

Колыш — бәк.

Чура Нарыков — атаклы бәк.

Баһү — бәк.

Азик батыр — сугышта һәлак була.

Арак батыр.

Юлбарыс Раст углы — илче.

Даниян — Мөхәммәд углы, илче.

Мәмәзар — батыр, Муром сугышында шәһид китә.

Шәех Мамай — әмир.

Касай — мирза.

Канбәй — мирза.

Би — мирза.

Байтимер — илче.

Курат — мирза.

Тулыбай — бәк.

Баранча — мирза.

Байкилде — мирза.

Намаз — мирза.

Кәнтуган Хафиз.

Белүк Булат — мирза.

Арслан — мирза.

Иделчура Хаҗи — илче.

Илиман — илче.

Кушай — илче.

Атай — мирза.

Тайлак — мирза.

Дулатъяр — илче.

Килдавыр — илче

Мөхәммәд Беззубов — илче.

Аккүбек Тугаев — илче

Төмән — бәк, илче

Бибарс Растов — илче.

Касыйм — Казан мулласы, шагыйрь, илче.

Ходайкол — углан, илче.

Аңкилде абыз — илче.

Кошчак — углан. Чукынырга ризалык бирмичә, шәһит китә.

Акмөхәммәд — углан, Казан өчен сугышып үлгән кырымлы батыр.

Гали Мәрдән Хаҗи — илче.

Ишем — илче.

Колай — мирза, Растов мирза углы, илче.

Кадыш — бәк, Карамыш — бәк, Колгали — бәк, илче. Өчесе дә Шаһгали тарафыннан суела.

Шамса — бәк.

Ислам — бәк, батыр, Казан капкаларын бикләтүче кеше.

Күбәк — бәк, батыр.

Лиман (Әлиман) — бәк.

Чура Кадиев — бәк.

Богдан — Арча бәге.

Шаһчура — батыр.

Шамай — бәк, батыр.

Ибраһим — мирза, Йосыф углы, нугай.

Илморза — Йосыф углы, нугай

Котым — мирза.

Сәеш (Сиваш) — Илморза углы, мирза.

Баймирза — Илморза углы.

Баримирза — Гали мирза углы.

Чалбәк — Казан өчен сугышта һәлак була, Кырым кешесе.

Ядкәр Мөхәммәд Касыйм углы — шаһзадә, Казан ханы.

Янчура — мирза.

Канбирде — Кырым шаһзадәсе.

Дәүләт Гәрәй — хан.

Кол Шәриф — сәйед, илче, шагыйрь. Сугышта һәлак була.

Зәйнәш — бәк, әсир төшә.

Япанчы — мирза, атаклы баһадир.

Яуш — Арча бәге.

Шонак — мирза, батырларча һәлак була.

Отуч — дин әһеле булырга тиеш, «Отуч» мәчете булган.

Илекмән — күрәсең, мәшһүр шәхес, аның исеме белән Казанның иң биек манарасы аталган булган.

Исмәгыйль мирза — Сөембикә ханшаның агасы.

Сөембикә — Йосыф әмир кызы, канча.

Үтәмеш — ханзадә, хан. Сафа Гәрәй хан углы.

Нургали Булат бәк Ширин углы — карачы.

Илбога — бәк, Казанның бер манарасы, бер капкасы аның исемендә булган.

Шимай — бәк, Арча түрәсе.

Кубыш — бәк, Арча зыялысы.

Әкрам Гали — хан, Сөембикәнең энесе.

Сөембикәнең агасы Исмәгыйль мирза углы Динәхмәтнең кызлары:

Ханзадә ханым,
Лап тутай,
Алатык тутай,
Тугай тутай,
Болым тутай,
Дивай тутай,
Багым тутай,
Исән тутай,
Шөгер тутай,
Котлы тутай,
Татлыбәк тутай,
Сөен-бәк тутай.

Динәхмәт мирзаның хатыннары:

Хантай ханым,
Низәк ханым,
Малга-Орын ханым.

Үрмөхәммәт — мирза.

Илсыман — бәк, илче.

Күчем — хан.

Сүзгә — ханбикә, Күчемнең хатыны. Урыс юлбасары Ермакка әсир төшмәс өчен үз-үзен хәнҗәр кадап үтерә

Рабит БАТУЛЛА әзерләде.

МӘДӘНИ ҖОМГА

Роза ТУФИТУЛЛОВА:

Хатын-кыз табигатен бозу — атом бомбасын уйлап табудан куркынычрак

— Хөрмәтле Роза ханым, Сез менә дөньяның күп илләренә тарала торган мәшһүр «Сөембикә» журналының баш мөхәррирәсе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисенең урынбасары, Бөтентатар хатын-кызларының «Ак калфак» берләшмәсе президенты да булып торасыз. (Ходаем, ничек житешергә кирәк боларның барысына да!) Кайчан, ничек барлыкка килде бу «Ак калфак» дигән берләшмә? Аның чишмә башы каян башлана?

1991 елның июне «Азатлык» радиосыннан килгән Фәридә Хәмит белән бергә әлеге радионың Казандагы хәбәрчесе Римзил Вәлинең төзелеп бетмәгән дачасында. Идел буенда учак ягып ятабыз.

Хәзер сез икегез татар хатын-кызларының ике кыйтгасыннан вәкил булып торасыз, дип шаярты Римзил. – Инде сезгә аларны берләштерергә кирәк

Шушы уеннан уймак чыкты бит! Бөтендөнья татар конгрессында хатын-кызлар секциясе юк иде. Мансур Хәсәнович Хәсәнов Премьер-министрның беренче урынбасары иде. Аңа кердем. Шушы ихтыяҗ турында әйткәч, тәкъдимемне белдердем:

- «Хатын-кыз, милләт, гаилә» дигән темага сөйләшү билгелик, – дидем.

ны? Минемчә, шулай кирәктер ул!

Елена Рерих әйтмешли, дөнья сыңар канатында гына, ир канатында гына оча, шуңа күрә һәлакәткә бара. Аңа пар канатлар кирәк. Ә монда хатын-кыз

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАШ

Мин үзем көнбатыш хатын-кызының бөтен сы... ларын да кабул итә алмыйм. Аларда ничек тә ... өскә чыгарга тырышу омтылышы бар, ә без ... вакытта да ирләр белән тигез була алмыйбыз... че төрлерәк әйткәндә, алар белән бер төсле ... алмыйбыз. Әдәп, әхлак сыйфатларын без ... көнчыгыштан алганбыз. Безнең фәлсәфәбез ... рәктер, без ниндидер бер урталыктабыздыр ... тосла миңа. Көнчыгышка тигезлек, пар канатл... хас.

— ... Ә безнең парламентта нибары өч татар ... тын-кызы...

- Дәүләт дәрәҗәсендә уйлый ала торган ... әзерлекле хатын-кызларыбыз бар бит безнең ... ламентыбызда өч кенә хатын-кыз булуы бер ... ителә торган хәл түгел. Ә бик күп илләрдә ... ле хатын-кызларны дәүләт эшенә тартуга ... җитәкчеләренең хатыннары булыша. Төркиянең ... рхүм президенты Тургут Озалның хатыны шу... лардан. Ул җитәкләгән оешма ярлы гаилә... гимназияләргә шефлык итә. Бездә дә олы җ... челәребезнең хатыннары шул юлдан барсын иде...

Көнбатышта көнкүреш мәсьәләләре тиешле ... рылыкка куелган. Андагы хатын-кызның үзен ...

— Өстегезгә аласызмы? — дип сорады Мансур Хәсәнович.

- Алам! Конгрессның бурычы — татарны барлау Тудыручысыннан башка ничек барлыйсың аны!

Секциядәге сөйләшүдә Австралия, Америка, Төркия, Финляндия, Германия, Япония, Украина, Үзбәкстан, Мәскәү, Ленинград вәкилләре катнашты. Шунда татар дөньясын нык белүче гаҗәеп көчле хатын-кызлар ачылды.

Шушы сөйләшү бөтен сөембикәләр өчен яңа офык ачты, кысылып яшәвебезгә, изелүебезгә гаҗәпләндек, хәйран калдык. Болай яшәп булмый! — дидек Гыйффәт туташларга, киленбикәләргә багышланган кичәләр шуларның балалары инде.

Сөйләшүдә катнашкан кешеләрнең исәбен алдылар. Башка секцияләр эшендә 30-40 кеше катнашса, безнекендә 386 кеше булды. (Бу турыда хәтта йомгаклау утырышында әйттеләр). Шунда инде милләтнең язмышы хатын-кыз кулында икәне, аны саклау хатын-кыз җилкәсенә төшкәне ачыкланды. Инде хатын-кызлар берләшмәсе тумый кала алмады, чөнки анда сөйләшкән сүзләрне гамәлгә ашырыр өчен оештыру үзәге кирәк иде.

Берләшмәгә «Ак калфак» дип исем куштык. Аның – Казанда һәм Хельсинкида – ике үзәге барлыкка килде. Хельсинки үзәгенең җитәкчеләре Фәридә Хәмит (Германия) белән Фәридә Низаметдин (Финляндия) булды. Алар күп сөйләнмәделәр, эшләделәр. Без Казанда оештырган балалар бакчасына һәм татар кызлар гимназиясенә матди ярдәм күрсәттеләр. Бу эшкә Америкадан Шәмсия Апакай, Төркиядән Сәйдә Арсланбәк килеп кушылды. Америкада, Төркия, Германия, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең дә матди ярдәме тиде. Алар безгә омтылалар, ярдәм итәргә тырышалар.

— Ничек ул, Казанда гына хәрәкәт итәме сезнең бу берләшмә?

Республикабызда безгә карата район хакимияте башлыклары илтифатсызрак булдылар, оештыру эшенә теләр-теләмәс кенә ризалаштылар. Ни өчен татар гына берләшә, имеш. Ә менә Азнакай, Аксубай, Кукмара, Лениногорск районнарындагы хатын-кызлар үзләре бик зур активлык күрсәттеләр.

Еракка китеп кара, диләр бит. Мин Русия өлкәләрендә күп йөрдем. Мәскәүдә, Киевтә, Ырынбурда, Минусинскида (Краснояр крае), Вильнюста (Литва) хатын-кызларның бик көчле оешмалары эшли. Чеп-чи урыс өлкәсе Ивановода 1993 елдан бирле «Ак калфак» оешмасы, Омскида ике оешма - «Ак калфак» һәм «Зәңгәр шәл», Ташкентта көчле оешмалар эшләп килә. Читтә безне артыграк зурайталар кебек тоела миңа, безгә зур өметләр баглыйлар, Казанга ышанычлары зур. Миңа хәтта кайчакта уңайсыз булып китә.

Татар бар, татар яши һәм яшәячәк!

— Мәсләге нидән гыйбарәт инде сезнең берләшмәнең, тоткан юнәлеше?

Без хатын-кызның хәл-хәятен яхшырту максатын куябыз, татар халкын саклап калу кебек изге гамәлләребезне зур сәяси трибунага күтәрергә тырышабыз. Хатын-кызның учакны сүндермичә тотучы, милләтне яшәтүче көч икәнен халкыбызга аңлатырга омтылабыз.

Рухи байлыкны – гореф-гадәтләрне, гаиләнең борынгыдан килә торган кадерле әйберләрен саклау, телне саклау - хатын-кыз өстендә.

Менә хәзер безнең хатын-кызлар съезды әзерләнә. Монда сүз тагын шул хатын-кызны социаль яклау турында барачак. Ветераннарны социаль яклаган кебек, хатын-кыз ветераннар рәтендә йөрергә тиешмени?! Хатын-кызны ничек якларга, кыргый базардан ничек сакларга, диләр. Кыргый базар бетәр ул бер. Изге гамәлләрне аяк астына салып таптаган җәмгыятьтән сакларгамы әллә хатын-кыз фикерен санга сукмау, аны икенчел даирәләрдә генә куллану хөкем сөрә.

— Чит илләрдәге хатын-кызлар оешмалары белән бәйләнешләрегез ничек, аралашасызмы?

- Дөньядагы күп кенә хатын-кызлар оешмалары белән аралашабыз. Күптән түгел безгә килгән Бөтенливан хатын-кызлары ассоциациясе генераль секретаре Нәдә Мөэзин Әюби, милләт генофондын саклауга омтылуыбызны күреп, шаккатып китте.

Ә менә Төркиядә хатын-кыз оешмалары гаиләләргә, аерым балалар йортларына шәфкать итү белән генә шөгыльләнә.

1993 елның августында Анкарада төрки халыклар хатын-кызларының конференциясендә татар хатын-кызларының милләтне саклаудагы роле турында чыгыш ясарга туры килде миңа. Текстсыз-нисез, йөрәктән чыкканын гына сөйләдем. Чыгышымны бик җылы, озакка сузылган алкышлар белән кабул иттеләр. Сөйләгәннәремне турыдан-туры Сәйдә Арсланбәк тәрҗемә итте. Уңышлы булуы бәлки шуннан да торгандыр.

Әлеге конференциядә Бакудан, Алматы, Дагстан, Югославия, Болгария, Босния, Америка, Германиядән, башка җирләргә таралып яшәүче төрекләр бар иде. Шунда мине төрки халыклар хатын-кызлары берләшмәсенен шурасына әгъза итеп сайладылар. Ә төрек хатын-кызлары берләшмәсенең генераль секретаре Айсели Гүксойны без төрки халыкларның хатын-кызлары берлегенең президенты итеп куйдык.

Безнен илдә сәясәт тирәсендә йөрүче хатын-кызларыбызның әзерлекле икәнен танырга мәҗбүр булдылар анда. Төрки халыклар хатын-кызлары берлегенең штабын Казанда булдырыргамы әллә, дигән фикерләр дә әйтелде. Андый мәсьәләне хәл итәргә вәкаләтем юк иде, хәзергә Төркиядә торып торсын әле, дидек.

— Катнаш никахларга карашыгыз ничек сезнең, Роза ханым?

Катнаш никахларны мин бездә хатын-кызга игътибар җитмәүдән килеп чыга дип исәплим. Бездә чит милләткә китә дип хатын-кызны гына гаепләү алга сөрелә. Ә ник китә соң ул, дигән сорау куелмый. Ник җибәрәсез, дияр идем мин.

Аяз абый Гыйләҗев бер мәкаләсендә милләт язмышы хатын-кыз кулында, яшь кызлар кулында, дигән иде. Минем шуңа болай дип өстисем килә: бала ана карынында чакта ук формалаша, ә кимсетелгән, изелгән хатын-кыздан горур кешеләр туа алмый!

— Әйткәнегезчә, сез төрле кыйтга хатын-кызлары белән аралашасыз. Шәрык белән гарәп хатын-кызлары арасында нинди дә булса аерма күрәсезме?

- Кызыклы сорау. Бу бик катлаулы мәсьәлә мине уйландыра иде, Саимә ханым. Мәскәүдә «Хатын-кыз һәм экология» дигән Халыкара конгресста чыгыш ясаганнан соң мине Мисыр илчелегенә чакырдылар. Татар хатын-кызы үзен ни дәрәҗәдә шәрык хатын-кызы итеп саный ала дигән бәхәс булды. Мин «ир - баш, хатын - муен» дигән фәлсәфә белән чыктым. Алар безне шәрыктән читләшкән, урыслашкан дип уйлыйлар. Сөембикә ханбикәгә шаккаттылар. Ханыбызның хатын-кыз булганын белмәгәннәр. «Ир - баш, хатын - муен» дигән сүздә галәмәт зур мәгънә ята. Күп очракта мин татар хатын-кызының сабырлыгына сокланам. Бу — басынкылыктан түгел, кирәк җирдә юл бирә белүдән. Халыкның холык-фигыленнәндер ул.

Көнбатыш хатын-кызлары элек тә киләләр иде безгә, хәзер дә киләләр. Мәсәлән, 1994 елда безгә Германия хатын-кызлары федераль берлеге әгъзалары килде. Быел үзем Германиянең Тюрингия дигән җирендә булдым. Анда хатын-кызлар хакимияттә урын өчен, хатын-кызлар тигезлеген танучы законнар чыгарту өчен парламентларда җан-фәрман көрәшәләр. Инде зур уңышларга да ирешкәннәр. ...рга да, ял итәргә дә, башкасына да вакыты ... Алар безнең кебек изелмиләр.

Районнарга чыкканда мин бала табу йорт... карыйм. Ишелеп таралырга җиткән бинала... бит республиканың киләчәгенә мөнәсәбәт ... сүз!..

Туниста (хатын-кызлар милли шурасының ... — Нәзиха Мәсхүдә), Ливанда, мәсәлән, яшь ... өчен тел буенча курслар оештырыла. Бездәге ... теле кебек, аларның да телләрен инглиз теле ... китә язган. Курсларга йөрмәсәләр, декрет акча... түләнми. Анда иң кадерле кеше — күп балалы ... Демография мәсьәләсе — изге гамәл. Бала ... саен акча арта. Бу инде — уйланылган дәүлә... ясәте! Бездә исә ана булу вазифасы гомумән ... мый. Курслар оештыру кебек нәрсәләр турында ... дә йөртеп булмый.

Көнбатышта да хәзер бала табу бик нык ... гән. Һәм менә мин барып кайткан Тюрингия ... җәһәттән күп төрле кызыксындыру чаралары ... чыгарылган.

2000 нче елга безнең җәмгыятебезнең пенсио... лар җәмгыяте генә булып калу куркынычы ... (Аны, «Бетәбез бит, җәмәгать...» дип, гәзит... сез дә яздыгыз). Ә шушы җәмгыять өчен кый... ләрне кем тудырыр?

— Сезгә бу тынгысыз, мөбарәк эшегездә хак... ят кешеләреннән, җитәкчеләрдән ярдәм итүче б... мы?

— Аерым, олырак чаралар үткәргәндә бу... лар, әлбәттә. «Гыйффәт туташ» кичәсен әзер... дә, мәсәлән. Ә болай, көндәлек эштә азрак ... Аның каравы Жириновский әфәнде ярдәм ... сузды миңа! (Роза ханым шулай әйтте дә ... ләнеп көлеп җибәрде. – С.И.). Госпожа Туф... лова дип язган ул миңа. Хатын эчтәлеге ... төрки халыклар арасында иң хөрмәт иткәнем – ... тар халкы, ә сез шушы халыкның гүзәл бер ... тәшкил итәсез. Шуңа күрә хатын-кыз мәсьә... мин үземнең киләчәк эшемдә төп мәсьәлә... берсе итеп куячакмын. Безгә бер тирәдә бу... кирәк. Мин сезне хезмәттәшлек итәргә чакы... Риза булган сурәттә сезне теләсә кайсы өч ... чыгаруны үз өстемә алам, дигән... Ә үзен бер ... дә кертмиләр!

Ә менә быелның сентябрендә Кытайда IY Бөт... дөнья хатын-кызлары конгрессы булды. Яшерм... катнашасым килгән иде бу форумда, чөнки ан... мөнбәреннән әйтер сүзләрем дә, фикерләрем дә ... иде. Шунда җибәрүләрен сорап, кат-кат мөрәҗ... итеп карадым, югыйсә...

— Сезнең йокыгызны качырып уйландыра тор... нәрсәләрне ишетәсе килә...

— Без, хатын-кызлар, күбрәк булдыра ал... бит, безнең кулдан зуррак эшләр дә килә. А... яклау табылсын иде. Заманыбыз да инде шу... — ир-егетләребез үзләре дә югалып калган ... Гасыр бетә, меңьеллык тәмамлана, җәмәгать! ... ясәтчеләребез уйлансын иде ... нәрсәгә ирешт... әле без, дип. Хатын-кыз табигатен бозуга ир... Ул атом бомбасын уйлап табудан да куркыныч... Хатын-кыз логикасына карата бүген дә мыск... караш яши. Ни өчен әле ул ир кеше төсле уй... тиеш?! Ә бездә шундый булса гына хатын-кыз ... лы санала.

Хатын-кыз логикасы дигәннән, ул әледән-ә... тына борылып карый, анда җаваплылык хисе ... чөнки артыннан баласы, ата-анасы килә. Ана ... хисе — начармы әллә!! Ә безнең хакимнәребе... нәкъ менә шул артка борылып карау җитми дә... Хатын-кыздан ир ясау дигән авырудан коты... инде XXI гасырда! Ул чагында «Ак калфак»ның ... шы игелекле эшкә өлеше кергән дип санарга ... кин булыр иде.

Әң...

Саимә ИБРАҺИМОВА оешты...

Каз канаты каурый-каурый, хатлар язарга ярый

Укучылар даирәсен киңәйтергә мөмкин

«Мәдәни җомга»ны кызыксынып карап барам уңышларыгызга чын күңелдән куанам Миңа калса газетагыз камилләшә көннән-көн яхшыра бара Концепциягез әйбәт Укучыларыгыз даирәсен киңәйтү турында да уйланырга кирәктер Моның өчен татарчадан урысчага тәрҗемә ителгән тарихи дөрес яктыртылган материаллар бастыру урыс мәктәбен тәмамлаган укучыларга да барып ирешсә файдасы тияр иде

Үзбәк ӘХМӘРОВ.
Казан

Киләчәгебез — иманлы яшьләр кулында

Кайбыч районы үзәк китапханәсендә түгәрәк өстәл артында яшьләр җыены булып узды.

Яшьләр белән очрашуга районыбыз хакимияте башлыгы А.Ханифатуллин, аның урынбасарлары Р.Малова, Х.Булатов, Җ.Гаффаровлар килгән иде.

Азат әфәнде шушы болгавыр заманда адашмыйча ничек дөрес юлдан бару, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык, татулыкны саклап калу, әби-бабаларыбыз гореф-гадәтләрен дәвам итү турында яшьләргә үзенең киңәшләрен бирде. Аның йөрәгеннән чыккан эчкерсез сүзләре яшьләрне битараф калдырмады.

Яшьләребез белән очрашуга килгән авылыбыз аксакаллары Русиядә һәм республикабызда оешып эшли башлаган, яшьләр аңын агулаучы төрле секталарга карата үз фикерләрен әйттеләр. Яшьләрнең дә бу дини оешмаларга тискәре карашта торулары ачыкланды.

Район үзәгендә яшьләрнең күзгә күренеп арта баруы безнең өчен зур шатлык та һәм зур җаваплылык та. Яшьләребез буш вакытларында төрле секталарга йөреп агуланмасыннар, ә сәламәт тормыш юлы сайласыннар өчен район үзәк китапханәсе төрле кызыклы чаралар — әдәби-музыкаль кичәләр, конкурслар оештыра.

Яшьләр түгәрәк өстәлдән киләчәккә якты өмет һәм ышаныч белән таралыштылар.

Ф.БАТТАЛОВА,
Кайбыч балалар китапханәсе китапханәчесе.

«Хәтер» китабының хәле ничек?

Бөек Ватан сугышыннан кайта алмаган ватандаш каһарманнарыбызның исемнәрен теркәүче, булганнарының фоторәсемнәрен дә урнаштыручы «Хәтер» китабы Татарстаныбызда да басылып чыга. Инде минем үземдә республикабызның унбиш район китабы бар.

Хәтер китабы нәшриятын яшьләр коллективы дип атасак та бик гадел булыр Эзләнүләр аша, төрле архивларга мөрәҗәгать итеп, төрле юллар белән җыйдылар алар мәгълүматларны. Үтә кысан бүлмәләрдә, ял вакытларын да онытып эшләделәр ул балалар. Әле узган елда гына нәшриятның бер хезмәткәре, шушы көнгә кадәр республика бюджетыннан акча бирелмәде, — дип язган иде. Акчалата ярдәм итүчеләр «Хәтер» китапларының барлык томнарында да күрсәтелгән. Күрше республикаларда һәр районнан берәр кеше бюджет хисабына «Хәтер» китабы нәшриятында үз төбәкләре буенча эшлиләр. Украина районнарында да шундый ук хәл, бу изге эшкә битараф булмаганнар җитәкчеләр.

Мин үзем дүрт йөзгә якын мәрхүмнәребезнең мәгълүматларын теркәп «Хәтер» китабы нәшриятына тапшырдым. Анкеталар төзеп, бланкларын бушлай эшләп бирделәр хәерле бәндәләр Шуларның ике йөз илледән артыгы үзем туган төбәктән, калганнары шәхси архивымнан һәм эш дәверендә миңа мөрәҗәгать иткән кешеләр — мәрхүмнәрнең якыннары, яшьтәшләре һ.б.лардан. Балтач районы җитәкчеләре, хезмәтемне искә алып, бүләген дә бирде Кенәбаш авылы сугыш һәм хезмәт ветераннарын хөрмәтләү бәйрәменә мине дә чакырды.

«Хәтер» китабы чыгарылачагы хакында моннан өч-дүрт ел элек республикабыз һәм районнарыбыз газеталары язган иде

Инде басылып чыгып халыкка таратылгач, китапка керми калган яки исән кайтып, китапка үлгән булып теркәлгәннәр хакында язылган хатлар килә хәзер Берсе Президентыбыз исеменә язылган Ул чара күрмәсә Русия Президентына мөрәҗәгать итәчәге хакында бәян иткән.

Үз районы «Хәтер» китабына исемнәре теркәлмәгән мәрхүмнәрнең барысы да диярлек сугышка башка район хәрби комиссариатлары аша киткәннәр һәм шул район «Хәтер» китабына теркәлгәннәр Андыйлар Балтач районында да йөздән артык

Исемнәре беркайда да теркәлми калганнары да бар Бу хәл нәшрият коллективы гаебе белән түгел. Югарыда әйткәнемчә һәр районнан бер кеше җибәрергә иде нәшриятта эшләү өчен Аның хезмәтенә түләгән акчадан гына район бюджеты какшамас иде Алар үз районнарындагы һәр авылдан алырлар иде мәгълүмат-исемлекләрне

Исемнәре теркәлмәгәннәре өчен республика күләмендә соңгы бер китап — җыентык басылачак Бу хезмәтне үтәү бурычын Балтач районы буенча үз өстемә алам ә мөрәҗәгатемә ничек карарлар тагы

Хәбибрахман ҺАДИЕВ,
сугыш ветераны

Тел сөйләр өчен генә түгел!

Мәрхабә, хөрмәтле «Мәдәни җомга»! Хуш килдең мәйданга! Синең белән язышырга сүз бирәм һәм беренче хатымны юллыйм.

Нигә опера һәм балет театры артистлары, Камал театры артистлары кебек, балалар өчен балет яисә опера куймыйлар, яшь буын турында кайгыртмыйлар?

Татар композиторларының балалар өчен язылган әллә ничә операсы, балеты куелмый ята бит Тамашачылар да бүген инде җитәрлек булыр иде, шөкер, татар гимназияләре, мәктәпләр ачыла тора, һәм балаларга курчак театры гына түгел, балет-опералар да кирәк, тел сөйләр өчен генә түгел, җырлар өчен дә, җырлап та ачыла ул. Шулхәтле тырышлык белән татарны, аның сәнгатен мөсхәрә итү бара опера театрында, опера куелмагач, либретто язарга да кирәкми, язучылар да, татар композиторлары да кирәкми икән булып чыга. Үз операңны куя алмау җыр сәнгатенә дә бик каты китереп суга. арияләр дә җыр бит, әллә татарча җыр күбәюдән куркалармы соң?

Рауза ВӘЛИЕВА,
биоэнергосенс.
Чистай

Талантның кадерен белик

Атаклы опера җырчысы Азат Аббасовны белмәгән, яратып тыңламаган кеше сирәктер Көчле чыңлы тавышлы мәһабәт гәүдәле бу олы артистыбызга быел октябрь аенда 70 яшь тула СССРның халык артисты дигән мактаулы исемгә ия булган Азат Аббасовның юбилее да башка күренекле сәнгать әһелләребезнеке кебек үк югары дәрәҗәдә узар иншалла Халык җырларын да оста башкаручы опера сәхнәсе йолдызын без телевизордан күребез радиодан ишетербез Әмма болай эшләү генә җитми минемчә Республиканың сәнгать бәйрәме булсын иде гөрләткән сәхнәдән туры трансляция ясап ул бәйрәмне телевиденец күрсәтсен иде бу бәйрәмне Мәскәү телевидениесенә тәкъдим итсеннәр иде Аның кыскартылган вариантын чөнки Русиядә дистә миллионга якын милләттәшебез яши Азатның да олы талант иясен күрергә ишетергә хаклары бар Татар үз талантлары белән горурлансын сәнгатькә хөрмәт артсын өчен дә кирәк ул Бигрәк тә бүгенге авыр заманны җиңеләк үтәр өчен

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.
Азнакай шәһәре

ҖАВАП - САВАП

? ***Әти белән әни аерылдылар. Әти үлем хәлендә ята. Әгәр аның белән ул-бу булса, мирас кемгә кала?***

К.Әхтәмов.

Әгәр гаилә башы алдан ук васыятен калдырган булса, мирас васыяттә искә алынган кешеләргә кала Мирас бүлгәндә закон буенча тигез өлеш беренче чиратта балаларга (шул исәптән уллыкка алынганнарга да) тия. аннары вафат булган кешенең әти-әнисенә (уллыкка алып тәрбияләгән кешеләргә дә) һәм хатынына (иренә) вафат булган кешенең туганнарына, әбисенә һәм бабасына (һәр ике якның да әби-бабасына) өлеш чыгарыла.

Икенче чираттагы мираска хакы булганнарга мирас бары тик беренчеләр исән булмаса яки мирастан баш тартса гына бирелә Монда шундый хокук та каралган әгәр вафат булган кеше турыдан-туры мирас алырга хаклары булган кешеләрне (беренче чираттагыларны) васыятендә мирастан мәхрүм итсә мирас икенче чираттагыларга калдырыла.

Вафат булган кешенең үләреннән бер ел алда аның тәрбиясендә (иждивениесендә) яшәгән хезмәткә яраксыз туганнары, якыннары да мирас алуга хокуклы

Мирас калдыручының оныкларына да (васыять көгазен ачканда аларның әтисе яки әнисе инде исән булмаса) мирас тия Монда шунысын да искә төшерергә кирәк уллыкка алынган кешегә һәм аның балаларына үз әти-әниләре яки туганнары вафатыннан соң мирас алу каралмаган

Хат язучының соравына җавап ачык һәм кыска. закон нигезендә аерылган ир яки хатынның мирас алырга хокуклары юк

«ОКО» юристлар агентлыгы.

? ***13 яшьлек бала әнисе фатирында пропискада тора. Әнисе вафатыннан соң бала торак мәйданын югалтмыймы? Югалтмасын өчен нинди шартлар кирәк? Фатир әле хосусыйлаштырылмаган.***

Ә.Садыйков.

Бала торак мәйданын югалтмый Әнисе вафатыннан соң балага опекун билгеләп, аны нотариуста рәсмиләштерү кирәк

? ***Кооператив юлы белән төзелгән фатирны хосусыйлаштырырга ярыймы?***

Д.Сәгыйтов.

Мондый фатирны хосусыйлаштыруның кирәге юк

? ***Миңа кибеттә алган товарны алмаштырып бирүдән баш тарттылар. Эленеп торган язуны нигез итеп күрсәттеләр. Анда: «Сатылган товар алмаштырылмый һәм кире алынмый», дип язылган. Нишләргә соң инде?***

П.Долгова.

Сатып алучы ниндидер сәбәп аркасында товарын ошатмаса, әйбер һәр очракта диярлек кибеткә кире алынырга тиеш Хәтта сатып алучы «Куллланучыларның хокукларын яклау» турындагы РФ законы белән хәбәрдар булмаса да, кибет хезмәткәрләре үз эшләрен яхшы белергә бурычлылар Кибет товарны берсүзсез кире кабул итәргә алмаштырырга тиеш Әлбәттә товарга акча түләнү турында касса чегы булса

Татарстан Кулланучылар хокукын яклау җәмгыяте.

Кадерле укучым! Югары Ослан районының Берек авылында яшәгән каенатамның архивыннан килеп чыккан кечкенә генә бер китапчык мине хәйран калдырды. Башта мин аны берничә дустыма биреп укытып алдым. Аларның һәрберсе әлеге басманы кичекмәстән татарчага тәрҗемә итәргә, үзебезнең укучыларга да җиткерергә киңәш кылды.

Татарстанда уздырыла торган Хәтер көннәре аларның бу искәрмәсен яңартып җибәрде. Тәвәккәлләдем. Китап, СССР халыкларын алып исәпләгәндә, бик кечкенә тираж белән, нибары 10175 данәдә дөнья күргән. Ул кеп-кечкенә татар авылында яшәп яткан каенатам Барый Ганиев архивына ничек эләккәндер, анысын белмим.

Бу — әлеге язманың өченче басмасы икән инде. Аны 1934 елда СССР Фәннәр академиясе нәшрияты Ленинградта бастырып чыгарган. Калганы язманың үзеннән аңлашылыр. Аның бары фәнгә генә кагылышлы өлешләрен сезгә тәкъдим итәм.

Кояш ТИМБИКОВА.



Альберт ШЛИХТИНГ

Явыз Иван дәверендәге

Кереш

Әлеге «Кыйсса»ның килеп чыгышы беренче тапкыр «Русия һәм Италия» дигән җыентыкта (1913 ел) профессор Е.Шмурло тарафыннан җентекләп тикшерелгән һәм ачыкланган. 1570 елда папа Пий V һәм Венеция республикасы Мәскәү патшасын төрекләргә каршы берләшмәгә кертергә телиләр. Үзара сөйләшүләр алып бару өчен поляк кешесе Портико сайлана. Әлеге кеше инде Мәскәүгә чыгып китәм дигәндә генә Польшага Мәскәү әсирлегеннән котылып чыккан Альберт Шлихтинг кайтып төшә һәм ул, әүвәл телдән, соңрак язма рәвештә урыс патшасы Иванның коточкыч холыксызлыгы турында бәян итә. Портиконың Мәскәүгә бару теләге сүнә. Ул әлеге Шлихтинг язмасын Римга, Сигизмунд Августка җибәрә. Аны укып барысы да хәйран калалар. Папа Пий V бу хакта Портикога болай дип яза: «Без Мәскәү государе турында язганнарыгыз белән таныштык: анда бару турында бүтән баш ватмагыз. Сезнең сәфәрне хәтта Польша короле хупласа да, без андый варварлар һәм кыргыйлар белән ниндидер уртаклык эзләүдән баш тартачакбыз». Шул рәвешле Мәскәү белән сөйләшүләр булмый кала.

Шлихтингның бөтен католиклар дөньясын шаккатырган хәбәрләре Портиконың Ватикан архивындагы язмалары арасында сакланып калган... Тарих-археография институты Шлихтинг нотыгының күчермәсен Римнан алдырган. Әлеге язма — шуның тәрҗемәсе. «Кыйсса»ның авторы турында аерым мәгълүматлар юк, бу хакта язманың эчтәлегеннән чыгып кына аңларга мөмкин. Ул урыслар кулына Литва крепосте Озерищены басып алганда, 1564 елның 6 ноябрендә әсир төшкән. Померааниядә үскәнлектән, немец һәм урыс-славян телләрен дә яхшы белгән, шунлыктан аны патша табибләре арасындагы бер белгечкә тәрҗемәче итеп билгеләпләр. Мәгълүматларга караганда, Явыз Иван табибләре арасында бельгияле Арнольд Ленззэй булган. Күрәсең, шул кеше әлеге әсирне үз канаты астына алгандыр. Шлихтинг бу табибкә җиде ел буена тугры хезмәт күрсәткән, аннары язмышының кыл өстендә булуын чамалап, үз башлыгының тәләктәшлеген тоеп, Польшага качып киткән һәм әлеге «Кыйсса»ны язган.

Альберт Шлихтингның латинча язылган хәбәрләреннән аның ифрат дәрәҗәдә тирән белемлелеген, дворяннар сыйныфына хөрмәт белән караучы кеше икәнлеген чамалавы авыр түгел. Аның язмаларында 1570 елгы коточкыч ачлык та сурәтләнә. Шуңа да нигезләп, ахры, белгечләр аның «Кыйсса»сын 1570 елда язылган булырга тиеш дип табалар.

Шлихтингның латинча язылган хәбәрләрендә шундый юллар бар: «... Бөек корольгә язган бу белешмәләр минем Мәскәүнең үзендә үз күзләрем белән күргән хәлләрдән чыгып бирелә. Ә Русиянең башка зур вә кече шәһәрләрендә нинди кыргыйлыклар кылынганын яза башласаң, томнарга да сыймас иде».

Язманың авторын аеруча боярларны кыру, опричнина кертү, кенәз Иван Петровичны юк итү, казначы Дубровскийны, дьякон Казарин-Дубровскийны, үз кияве Михаил Темрюковичны изалаулары, Александр сараенда алып барыла торган җәзалаулар аеруча каты тетрәндергән. Патшаның өлкән улының холкын да автор хәйран калып сурәтли. Патша боерыгы буенча, Новгородка, Псковка ясалган канкойгыч «сәфәрләр», кенәз Федор Умныйның һәлакәте, кенәз Афанасий Вяземскийның үлеме, Торжок, Тверь кебек шәһәрләрнең җимерелүе, поляк әсирләренең кырылуы... белән тәгәлләнә. Хатын-кызларның бу патшадан ни дәрәҗәдә мәсхәрәләнүләре, кешеләрнең ач аюлардан талатылуы, тереләтә яндырылуы, патшага хезмәт күрсәтүче татарларның җәзалап юкка чыгарылуы...

Патша үзе яши торган урынга якын гына бер җирдә яңа сарай салдыра: «Бу махсус үтертү мәйданы иде, — ди автор. — Анда аның иң тугрылыклы үтерүчеләре тупланды».

Язма Явыз Иванга каршы 1567 елда оештырылган фетнәгә дә кагылып үтә һәм үзенчә аның уңышсызлыкка дучар булу сәбәпләрен аңлатырга тырыша.

Мин бу кульязманы барлык тарихи чыганаклар белән чагыштырып, мөмкин кадәр урыс теленә якынайтырга теләп тәрҗемә иттем.

А.МАЛЕИН,
язманы латинчадан тәрҗемә итүче.

Мәскәү залиме Васильевичның холкы һәм рәхимсез идарәсе турында кыскача белешмәләр

Моңа кадәр берәү дә Мәскәү кенәзе Васильевичның нинди дәрәҗәдә холыксыз булуын һәм акыл сәләтенең бик тә чамалы икәнлеген исәпләп тормагандыр. Андагы рәхимсезлекне, хакимияттән һич уйламыйча файдалануын, тирә-юнендәге яраннарына мәрхәмәтсезлеген телгә алырга да куркыныч. Мәскәүгә килүче чит ил кешеләре, йә сәүдә белән мавыгып, йә җае чыкмыйча, аны күрми дә китеп баралар. Очрашучылар исә, бу коточкыч шәфкатьсез кешене күреп, шүрләп, тизрәк кайтып китү ягын карыйлар иде. Аның нинди кыргыйлыкларга «оста» булуын Полоцки яулап алынганнан соң гына аңлый башладылар. Әлеге яудан соң һич тукталып тормаган кан коюлар, кайбер качак әсирләр пәйда була башлау бу залимнең коллык чорындагыдан да куркынычрак рәхимсезлеген фаш итте.

... Полоцкины алгач, тиран тәмам кыргыйланды. Ул җиңүче, аңа теләсә нинди миһербансызлык та кичерелә, янәсе. Аның шәфкатьсезлеге чиктән ашты: ул үзенең иң якын яраннарына ябырылды, бигрәк тә моңарчы абруй казанып өлгергән, ата-бабасыннан ук килгән мәртәбәгә ия кешеләрне җәберли башлады. Чөнки алар аны хакимияттә ничегрәк утырырга, гадел булырга, урынсызга христиан канын коймаска, гаделсез сугышлардан сакланырга өйрәтәләр иде. Русиянең мәйданнары киң, тормыш матур, христиан государе шуңа шөкер итәргә, тормыш рәхәтен күрергә тиеш иде! Инде сугышырга бик теләсәң, әнә, башка халыкларга — татарларга, төрекләргә каршы барырга кирәк, алар Мәскәү тирәсен болгатып кына яталар бит. Бу киңәшләрне ул кимсетү кебек кабул итә, алардан шикләнә, һәм, шул ачулы уйларыннан буыла язып, кулыннан килгән ерткычлыкларны кылырга тотына.

Дмитрий Овчина дигән кенәз бар иде. Ул Литва сугышлары вакытында мәскәүлеләрнең үзәгенә үткән король Сигизмундка әсирлеккә төшкән булган. Соңыннан ул иленә кайткан, исән-имин гомер кичереп яткан. Менә шул Овчинаны тиран үзенә кунакка чакыртып алган. Табында ул аңа урыс дәүләтенең иминлеге һәм алга китеше өчен бер чирек аракыны эчеп бетерергә боерган.

Дмитрий, бу боерыкның никадәр мәрхәмәтсез икәнлеген аңласа да, эчә башлаган. Белгән бичара әгәр аның бер генә тамчысын эчеп бетермәсәң дә, башың җәһәннәмгә олагачак. Тотынган эчәргә. Чүлмәкнең яртысына да җитмәс борын, бу бичара бәндәнең эчендәгесе кире килә башлаган. Шул чак залим аны үзенең исерткеч эчемлекләре саклана торган нәүрәпкә ташлаткан:

— Эчеп бетерә алмаганыңны әнә шунда минем исәнлеккә чомер! — дигән.

Овчина, бичара, сөенә-сөенә нәүрәпкә төшеп киткән. Анда исә ач этләр өере яшәп ята икән. Алар кенәзне мизгел эчендә өзгәләп ташлаганнар.

Дмитрий Овчинаның бу һәлакәтенә тагын бер сәбәп бар. Ул татарларга каршы сугышта дан алган буын кешесе Басманның Федор исемле улы белән килешеп бетмәгән. Федор, язмышында кечкенә генә бер күңелсезлек чыкса да, Овчинадан зарланып, гел Иван патша янына керә торган булган. Тагын шунысы мәгълүм: әлеге ысул белән Явыз Иван исәпсез-хисапсыз адәмнәрнең җанын кыйган.

Бу дәрәҗәдәге шәфкатьсезлеккә шаһит булган дин әһелләре, кайбер күренекле шәхесләр белән берләшеп, патшага киңәш бирергә, үз якыннары аңа тугры хезмәт күрсәтүчеләр белән алай миһербансыз кыланырга ярамавын кисәтергә теләгәннәр. Христиан кешегә мондый миһербансызлык килешми, ул кешегә карата гына түгел, хәтта хайваннарга да рәхимле булырга тиеш, дигәннәр. Шулай булмаганда, Ходай Тәгалә аның үзен генә түгел, өч буынына кадәр бөтен нәсел-нәсәбен җәзалаячак. Мондый кисәтүдән соң патша бераз басыла төшә акланырга һичнинди сәбәп таба алмыйча, тыелырга, җәзалаулардан тукталып торырга мәҗбүр була. Аның бу тынычлануы алты айлап дәвам итә. Әмма ләкин шушы «тынып тору» чорында залим үз тирәсенә яңа төр үтерүчеләр — опричниклар булдыру турында план төзеп ята. Үзе исә «изгелеккә бирелә», илаһи тормыш итү турында, хәтта монахларча яшәү хакында сүз тарата. Хакимият белән идарә итүне ике улына тапшыру турында да сөйли. «Минем җаным мине дөнья кайгыларыннан арынырга чакыра, — дип белдерә ул. — Гөнаһлардан арынырга вакыт миңа. Ә минем ике улым сезнең карамакка тапшырыла, аларны юлбашчылыкка кабул итегез! Әгәр минем берәр файдалы эш кылганым булса, сез аны минем улларым исеменә теркәгез, аларны олылагыз! Алар сезнең белән яшәрләр, сугышлар алып барырлар, аларга буйсыныгыз! Киңәш кирәк булса, мин һәрчак сезнең карамакта». Ул үзе генә аерым яшәр өчен Неглинная елгасы янында яңа йорт та төзетә. Бу сарай белән рәттән яңа биналар да калкып чыга. Монысы — опричнина өчен икән, ягъни яңа җәлладлар өчен.

Минем илемнең короле үзе янына берәр кешене чакыртса, ул адәмне соенеч белән ала, чөнки король аңа нинди дә булса яхшылык кылырга ниятләгәненә без инде ышанганбыз. Ә Мәскәүдә... патша янына чакырылган адәм бөтен нәсел-нәсәбе белән бәхиллешә, яңадан исән-имин өйләнеп кайтуына берәүдә дә ышаныч юк. Мәскәү каласында гади кешеләр дә бер-берсенә ышанмыйлар, берсе өстеннән икенчесе шикаять язып тәм таба, берсен икенчесе куралмый, көнләшәләр, кычкырышалар, кыйнашалар, үтерешәләр. Залимгә исә шул гына кирәк. Ул аларның берсе өстеннән икенчесе язган шикаятьләргә таяна.

вәхшилекләреннән соң ул аны татарларга каршы сугышка җибәреп, «гаебен» акларга мөмкинлек бирә. Тегесенең хәрби юлга чыгарлык кием-салымы да булмый хәтта. Әмма чарасызлыктан ос-башын, ат-иярен бер монах туганыннан алып, сугышка китә. Кайта. Аны яңадан Явыз Иванга чакырталар. Иоһанн, бөтен нәсел-нәсәбе белән бәхиллешеп, патша янына юлга чыга.

Бичараны залим үзе каршылый һәм аны әр-яңа киемнәргә киендерергә куша. Киемнәре исә нәкъ патшанекына охшатып тегелгән. Әлеге бичара патша кнеменнән килеп кергәч, аңа Явыз Иван үзе генә утыра торган кәнәфигә утырырга боералар. Нишлә-

лим хәтта терлекләрдә дә «сыный». Бергә җыелып торган сыер, ат көтүлекләрен кырырга тотына. Әлеге урыннарда яшәп ятучыларның хатыннарын көчләргә, балаларын изаларга куша. Үзе шушы күренешләрне карап торырга ярата. Тәмам шәрә калган хатыннарны урманнарга куалар, ә анда аларны явыз-вәхши ирләр көтеп тора, кычкыртып көчләүләр башлана. Патша исә шул вәхшилектән ләззәт ала. Залим Иоһаннның хатынын монастырьга кертергә боера. Бичара хатын шунда җан тәслим кыла. Шул рәвешле, әлеге воеводаның нәселе төбе-тамыры белән юкка чыгарыла. Ошбу җинаять Бельский һәм Мстиславский дигән кенәз-

часын яшерүчеләрне еш кына кыйната торган була. Кияүне дә шул юл белән куркыта ул: «Килсен, булган алтынын селкеп күрсәтсен!» Кияү. булган акчасын җыеп, аның катына барып баш игәч, патша аны бик каты кыйната, акчасын яшерүдә гаепли. Соңыннан, үз киявен дә башкалар белән тигез рәвештә җәзалавын аңлатып, мактана да икән әле.

Берсендә шундый хәл килеп чыга: «бөек» патшаның кучеры белән аның кияве Михаил Темрюковичның кучеры очрашалар. Нилектәндер алар кычкырыша

Русия турында яңа хәбәр

Явыз Иван йортында кем белән сөйләшергә белми аптырыйсың. Кайсы синең белән ихластан сөйләшә, ә кайсы синең фикереңне аңа җиткерергә тырыша? Синең хакта яман сүз ирештерсәләр, Иван сораштырып тормый, опричникларга сине үтерергә генә боера. Алары исә йә башыңны кисәләр, йә этләрдән ашаталар, йә болганчык күлгә батыралар. Аюдан теткәләндерүләре дә бик ихтимал.

Яңа урында яши башлагач, ул үзен аерата иркен тота башлый. Опричниклар дигән палачлары аны шәп саклыйлар. Һәм нәкъ менә шушында ул үз «дошман»нарын аеруча каты җәзага тарта башлый. Ул үзенең мондагы явызлыкларын инде дингә, үзенең «монахлык» тормышына бәйләп башкара. Ил алдында чын хезмәте белән дан казанган ирләрне, ата-бабасыннан калган мактаулы исемне аклап яшәүчеләрне кырдыра башларга җай эзли. Үтерелгән көндәшләренең гаиләләренә матәм хәбәрләре, кайгы уртаклашу язулары җибәртә, гаеплеләрне табарга тырышачагын хәбәр итә. Болар исә — барысы да аның уйдырмалары, хәйләсе, мәкере генә.

Мәсәлән, ул Түбән Новгород кенәзе Ростовскийны үтерергә боера. Ни өченме? Бу кенәз үз карамагына җибәрелгән әсирләр белән «йомшак» мөнәсәбәттә булган икән. Кемдер патшага шулай җиткергән. Имеш, ул Польшага китеп барырга да җыена икән. Үзенә карата мондый карарны ишеткәч, кенәз Ростовский үзләре чукына торган бинага керә. Артыннан ук килеп кергән эзәрлекләп килүчеләр аңа әйтәләр: «Кенәз, син — бөек патшабызның әсире...»

Шуннан соң бу бичара, үзенә тапшырылган таякны ташлап (ул чакта зур шәхесләргә шундый махсус таяклар бирелгән), дәрәҗәсенә тиешле киемнәрен салып, җәлладлар кулына төшә. Ул заманда, Явыз Иван кушуы буенча, теләсә кем кулга алынырга һәм үтерелергә мөмкин иде. Шул рәвешле, Ростовскийлар нәселеннән 50дән артык кеше үтерелә.

Кабаттан Мәскәүгә кайтып урнашкач, «бөек» Явыз Иван хәтта үзенең ышанычлылары арасындагы шәхесләрдән дә шикләнә башлый һәм аларны үтертергә керешә. Мәскәү гаскәрие Иоһанн Петровичны тәмам эштән чыгара ул. Алтын-көмешләреннән, затлы савыт-сабаларыннан мәхрүм итә, тәмам хәерчелеккә төшерә. Шул

рга дә белмәгән Иоһанн кушканны үти. Нихәл кылсын инде? Шулчак аның каршына Явыз Иван килеп баса да:

— Син эзләгәнеңне таптың. Мәскәүнең бөек кенәзе булдың һәм аның урынын, ягъни әлегәчә мин утырган кәнәфине алдың. Йә, шатлан инде! — ди.

Тирә-юньдә тынлык урнаша. Бераздан Явыз Иван кабат сүз башлый:

— Шунысын да әйтим инде, — ди ул. — Сине бу урынга утыртырга мәҗбүр иткән кебек үк, мин сине аннан төшертә дә алам бит!..

Шулай дип, залим пычак белән, бичараның күкрәгенә кадый. Бу эшне үзенең ялчыларыннан да эшләтә. Иоһанның бөтен эчке әгъзалары тышка айкалып чыга. Аның җансыз гәүдәсен Кремль һәм шәһәр буйлап сөйрәп йөртәләр. Бу хәлдән соң Иоһанның якыннарын да җәзалыйлар.

Коломна кальгасында (аны патша Иоһаннга биргән булган), өч йөзләп адәм баласы суга батырыла. Аларның шактые урыс булмый. Иоһанн воеводасын шул рәвешле һәлак итеп, патша үз үтерүчеләре белән бергә, ат менеп, елга тирәсен күзләп йөри. Кайбер «гаеплеләр»не табып, ул аларны чишендерергә боера, аерым читлекләргә яптыра, ә ул өйчекләргә әллә нинди агулы газлар җибәрттерә. Аңа бу «ачышы» шул хәтле ошый ки, ул үзен яңа бер ачыш ясаган галимдәй хис итә башлый. Бу вәхшилеген за-

ләр кулы белән эшләнә. Бу ике зат патшага каршы әйтә башласалар, Явыз Иван, күзен дә йоммыйча: «Мин һәм сез Мәскәүнең төп таянычын тәшкил итәбез, — ди. — Бөтен держава безнең әчебезгә таянып кына басып тора ала». Нәкъ шундый ысул белән ул бик күпләрне үзенә сүзсез буйсындырып тора.

Тагын бер мисалны телгә алмый мөмкин түгел. Монысы — залимнең үз казначысы Хозяин Дубровский белән булган хәл. Бу очракта патшаның кияве граф Михаил Темрюковичка аны урлап качарга һәм балалары-фәләннәре белән мәйданга илтеп ташларга кушыла. Шул хәлдән соң патша аның үзенең башын чабып өзәргә, хатынын һәм дә балаларын һәлак итәргә боера. Әлеге фаҗига вакытында ялгышлык белән һәлак булучының бер кызы күзгә чалына. Аны да, казначының туган энесен дә шул ук мизгелдә үтерәләр.

Явыз Иванның кияве Михаил Темрюковичны аеруча яратуы турында да әйтми мөмкин түгел. Патша аңа һәрвакыт мәрхәмәтлек күрсәтеп тора. Бу хәл утыз еллап дәвам итә. Әмма киявенә карата аз гына шик уянса да, ул аның йорты янына үтерүчеләр гаскәрен генә түгел, хәтта котырган аюлар, кыргый этләр өере дә җибәртә, котын ала. Тегә бичара өеннән чыгарга куркып, сыны катып, көннәр буе биктә ятарга мәҗбүр була. Куркуыннан ашый да, эчә дә алмый, саташыр хәлгә җитә. Ул гынамы соң, патша үз ак-

башлыйлар. Нәтиҗәдә Михаилның кучеры Явыз Иван кучерын изеп ташлый. (Урыслар шунсыз аерылыша алмыйлар бит инде — К.Т.). Соңыннан Иван Васильевичның кучеры бу хакта үзенең башлыгына әйтә. Сүз Явызга барып ирешә. Шуны белүгә, патша үз опричникларын (үтерүчеләрен) кияве утарына җибәрә һәм бу утарның өч кешесен асуларын таләп итә. Кияве берни эшли дә алмый. Һәр көнне асылган хезмәтчеләренең чайкалып торган гәүдәләрен күрергә мәҗбүр була ул. Бу мәсхәрәле хәл ундүрт көн дәвам итә.

Шул ук елны диярга дә була, Великие Лукидан әйләнеп кайткач, залим үз кулы астындагы опричникларга канцлер Казарин Дубровскийны юк итәргә боера. Үтерүчеләр тегенең өенә бәреп керәләр. Тегә бичара, аны-моны абайламыйча, ике улы белән уйнап утыра икән. Чапкалыйлар да ташлыйлар канцлерны. Гәүдәсенең кисәкләрен коега ыргыталар. Сәбәбе бер генә икән — әлеге Казарин үз кулы астындагы кешеләрдән ришвәт алган.

Әлеге канцлерның берданбер улы нәкъ шул көнне өйләнергә ниятләп башка якка чыгып киткән икән. Нәселенең патша галиҗәнапләре тарафыннан кырып бетерелгәнен ишетеп, ул качып китә, ел буе сукбай булып йөри. Аның ил буенча исән-имин йөрүе хакындагы хәбәр Явыз Иванга килеп ирешә. Бу хәбәрне белеп алган залим аны тиз арада эзләп табарга боера. Табалар, әлбәттә. Егетнең табылганын ишеткәч, патша аны, камчылап, дүрт өлешкә бүләргә куша. Егетнең һәр кулы вә аягы аерым бауларга бәйләп тагылган булырга тиеш икән. Ә һәр бауны унбишәр башкисәр тартып барырга мәҗбүр ителгән. Бу хәлдә адәм баласының тәне, хәтта ул тимердән коелган булса да, телгәләнми кала алмас иде. Бу шәфкатьсезлекне кыргыйлык белән генә дә чагыштыру мөмкин түгел! Әмма патша мондый вәхшилекләрне үз күзе белән карарга яраткан. Кайчак җәзаланучы бәндәнең тәненнән агып чыккан кан аның йөзенә үк чәчрәгән. Ул исә гайрәтләнеп кычкыра икән: «Шулай кирәк, шул кирәк!» Аңа кушылып башкалар да шул ук сүзне кабатлыйлар. Берәрсе эндәшми утырса, аңа тагын да катырак җәза бирелә торган булган.

(Дәвамы бар).

КУЯН КҮЧТӘНӘЧЕ

Мидхәт МИНШИН

САНАРГА ӨЙРӘНӘМ

БЕР

«Тор, кызым», дип әнинең
Бер әйтүе дә житә.
Сикереп торам, юынам,
Йокы күземнән китә.

Үземә бер щетка бар,
Үземә бер сабын бар,
Үземә бер сөлге бар,
Ашарга бер урыным бар;
Киемнәрем бер жирдә,
Туфләләрем бер жирдә —
Аунап ятмый берни дә,
Бер дигән тәртип өйдә.

Әти илтә бакчага,
Алып кайта әнием.
Алар өйдә булмаса,
Килеп житә әбием.

Үземә бер бүлмә бар,
Бер караватъ, бер өстәл,
Әби сөйләп өлгерә
Бер әкият бер кичтә.
Бер тәрәзә бүлмәмдә,
Тәрәзәдә бер кояш.
«Бел», димимен, «бер», диям —
Оялтмаслар зур булгач.

ИКЕ

Әби әйтә: «И, балакай,
Ике битең — ике алма,
Ике күзең — ике йолдыз
Йөзләреңдә балкып яна».

Әни әйтә: «Йөрәк парәм,
Ике кулың — ике канат.
Син очарсың бөркет сыман,
Яшәрермен сиңа карап».

Әти әйтә: «Ике тапкыр
Сөйләп тормый егет кеше.
Күзне ачып йомганчы ук
Эшләп куя бөтен эшне»

Ике битем — ике алма,
Ике кулым — ике канат.
Икеләнсәң, кара санап,
Ике тапкыр, ике кабат.

ӨЧ

«Кондыз» диеп атыймын
Мин үземнең атымны.
Аягы юк, ялы юк;
Ял көнендә ялы юк...
Өч көпчәкле «велик» ул
Һәм лә минем милек ул.

Линейка бар — өчпочмак,
Абый сыза өчпочмак.
Әни йөри пешереп
Тәмле-тәмле өчпочмак,
Таба саен куя ул
Өчәр-өчәр өчпочмак.

«Берәү», «икәү», «өч», диеп,
«Без жыябыз көч», диеп,
Чыныктырам үземне;
Шуңа бит мин түземле
Сикерәм дә, чабам да
Арганым да сизелми
Бер, ике, өч
Бер, ике, өч.

ДҮРТ

Урындыкта дүрт аяк,
Атларда да дүрт аяк.
Энем йөри мүкәләп —
Аның да бит дүрт аяк.

Беләсеңдер син аны,
Дөньяның бар дүрт ягы:
Көнчыгышы, көньягы,
Көнбатышы, төньягы.

Ел да дүрткә бүленгән,
Бар да төрле киемнән.
Яз, җәй, көзе чәчәкле,
Кышы карга төренгән.

БИШ

Әби бәйли бишбармак
Миңа сарык йонынннан
Йөрсен әле бармаклар
Рәхәтләнеп жылыда.

Һәр кулда да биш бармак,
Һәр аякта биш бармак
Нигә әби бәйләми
Аякка да бишбармак.

Аякларда бармаклар
Кочаклашып яталар.
Бүләк итте бабаем
Миңа киез каталар.

АЛТЫ

Алты катлы безнең йорт,
Алтынчы йорт урамда.
Күчкән идек анарга
Миңа алты тулганда.

Әни гора көн саен
Сәгать алты сукканда.
Бәхет качып китәр, — ди, —
Ярамый күп йокларга.

Сөйли башлый радио
Сәгать алты тулуга.
Хәерле көн тели ул
Безгә гомер буена.

ЖИДЕ

Күк йөзендә жиде йолдыз,
Жиде чишмә болында.
Матур-матур жырлар беләм
Мин дә алар турында.

«Жидегән йолдыз жиде әйләнә
Жиде төн уртасында.
Жидегән йолдыз нурлары бар
Битеңнең уртасында».

«Жидегән чишмәләрдә жиде улак,
Челтер-челтер ага көмеш су.
Көмеш сулар ага, кошлар сайрый,
Шул чакларда бигрәк ямансу».

Бер атнада жиде көн бар,
Жиде иртә, жиде кич.
Нигә иртә йоклаталар —
Төнне күреп булмый һич.

Әти әйтә: нишләсәң дә
Башта үлчә жиде кат.
Бу балакай пешмәгән, дип,
Көлешмәсен жиде ят.

СИГЕЗ

Сигезенче март — бәйрәм көне
Бөтен жирдә, дөньяда.
Сабан туе кебек зурлап
Әзерләнәм мин аңа.

«8»лене язып куям
Һәрберсенә бүләкнең.
Үзем рәсем ясый белгәч
Бүләк эзләп чиләнмим.

Сигезенче март бер булса да,
Бәйрәм булсын ел буе.
Әниләрне, әбиләрне
Соендерик ел буе.

ТУГЫЗ

Үз-үземә ышанмыйм,
Әллә күзем бәйләнә:
Борып куйсаң алтыны
Тугызлыга әйләнә.

Сизми калдык килгәнен
Туя белмәс тилгәннең:
Алып киткән чебешне —
Ни эшләргә белмәдем.

Ун чебешнең тугызы
Йөри хәзер чирәмдә.
Тугызының берсен дә
Бирмәм инде тилгәнгә.

Үз-үземә ышанмыйм,
Әллә күзем бәйләнә:
Борып куйсаң алтыны,
Тугызлыга әйләнә.

УН

Әби кайткан бакчадан,
Кәрҗинендә алмалар.
Әйтә миңа: «Аларны
Берәм-берәм санап ал.

Сиңа ничә яшь булса,
Шул кадәрле үзеңә.
Абыеңа калганы,
Аның туган көненә».

Миңа биш яшь тулды бит
Биш алманы алдым мин;
Күпме кала абыйга —
Инде шуны саныйм мин.

Бик тырышып санадым,
Аннан тезеп карадым:
Килеп чыкты ике рәт
Бишәр-бишәр алмалы.

Ике бишен ун була —
Ун яшь тула абыйга.
Яңып торган алмалар
Ямь өстәрләр табынга.

Әби миңа әйтсә дә
Биш алманы алырга,
Унга кушам бишне мин —
Бүләк булсын абыйга.

АЧКЫЧ

Әби күпме сынаса да,
Ялгыштыра алмады;
Саный белгәч унга кадәр,
Жиңел икән аннары.

Ун һәм берәү — унбер була,
Ун һәм ике — унике...
Унөч, ундүрт, унбиш, дидем —
Дөрес чыкты минеке.

Уналтысы, унжидесе,
Унсигез һәм унтугыз.
Унтугызга житү белән
Бераз уйлап торыгыз.
Унтугызга берне кушсаң,
Булып куя егерме.
Бу егерме дигәннәре
Ике дистә түгелме?
Ике дистә дә егерме,
Ике ун да егерме
Егермене йөгәнләдем,
Инде йөзгә йөгердем.

ТЫЯСЫМ

Матур-матур шакмаклар
Бүләк итте әтием.
Әй, әтием, әтием,
Сиңа ниләр әйтием?!

Һәр шакмакта берәр сан,
Бергә тезеп карасаң:
Исең китеп калырсың —
Мин дә белмим барысын.

Әти әйтә: шурләмә,
Төшенерсең серенә.
Төрле-төрле шакмаклар
Куеп кара берләңә.

Бер янында бер божра —
Ун була ул — бер дистә.
Миңа хәтле санарга
Өйрәнерсең бер кичтә.

Ике божра куюга
Шул берленен янына —
Бусы инде 100 була —
Әллә каян тапыла.

Баскыч ясыйм саннардан
Болай жиңел санарга.
Бердән 1000 гә менәргә
Ярдәм итим кемнәргә?!

Атналык манзара TV

Дүшәмбе
16 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.35 Мультфильм. 18.45 Балалар өчен «Тамчы». 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшырулар анонслары 19.40 «Түгәрәк өстәл» Реформалар программасы: ул нинди булырга тиеш? 20.10 «Әлли-бәлли-бәү» 20.20 Р.Миндияр җырлый. 20.30 Нәфис фильм. «Лес» 22.00 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «А в этой сказке было так...» 7.30 «КиноМеню» 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 8.15, 11.05 — «Юл патруле» Атналык йомгак 8.30, 14.45 «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!» (MTV) 9.20, 12.55 — «90х60х90» 9.40 Диск-канал. 10.00 «Канун» 10.30 Сериал: «Один к десяти» 11.20 Атна фаразлары. 11.50 «Валюта бәясе» 12.00 Нәфис фильм: «Мстители» 3 нче серия. 13.10 Нәфис фильм: «Не может быть» 15.00 Телесериал. «Флиппер» 5 нче һәм 6 нчы серияләр 15.55 «Кино музыкасы» Б.Сичкин 16.10 «Минем кино». М.Кокшенов 16.50 А.Габриловичның документаль фильмы. «Цирк нашего детства». 17.40 «Минем тарих» А.Градский. 18.25 Теледискотека. 19.30 «Видеомода» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.45 — «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Лариса» яңалыклары. 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Нәфис фильм: «Памяти Каролины» (Анни Жирардо). 23.15 «Криминаль хроника тележурналы». 0.05 Нәфис фильм: «Договор Холкрофта».

1 НЧЕ КАНАЛ

16 октябрьдә көндезге сәгать 3 кә кадәр 1 нче, «Русия», «Санкт-Петербург» каналларында профилактик эшләр.

15.00, 18.00, 0.00 — Яңалыклар. 15.20 Мультсериал. «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Марафон-15» 16.00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 16.55 «Джем». 17.30, 1.20 — «Спортның җиде көне». 18.15 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен. «Көен таны» 20.00 «Әгәр...» В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 Фантастик детектив. «Электронные жучки» (Багз). 3 нче серия. 22.50 «Тарих табышмаклары» циклыннан. Э.Радзинский. «Акыллылык үзе бер бәла». 23.30, 0.10 Сериал. «Твин Пикс»

Төнге канал. 1.50 Сериал: «Ставка больше, чем жизнь». 2.45 «Джаз дөньясында».

«РУСИЯ»

15.00 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «РОСТ» компасы. «Евровидение концертында яшь талантлар» 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 17.20 «Яңа тармак» (Самара). 17.50 «Алыргамы-алмаскамы». 18.00 Ирекле көрәш. Русия һәм Дөнья җыелма командалары. 18.30 «Коткару-911» 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 «Дүшәмбе саен детектив». «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм: «Грехи отцов» (Бөекбритания). 21.40 Репортер. 21.55 Клип-антракт В.Меладзе. 22.05 «Хакыйкать мизгеле». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Нәфис фильм: «Горькая кровь» (АКШ). 1 нче серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле». 13.25, 15.40, 22.35 — «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм: «Фунтик и старушка с усами». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.45 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Заноза» (Грузия). 17.20 Мультфильмнар: «Цветочная песенка», «Бояка мухи не обидит», «Муммидол приходит осень». 17.55 «Мәхәббәт тиңләшә...» 21.35 «Шәһәр эшләре». 21.55 «Иминлек тәләсмәте». 22.05 «Театр бинокле». 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Музыкаль шоу: «Телекомпакт». 0.15 Нәфис телефильм: «Валентина» (Италия). 5 нче серия.

Сишәмбе
17 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.00 Балалар өчен телеспектакль. «Алтын чеби» 18.50 Мультфильм 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19.35 «Тукталыш» 19.50 «Әлли-бәлли-бәү» 20.10 «Изгелек һөнәрчесе» Рәссам Б.Н.Зыков 20.40 Күп серияле нәфис фильм премьерасы «Тарзан» 20 нче һәм 21 нче серияләр (Мексика - Канада - Франция) 21.25 «Ерактагы якын кардәшләр...» Себер татарлары белән очрашу 22.15 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм. «Колесо Фортуны» 7.30, 20.20, 23.45 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (16 октябрь тапшыруын кабатлау) 8.15, 11.05 «Юл патруле» 8.30, 14.50 «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!». 9.20, 12.55 «90х60х90» 9.40 «Диск-канал» 10.00 «Минем кино» М.Кокшенов 10.40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11.20 «Атна һәлакәтләре» 11.50 «Валюта бәясе» 12.00 Сериал: «Спасатели Малибу» 13.10 Нәфис фильм. «Сказание о земле Сибирской» 15.00 «Музыка һәм матбугат» «Каләм осталары» Ю.Саульский 15.55 «Телекүпер» Мәскәү — Атланта (АКШ) 16.35 «Сатира» театрының юбилей кичәсе 18.40 Сериал: «Против течения» 6 нчы серия 19.30 «Актуаль әңгәмә» Казан шәһәренең Эчке эшләр идарәсе башлыгы Н.Әкбәров 19.40 Мультфильм «Чертенок № 13» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе» 21.05 Мультфильм «Шиворот-навыворот». 21.15 Телеэкспресс 21.35 Туры эфирда уен. «Кичке аваз» 22.20 Русия киносы көне Нәфис фильм. «Дьявольская карусель» 0.05 Өлкәннәр өчен мультфильм. «Новые приключения мальчика-с-пальчика»

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00, 6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 8.30 «Көн хроникасы. Һава торышы» 6.05, 7.05, 8.05 Спорт яңалыклары. 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7.10 Мультфильм. 7.20 «Пресс-экспресс» 7.40 «Шанс» 7.45 «Яшьләр өчен яңалыклар» 7.50 «Монетный двор» 8.10 «Иртә» кунагы. 8.40 «Зәңгәр ут» 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 — «Яңалыклар» 9.15 Телесериал: «Тропиканка» 10.55 «Кеше һәм закон» 11.30 Телеуен. «Көен таны» 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 Сериал: «Приключения Шерлока Холмса и доктора Ватсона» «XX век начинается» 2 нче серия. 14.05 Сериал: «Ставка больше, чем жизнь» 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь» 15.40 «Күңелле квампания» кварьетесы. 15.50 «Мультитроллия» 16.10 «Тылсымлы дөнья, яки Синема» 16.35 Яшьләр өчен сериал. «Элен и ребята» (Франция). 17.00 «16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен» 17.30 «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен. «Көен таны» 20.00 «Тема» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт». 21.50 Никита Михалков фильмнары: «Без свидетелей». 23.30 «Мәскәү Кремль» 23.50, 0.10 — Сериал: «Твин Пикс»

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Минем Русия» В.Астафьев һәм М.Полторанин әңгәмәсе. 9.35 Нәфис фильм: «По ком тюрьма плачет» 10.45 «Телегазета» 10.50 «Мөһим мизгел» 11.20 «Милиция хроникасы» 11.30 «Безнең хәбәрчедән». Базар ябылганда. 11.50, 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений» 12.15 «Яңа тармак» 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «РОСТ» компасы. «Тозлы җил» 16.50 «Ай тотучы» 17.20 «Дөнья хәтерли» 18.15 Клип-антракт А.Губин. 18.20 «Сезнең партнер». 18.30 «Телебәхәсләр». 19.00 А.Гурнов. «Саф инглизчә репортаж» 19.10 «Л» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Киномарафон. И.Чурикова, М.Ульянов һәм С.Любшин Г.Панфиловның «Тема» фильмында. 22.25 «Мәхәббәт йолдызнамәсе» И.Понаровская. 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел». 23.40 Криминаль хәбәрләр экраны. 23.50 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Горькая кровь» (АКШ) 2 нче серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә» 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Язалар». 9.40 «Рекордлар». 10.10 «Бибу-шоу» 10.20 «Төш юрау». 11.15 «Аукцион» 12.10 «Джаз» 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле» 13.25, 15.40, 17.40 — «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 Нәфис фильм: «Лурджа Магданы» 16.55 Мультфильмнар 17.50 «Бүген Русия буйлап». 18.00 Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә.
21.55 «Кино йорты» «Катрин Денев, Педро Альмадовар, Майкл Найман һәм башкалар...» 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Нәфис фильм: «Тартюф»

Чәршәмбе
18 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.20 Мультфильм 18.30 Музыкаль телефильм «Странник в Булгаре» 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19.35 «Авыл» Лаеш районында очрашулар 20.05 «Әлли-бәлли-бәү» 20.15 «Шигърият» З.Мәҗитов 20.25 «Болл» клубы 20.55 Киноның 100 еллыгына Нәфис фильм «Идиот» 1 нче серия Рольләрдә Ю.Яковлев, Ю.Борисова 22.00 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.50 «Зарядкага басыгыз!» 7.00 Мультфильм: «Белоснежка» 1 нче серия 7.30, 20.20, 0.25 — «Шәһәр» информацион программасы 7.55 Телеэкспресс (17 октябрь тапшыруын кабатлау) 8.15 «21 нче параграф» 8.40 «Тарыш» 9.10 «Бөтенләй башкалар» «Цирк балалары» 9.40 Сериал «Один к десяти» 10.10 «Тегеләр, кемнәр...» 10.30 «Атна низаглары» 11.00 Нәфис фильм. «Кузен, кузина» 12.20 А.Политковский программасы «Волгоград окопларында» 13.10 Сериал «Ночная жара» 14.10 «Юл патруле» 14.25 «ПОСТ» — музыка яңалыклары» 14.40 Диск-канал «Нирвана» 15.40 «Эфирда музыка» 15.50 «Русская живопись XX века» циклыннан документаль фильмнар «Азбука в картинках», «Алое на голубом», «Противостояние Марса» 17.25 «Актуаль әңгәмә» Янгын куркынычсызлыгы айлыгы 17.35 М.Шуфутинский — Әлмәттә 19.20 «Поза» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Казан» автосалоны 21.15 Телеэкспресс 21.35 «Үз кешеләр» 22.10 Нәфис фильм. «Река»

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00, 6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 8.30 «Көн хроникасы. Һава торышы» 6.05, 7.05, 8.05 — Спорт яңалыклары. 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7.10 Мультфильм. 7.20 Пресс-экспресс 7.40 «Досье» 7.50 «Монетный двор» 8.10 «Иртә» кунагы. 8.40 «Стиль» 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.20 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал. «Тропиканка» 10.05 «Тема» 10.50 «Хайваннар дөньясында» 11.30 Телеуен. «Көен таны» 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 «Обыкновенное чудо» 1 нче серия 14.00 Сериал: «Ставка больше, чем жизнь» 15.20 Мультсериал. «Виджит спешит на помощь» 15.40 «Кактус һәм К» 15.55 «Күңелле ноталар» 16.10 «Джунглилар чакыруы» 16.35 Яшьләр өчен сериал. «Элен и ребята» (Франция) 17.00 «Тет-а-тет» 17.30 «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 Телеуен. «Көен таны» 20.00 «Югалтылганнарны эзләгәндә» В.Володин. Г.Скороходов алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21.45 «Көлкеле манзара». Е.Петросян алып бара. 22.20 Футбол. Чемпионнар лигасы. «Русенборг» (Норвегия) — «Спартак» (Мәскәү) Норвегиядән трансляция. 0.30 Футбол. Чемпионнар лигасы. 7 матчка күзәтү...

Төнге канал: 1.55 Сериал. «Ставка больше, чем жизнь»

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Үтә яшерен» 9.30 Клип-антракт Лицца. 9.40 «Телегазета» 9.45 «Крестьян мәсьәләсе» 10.05 Телесериал: «Санта-Барбара» 11.20 «Гадәттән тыш канал» 11.30 «Сезнең партнер» «Газпром» 11.50, 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений» 12.15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 — «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Көнчыгыш» 17.20 «Яңа тармак» «Ерак Көнчыгыш» 18.15 «Видеошигърият» С.Есенин. 18.25 «Сезнең партнер» 18.40 «Көтү залы» 19.25 «Үз уены» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара» 21.30 М.Боярский доминосы. 22.05 «Гадәттән тыш канал» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «Криминаль хәбәрләр экраны» 23.50 Экранда «Дебют» Кыска метражлы нәфис фильмнар: «Плохая квартира», «Частная история»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 7.45, 11.45 «Тәҗрибә» 8.15 «Киношче» 8.45 Балалар өчен 9.15 «Гүзәллек» 10.10 «Бибу-шоу» 10.20 «Төш юрау» 10.40 «Такмаклар» 11.15 «Аукцион» 12.10 «Джаз» Фильм: «Московской группе «Лига Блюза» 15 лет» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары. 13.25, 15.40, 22.00 — «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм «Домовые, или Сон в зимнюю ночь» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм: «Мануэла» 15.15 Бакчачыларга киңәшләр 15.45 Нәфис фильм: «Тартюф» 17.20 Документаль фильм: «Мировая душа» 17.50 Балалар телевидениесе. Мультфильмнар. «Там, где живет Паутиныч», «Три колеса, фолиант и...» 22.05 «Блеф-клуб» 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Юмористик программа. «Золотой телец» 0.05 Нәфис фильм премьерасы: «Валентина» (Италия). 6 нчы серия.

Пәнҗешәмбе
19 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 «Чулпан» информацион программасы 17.30 Мультфильмнар 17.50 Г.Андерсен «Оле Лукойе» Әдәби-музыкаль композиция 18.20 «Яшәү мохите» Экологик программа 18.50 «ГАИ мәгълүматлары» 19.00 «Татарстан» 19.30 «Хөкүмәт сәгате» 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.10 «Телемарафон» Әфган сугышы кайтавазы. 22.40 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм. «Дядюшка Ау в городе» 7.30, 20.20, 0.25 «Шәһәр» информацион программасы 7.55 Телеэкспресс (18 октябрь тапшыруын кабатлау) 8.15, 10.50 — «Юл патруле» 8.30, 14.50 «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» 9.20, 13.20 «90х60х90» 9.40 Диск-канал. 10.00 Юмористик сериал «Один к десяти» 11.00 «Нью-Йорк, Нью-Йорк» 11.30 Детектив сериал «Ночная жара» 13.25, 16.20 — Нәфис фильм «Клетка для канареек» 15.00 «Тегеләр, кемнәр...». 15.20 Ток-шоу «Мин үзем» «Шалтырат миңа, шалтырат» 17.45 CNN «Стиль» 18.05 Мультфильм «Топчумба» 18.15 Диск-канал «Мәхәббәт көйләре» 19.15 «Минем пейджерым бар һәм мин тыныч» 19.20 «Ушуайя» 19.40 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе» 21.05 «Казанские ведомости» нәрсә турында язды?» 21.15 «Телеэкспресс» 21.35 «Бары тик кызык өчен генә» 22.05 Нәфис фильм «Последнее лето в Танжере» (Франция-Италия)

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00, 6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 8.30 «Көн хроникасы. Һава торышы» 6.05, 7.05, 8.05 Спорт яңалыклары. 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7.10 Мультфильм. 7.20 «Пресс-экспресс» 7.45 «Яшьләр өчен яңалыклар» 7.50 «Монетный двор» 8.10 «Иртә» кунагы 8.35 «Ел буе... яшелчә бакчасы» 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал «Тропиканка» 10.05 Футбол Чемпионнар лигасы «Русенборг» (Норвегия) — «Спартак» (Мәскәү) 2 нче тайм «Легия» (Польша) — «Блэкберн» (Англия) 2 нче тайм 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12.50 «Обыкновенное чудо» 2 нче серия 14.00 Сериал «Ставка больше, чем жизнь» 15.20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15.40 «Лего-го» 16.10 «Гин-тоник» 16.35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» 17.00 «Рок-дәрес» 17.30, 1.35 «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал. «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 «Лотто-миллион» 20.00 «Күзгә-күз» А.Любимов алып бара 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21.50 Н.Михалков фильмнары. «Урга территория любви» 23.50, 0.10 «Музыка күзәтүе» 0.45 Сериал «Твин Пикс»

Төнге канал 2.05 Сериал. «Ставка больше, чем жизнь»

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 Мульти-пульти. «Петух и боярин» 9.00 «Пушкин йорты» 9.40 «Телегазета» 9.45 «Крестьян мәсьәләсе» 10.05 Телесериал. «Санта-Барбара» 11.20 «Милиция хроникасы» 11.30 «Сәүдә йорты» 11.45, 17.25 Мультсериал. «Камень сновидений» (Бөекбритания) 12.10 «Клип-антракт» «Браво» төркеме 12.15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 — «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Яңа тармак» «Сүнгән йолдыз?» 17.20 «Беркем дә онытылмаган» 17.50 Клип-антракт Т.Буланова. 17.55 Футбол. Кубоклар иясе кубогына. 1/8 финал. «Динамо» (Мәскәү) — «Градец-Кралове» (Чехия). «Динамо» стадионыннан трансляция (Тәнәфестә — «Сезнең партнер» «Русиянең тимер юллары»). 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара» 21.30 «Битлек-шоу» 22.10 Киноафиша. 22.25 «Әйдәп баручы фаразы» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 Футбол УЕФА кубогына. 1.30 Сәүдә йорты. «Ле Монти»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 7.45, 11.45 «Тәҗрибә» 8.45 «Язалар» 9.15 «Гүзәллек» 9.40 «Рекордлар» 10.10 «Бибу-шоу» 10.20 «Төш юрау» 11.45 «Аукцион» 12.15 «Спартак» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле» 13.25, 15.40, 17.10, 17.45 — «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм. 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телесериал: «Мануэла» 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 Нәфис фильм: «Любовь с первого взгляда» 17.15 Ретроэкран. Телевизион фильм: «Лицей. 19 октября» 17.50 «Бүген Русия буйлап» 18.00 «Ленинград өлкәсе» телекомпаниясе күрсәтә

21.30, 21.15 Фильмоскоп. Нәфис фильм «Астенический синдром» 23.00 «Спорт, спорт, спорт...»

ҖОМГА

20 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы 17.45 Балаларга фильм «Принц Ходоп и принцесса Рангал» 19.00 «Татарстан» 19.30 «Татарстан Дәүләт Советында» 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.10 «Ислам чакыруы» 20.20 «Җомга көн кич белән» Альманах. 21.00 Нәфис фильм «Идиот» 2 нче серия. 22.00 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

6.50 «Зарядкага басыгыз!» 7.00 Мультфильм «Белоснежка» 3 нче серия 7.30, 20.20, 0.20 – «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 «Телеэкспресс» (19 октябрь тапшыруын кабатлау) 8.15, 11.05, 17.45 «Юл патруле» 8.30, 14.45 – «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» 9.20, 12.55 «90x60x60» 9.40 Диск-канал 10.00 А.Политковский программасы «Волгоград окопларында» 10.30 Юмористик сериал «Один к десяти» 11.20, 15.55 «Спорт атнасы» 11.50 «Валюта бәясе» 12.00 Детектив сериал «Ночная жара» 13.00 Нәфис фильм «Ангел IY» (АКШ). 15.00 «Тегеләр, кемнәр » 15.20 Сериал: «Мелочи жизни» 16.25 Фантастик нәфис фильм «Темная звезда» 18.00 «ПОСТ» музыка яңалыклары 18.20 Иерусалимнан хәбәрләр 18.40 «Суперспорт» 19.00 Нәфис фильм «Корабль любви» 7 нче серия 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Көннәрнен ямьсезләре булмый» 20.55 «Экология хәбәрчесе» 21.00 Мультфильм «Кошкин дом» 21.15 Телеэкспресс 21.35 Сериал «Сирены» (АКШ) 22.30 Нәфис фильм «Нечто» 0.40 «Эротика Венеры» телепрограммасы

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00 6.30 7.00, 7.30 8.00 8.30 – «Көн хроникасы. Һава торышы» 6.05, 7.05, 8.05 Спорт яңалыклары 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7.10 Мультфильм 7.20 «Пресс-экспресс» 7.40 «Гайбәтләр» 7.50 «Монетный двор» 8.10 «Иртә» кунагы 8.45 «Нечкәлекләр» 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 23.50 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал «Тропиканка». 10.05 «Күзгә-күз» А.Любимов алып бара. 10.45 Документаль фильм «Сергей Есенин». 11.30 «Бар да өйдә чакта» 12.10 Эфирда – «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12.50 Телефильм «Лев Гурыч Синичкин» 14.00 Сериал «Ставка больше, чем жизнь» 15.20 Мультсериал «Отверженные» 15.50 «Яңа чыңбарлык» 16.05 Фильм-әкият «На златом крыльце сидели» 17.30, 1.40 «Спортның жиде көне» 18.20 Телесериал «Тропиканка» 19.10 «Кыргый кыр» 19.25 «Кеше һәм закон» 19.55 «Могжизалар кыры» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21.50 Н.Михалков фильмнары «Автостоп» 22.55 «Караш» 0.00 Төнге кинозал Гүзәл һәм албасты «Макс моя любовь» фильмында

Төнге канал 2.05 Сериал «Ставка больше, чем жизнь» 3.10 «Жыр-95»

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 17.00, 20.00, 23.00 – «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк ..» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 Сәүдә йорты «Ле Монти» 8.50 «Ритмика». 9.05 «Клип-антракт» Л.Нежданная 9.10 Антреприза В.Стрежельчик 10.00 «Телегазета» 10.05 Телесериал «Санта-Барбара» 11.20 «Милиция хроникасы» 11.30 «Сәүдә йорты» 11.45 «Крестьян мәсьәләсе» 12.05 Мульти-пульти «Веселая карусель» 12.15, 17.20 – «Яңа тармак» 12.30, 14.20 – «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Онытылган көн» 16.50 «Ай тотучы» 17.35 Мультконцерт «Романтики с большой дороги». 18.00 «Җомга саен Дисней» Нәфис фильм: «Зорро» 21 нче, 22 нче, 23 нче серияләр. 19.25 Вертикаль «Хөкүмәтнең эш көннәре» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал «Санта-Барбара» 21.30 «Үз-үзенә режиссер». 22.05 «К-2» тәкъдим итә «Фрак народа» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 Италия киносы фестивале У.Тоньяцци һәм А.Эме Б.Бертолуччиның «Трагедия смешного человека» фильмында 1.35 «Ералаш»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 7.45, 11.45 – «Тәҗрибә». 8.15 «Киношче» 8.45 «Балалар өчен» 9.15 «Гүзәллек» 10.10 «Бибу-шоу» 10.20 «Төш юрау» 10.45 «Такмаклар» 11.15 «Коллекционерлар» 12.10 Джаз 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.50 – «ТВ мәгълүматлары» 13.10 «Яшәү стиле» 13.25, 15.40 – «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телесериал «Мануэла» 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 А.Глазунов «Раймонда». Мариинский театры 17.05 «Кино йорты» «Аерылышуларсыз очрашу» 18.05 Балалар телевидениесе «Әкият арты әкият».

21.30 Нәфис фильм «Зеленый фургон» 23.05 «Спорт, спорт, спорт » 23.20 Нәфис фильм «Ловцы душ»

ШИМБӘ

21 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы 19.05 «Татарстан» 19.35 «Гадәти шимбә» 20.10 «Әлли-бәлли-бәү» 20.20 «Күзгә-күз — сүзгә-сүз» Рауза Хәйретдинова. 21.30 «Болл» клубы 22.00 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.50 «Зарядкага басыгыз!» 7.00 Мультфильм: «Белоснежка» 4 нче серия 7.30, 20.20, 0.45 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (20 октябрь тапшыруын кабатлау) Узган атна тапшырулары 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (17 октябрь тапшыруын кабатлау) 8.30 «Видеомода» 8.50 «Лариса» яңалыклары 9.20 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 9.30 «700 нче клуб» 10.00 «Казан автосалоны» 10.30 «Поза» 11.00 «Үз кешеләр» 11.35 «Атнага бер тапкыр» юмористик тапшыруы 12.00 Шимбә сериалы: «Флиппер» 5 нче һәм 6 нчы серияләр. 12.50 «Кино музыкасы» Никита Михалков. 13.05 «Хәрби телевидение» 13.35 «Безгә әле һаман да кызык» Сатира театрының юбилей кичәсе 15.30 «Эфирда музыка» 15.45 Телесериал: «Тропическая жара» 16.40 Телесериал: «Детективы на полставки» 17.35 «Яшерен йомыш» 18.00 «Дублик» 18.20 «Исәнмесез». 20.45 «Мавыгулар дөньясы» 21.15 Сериал: «Сирены» (АКШ) 22.10 «Музыкага чикләр юк» 23.15 Нәфис фильм: «Фантазм» 1.05 «Red Wave» тәкъдим итә. 1.30 «Эротика Венеры» телепрограммасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

7.45, 9.10 — «Уяныгыз» телеканалы 8.45 «Пастырь сүзе» Митрополит Кирилл 9.00, 15.00, 18.00, 23.50 – Яңалыклар 10.30 Балалар өчен күңел ачу программасы «Оттырма» 11.00 «Иртәнге почта» 11.30 «Тәмле». 11.50 «Бомонд» 12.15 В.Васильева «Язмышыма рәхмәт әйтәм» 12.55 Телесериал: «Живопись великие имена» 13.25 Н.Гогольнең «Нос» фильмы геройлары 15.20 «Автомобиль һәм мин» 15.50 «Хайваннар дөньясында» 16.30 «Европага тәрәзә» Д.Киселев алып бара. 17.00 «Шулай бервакыт» 17.10 «Бәхетле очрак» 18.20 Кинематография. 18.55 Н.Михалков фильмы «Анна от 6 до 18» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21.50 Тарихи сериал «Приключения королевского стрелка Шарпа» (Бөекбритания) 3 нче серия 22.55 «Брэйн-ринг» 23.45 «Русиянең иң яхшы мультипликациясе». «Выставка» 0.00 Микки Рурк «Красавчик Джонни» фильмында

Төнге канал 1.35 Евровидениенең эстрада җырлары конкурсы

«РУСИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 – «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызлар сөйли» 8.30 «Вовкулакия: яки Убырлар иле» 8.45 «Өмет стартлары» 9.00 Нәфис фильм «Одиссея» (Канада) 9.30 «Алтын ачкыч» 9.50 «Этикетка». 10.00 «Парламент атнасы» 10.45 «Винил джунглие» 11.15 «Мәскәүгә кадәр ерак» 12.00 «Пилигрим». 12.45 «Яңа тармак» 13.05 Зур хоккей. 13.45 «Кайнар Уңлык» 14.20 «Де факто» 14.35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм. «Влюбленный в мадам Мегрэ» 1 нче кисәк 15.25 «Веди» 15.55 «Берлин-Мәскәү-Берлин» Ике башкаланың мәдәният көннәре 16.25 «Дөнья экраны йолдызлары» 16.55 Футбол. Русия чемпионаты. ЦСКА — «Спартак» (Владикавказ). «Динамо» стадионыннан трансляция 19.00 «Йолдызлар яңгыры» 20.25 Киномарафон. А.Фрейндлих һәм А.Мягков Э.Климованың «Похождение зубного врача» фильмында. 22.05 «Үтә яшерен» 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел» 23.40 Концерт

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос – бөтен дөньяда» 8.00 «Хәерле иртә» 10.00 «Яшәү стиле» 10.15 «Атналык тапшырулар программасы» 10.20 Балалар өчен нәфис фильм «Три толстяка» 11.45 Мультфильм «Чертенок № 13» 11.50 Күңел ачу программасы «Приказано выжить» 12.05 Телефильм «Сен-Жермен де Пре» (Франция). 12.40 «Рандеву» Агата Кристи. 13.10 Теледоктор 13.30 «Тест» 13.45 «Тарихи альманах» 14.15 Нәфис фильм «Чужая». 15.35 Балалар телевидениесе. «Алтын ачкыч», «Ыргыт, әйдә!» 16.35 «Гыйбадәтханә» 21.35 «Оранж» телевидениесе «Теләмәсәң – карама» каналын тәкъдим итә 22.45 «Информ-ТВ» 23.05 Нәфис фильм «Я не обещала тебе сад роз» (АКШ)

ЯКШӘМБЕ

22 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.35 Балалар өчен «Фазыл бабай әкиятләре» 19.00 «ТОН» (атналык телекүзәтү) 19.35 «Автокалейдоскоп» 19.50 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.05 Б.Рафиков. «Париж башкорты» Стәрлетамак башкорт дәүләт драма театры спектакле 21.30 «Күңел чишмәләре». Мөслим көзе 22.20 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). Узган атна тапшырулары. 8.30 «Шәһәр» 8.55 Коммерция әйләнмәсе (19 октябрь тапшыруын кабатлау) 9.15 «Бары тик кызык өчен генә» 9.45 «Ушуайя» 10.05 «Суперспорт» 10.25 «Дублик». 10.45 «Мавыгулар дөньясы» 11.15, 16.45 «Эфирда музыка» 11.30 «Барысын да белергә телим». 11.50 Мультфильм. «Сказка о двух котятах» 12.00 «Атна фаразлары» 12.20 «Подводная «Одиссея» команды Кусто» 13.20 «Атнага бер тапкыр» 13.50 Э.Сагалаев программасы: «Кешеләр дөньясында» 14.40 Нәфис фильм: «Не самый удачный день» 16.15 «Кино музыкасы» Юлий Ким җырлары 16.35 Телесериал «Тропическая жара» 17.50 Телесериал: «Детективы на полставки» 18.45 Сериал: «Спасатели Малибу» 3 нче серия. 19.45 «КиноМеню». 20.15 «Жирле вакыт». Информацион программа 20.45 Нәфис фильм «Цель: Гарри» (АКШ). 22.20 «Битлекләр» банк таләпләр. 22.50 «Исәнмесез!» (22 август тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.50 «Спортлото» тиражы 8.00, 9.10 «Уяныгыз!» телеканалы 9.00, 15.00, 17.10, 0.00 — Яңалыклар. 10.30 «Бар да өйдә чакта». 11.00 «Иртәнге йолдыз» 11.50 «Беренче куллардан» 12.00 «Русиягә хезмәт итәм». 12.30 Лукошкино авылы рейтингы 13.00 «Чегән җырлары». 13.30 «Пи» билгесе астында». 14.00 Телесериал: «Мой друг — лошадь». 14.30 Миров, Новицкий һәм башкалар 15.20 «Сәяхәтчеләр клубы». 16.15 Мультфейерверк «Легенды острова сокровищ», «Погонщики динозавров», «Подарок для слона». 17.30 Н.Михалковның юбилей кичәсе 19.15 Премьера «Утомленные солнцем». 22.00 «Якшәмбе» 23.05 Тарихи сериал «Приключения королевского стрелка Шарпа» 4 нче серия 0.10 Футбол күзәтүе.

Төнге канал 0.40 Документаль сериал «Духовные голоса» 3 нче серия 2.10 «Наутилус Помпилиус».

«РУСИЯ»

8.00 «Формула-1» автоярышлары буенча дөнья чемпионаты «Тын океан» гран-прие. 11.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр 10.00 «Хәерле иртә!» 10.30 «Агы-баты ..» 11.15 «Рус лотосы» 12.00 «Консолидация» 12.05 «Хайваннар дөньясында» 13.00 «Футболга чикләр юк» 13.45 «Клип-антракт» «Л.Агутин» 13.50 «Беренче нөсхә» 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык» 14.35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм: «Влюбленный в мадам Мегрэ» 2 нче кисәк. 15.20 «Параллельләр». Кипрас Мажейка. 15.35 «Клип-антракт». «На-на» төркеме. 15.40 «Китап киштәсе» 16.10 «Безнең бакча» 16.40 «Урысча Караоке». 17.10 «Өч баһадир». 18.00 Мультфильмнар «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха» 18.55 «Комедия положений» «Фредди Стар». 19.25 «Видеошигърият» И.Бунин. 19.35 «Тапшырулар тартмасы». 19.50 «Клип-антракт» «О.Газманов белән» 20.25 Нәфис фильм «Одержимые» 22.25 «Ксюшада кунакта» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «Хроно» 0.10 Музыкаль тапшыру «Оставайтесь в шляпе»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез» 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә» 10.00 «Яшәү стиле». 10.15 Мультфильм «Еловое яблоко» 10.25 Нәфис фильм «Плоть» 12.00 «Якшәмбе лабиринты» 13.15 Документаль фильм «Дороги Алехо Карпентьера» (Франция). 14.14 Мультфильм 14.30 «Страсти-мордасти»: 14.45 «Классика-5» 15.30 «Депутатларга сүз бирабез» 16.00 В.Борисов-Мусатовка багышланган документаль телефильм «Русская песня» 16.25 Футбол буенча Италия чемпионаты.

21.25 «Телекомпакт» тәкъдим итә 22.05 «Янган кульязмалар» М.Булгаков 22.30 «Карарбыз» 22.45 ТВ мәгълүматлары 23.05 «Адәм алмасы» 23.50 «Адәм һәм Хава плюс»

ДҮШӘМБЕ, 16 ОКТЯБРЬ

6.00, 19.15 – Соңгы хәбәрләр 6.15 «Иртәнге дулкында» 6.48, 20.33 «Татарча өйрәнәбез» 6.53, 7.58, 20.38 – Һава торышы 6.55, 7.50 Белдерүләр 7.00 Информацион-музыкаль программа 7.45, 20.38 – Тапшырулар программасы 8.00, 18.30, 20.45 – Радио-1 14.00 Радио-1 Музыкаль очрашулар. Күзәтү Татарстан радиосы тапшыруы 17.45 «Язучылар – балаларга» Ж.Дәрзаман. 18.15 «Дүшәмбедән – дүшәмбегә». Мәдәният-сәнгать яңалыклары. 19.45 «Һәвәскәр башкаручылар концерты».

СИШӘМБЕ, 17 ОКТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 – Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында» 6.48, 20.33 «Татарча өйрәнәбез» 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 – Һава торышы 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.15 Концерт 7.45, 12.25, 20.38 – Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18.30, 20.45 - Радио-1. 12.25–14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта. 12.30 Башкортстан артистлары концерты 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 «Турыдан-туры элемтә» 17.45 «Яшьлек» студиясе 18.15 «Көн темасына». Әңгәмәләр, аңлатмалар. 19.45 «Р.Ишморат, Х.Вахит шигырьләренә язылган җырлар».

ЧӘРШӘМБЕ, 18 ОКТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 – Соңгы хәбәрләр 6.15 «Татарстан дулкынында» 6.48, 20.33 «Татарча өйрәнәбез» 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 – Һава торышы 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.15 Концерт 7.45, 12.25, 20.38 – Тапшырулар программасы 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 - Радио-1 12.25–13.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы Чыгарылышта 12.30 Концерт «Без Татарстан җирендә яшибез» 13.10 Республика газеталарына күзәтү 18.00 «Старт» (Татар телендә) 19.45 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 19 ОКТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 – Соңгы хәбәрләр 6.15 «Иртәнге дулкында» 6.48, 20.33 «Татарча өйрәнәбез» 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 – Һава торышы 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.15 Концерт 7.45, 12.25 20.38 - Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 – Радио-1 12.25–14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта 12.30 «Балалар җырлый». 13.10 Республика газеталарына күзәтү 18.05 «Эшмәкәрләр клубы» 19.45 «Р.Сәйфи, Р.Харисов, И.Сафин һәм С.Гарифуллин житәкчелегендәге ... концерты»

ҖОМГА, 20 ОКТЯБРЬ

6.00 «Балкыш» 6.48, 20.33 «Татарча өйрәнәбез» 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 – Һава торышы 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.00, 13.05, 19.15 — «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт 7.45, 12.25, 20.38 – Тапшырулар программасы 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 – Радио-1 12.25-13.30 «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта. 12.30 З.Хисмәтуллина концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.45 «Педагог, музыкант, инженер Р.Халитова» Концерт-очерк

ШИМБӘ, 21 ОКТЯБРЬ

6.00, 7.00 Соңгы хәбәрләр 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт 6.58, 7.58, 14.30 Һава торышы 7.15 Концерт. 7.45, 14.30 Тапшырулар программасы 7.50 Белдерүләр 8.00, 10.30, 14.35 Радио-1 8.15 «Сезнең хатларыгыз» 8.40 «Көмеш кыңгырау» 9.00 «XX гасыр интеллекты» 9.30 Әдәби редакция программасы. «Ә.Сафиуллин һәм Б.Камал хикәяләре» 10.00 «Гасырларны бәйләүче җепләр» 11.45 «Татулыкка ни җитә» 12.15 Татар халык көйләре 13.10 Яңалыклар кафетасы 13.30 «Яшьлек» студиясе 14.00 «Көнге».

ЯКШӘМБЕ, 22 ОКТЯБРЬ

7.02, 7.58, 13.40 – Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 Тапшырулар программасы 7.50 Белдерүләр 8.00 «Идел белән Урал арасында» Ике республиканың берләштерелгән радиожурналы 9.00 «Гөлбакча» 9.30 «Гаделлек сагында» Язучы Мәгъсүм Насыйбуллинга 70 яшь 10.15, 16.00 - Радио-1 12.15 «Сәламәтлек» 12.45 Ял концерты 13.45 «Татарстан дулкынында». 14.20 Н.Исәнбәт «Өбугалисина» Радиоспектакль.

Сагыналар сине якын дуслар, сагыналар сине сайрар кошлар...

27 октябрьда «Медени җомга» газетасы һәм Сара Садыйкова фонды соекле композиторыбызның әдәби-музыкаль кунакханәсендә чираттагы табынны ачып җибәрәләр. Бу уңайдан газетабызның махсус хәбәрчесе Нияз АКМАЛ Сара Садыйкованың мәдәни-хәйрия фонды рәисе Әзһәр ХӨСӘЕНОВ белән әңгәмә корды.

— Әзһәр әфәнде, Сара апа табыны инде елдан артык эшләп килә. Ул үз тирәсенә бик күп сәнгать әһелләрен туплады. Ә минем исә сүзне калфактан башлыйсым килә. Чөнки Сез «Сара апаның ак калфагы» диген сүзне үзегез бик еш кабатларга яратасыз...

— Әле калфак кию, түбәтәй кию турында беркем дә уйламаганда, мондый эш кемнәрдәдер шелтәле сүз уяткан бер вакытларда да Сара апа гел калфак киде сәхнәләргә гел калфактан чыкты Менә үзегез үк әйтеп үттегез Сара апа табыны үз тирәсенә бик күпләрне туплады дидегез Ә миңа калса Сара апаның ак калфагы — барлык хатын-кызларыбызны барлык сәнгать кешеләрен гомумән, аның җырларын иҗатын үзен яраткан кешеләрне, халкыбызны берләштергән, туплаган символ ул

— Быелгы беренче табын яңе дә аның туган көне алдыннан ачыла...

— Әйе 1 ноябрь — Сара апаның туган көне Быел да без аның истәлеген яңартып бу көнне татар зиратына барабыз Сара апаның кабере Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким кабере янәшәсендә Хәтта уртасында дип әйтер идем Күрәсезме Сара апаның язмышыдырмы бу — монда да ул ике олы шигъриятне берләштерә кебек..

Зиратка без Татарстан Композиторлар берлеге бинасы янынннан кузгалып китәбез Анда искә алу җыены узачак. Сара апаның, Сибгат абый белән Хәсән абыйның каберләренә чәчәкләр салып кабер тирәләрен барлап-чистартып кайтачакбыз Бу митингка халык та җыелыр дип уйлыйм

— Әзһәр әфәнде, Сара апа үз җырлары аша меңләгән-миллионлаган кешеләрнең язмышына килеп тоташа. Аның табынына исә, гадәттә, үзе белән якыннан аралашкан, очрашкан, хатирәләр саклап калган, аның иҗатына турыдан-туры бәйле булган кешеләр җыела. Аларның истәлекләрен тыңлап, Сара апа турында тагын да күбрәк беләсе, тагын да күбрәк ишетәсе килә. Мин үзем дә Сара апаның үзе белән азмы-күпме аралашып калган кеше. Әмма һәрбер истәлек миңа аны әр-яңадан ача кебек. Әйтик, миңа халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повестен журнал өчен редакцияләргә туры килгән иде. Шунда, сугыштан кайткан ир-атларның, хатын-кызларның авыл клубында татарның беренче тангосына биюләре турында укып, күземә яшьләр килгән иде. Татарның беренче тангосын Сара апа Садыйкова язган! Хәтерлисезме: «Син кайларда йөрисең икән...»

— Әйе. «Сагыналар сине якын дуслар сагыналар сине сайрар кошлар ..» Ә сезнең әлеге җырның ничегрәк тууы турында ишеткәнегез бармы? Сара апа үзе миңа болай дип сөйләгән иде 1941 елда аның тормыш дусты армиягә алына, фронтка Менә шундый бик әрнүле-сагынулы көннәрдә — салкын декабрь аенын бер көнендә — трамвай тукталышында туңып-биеп басып торганда Сара Садыйкова газиттән бер шигырь укый Әхмәт Ерикәйнең «Көтәм сине» дигән шигыре Шунда ук аның күңелендә инде булачак җырның моңнары туа башлый

— Без «Мәдәни җомга»да Сара апаның әлеге җырын һәм дә «Бәхилләшү» повестеннан әлеге өзекне тәкъдим итәргә уйлыйбыз. «Бәхилләшү» сүзе аның истәлегенә күләгә салмастыр бит? Бәхилләшмибез, сагынабыз бит Сара апаны...

— Шулай нәкъ үз җырындагыча «Сагыналар аны якын дуслар сагыналар аны сайрар кошлар»

— Бу җырны радио аша беренче тапкыр башкарган җырчы бәхетле: ул елларда әлеге җырны бит, үз йөрәк ярасы итеп, меңләгән йөрәкләр күтәреп алган...

— Ул елларда да, хәзер дә шулай Җырны ул үзе үк беренче башкарган Киләчәктә меңләгән йөрәкләрнең моңы булачак Сара апа ..

Үткәнебезгә яңача бер караш

(Ахыры Башы 12 нче битта)

Василий Блаженный соборы кем хөрмәтенә салынган?

...Русиядәге «реформалар заманы» күп урыс изгеләрен канунлаштыру һәм исәрләргә искиткеч игътибар заманасы булды Ул вакытта Мәскәүдә җәен-кышын өстенә кимичә муенына авыр яга асып йөргән «гаҗәп шәрә адәм» бик зур хөрмәттә булган икән. Ул Василий Блаженный була Аның вафаты Разряд Приказының рәсми язуларында да билгеләп үтелә (Бер сәер нәрсә игътибарны җәлеп итә Разряд Приказы — ул дини түгел. ә дөньяви учреждение һәм чиркәү вакыйгаларын билгеләп үтү аның эше түгел. Ә исәр изге дип канунлаштырылмый торып, аның үлеме чиркәү вакыйгасы да булмый — (Авт) Исәрне күмәргә Троица-Сергий монастырена бик күп халык җыела

Иван IYнең бердәнбер чын портреты Копенгагенда саклана Русиядә аның портретлары калмаган (?!) Шунысы сәер Грозныйның бу портреты портрет түгел, ә чиркәү иконасы

Бу икона-портретка Иван IY исеме язылган Димәк ки патша Иван IY изге итеп канунлаштырылган булган Әлбәттә инде патша булгач ул Василий Блаженный исеме белән канунлаштырылган «Василий» — грекча «патша» дигәнне аңлата Димәк ки авыруыннан соң Иван IY эшләреннән читләшә «Блаженный»га (рәхәт кешегә) әйләнә Дүрт елдан соң (1557 елны) ул үлә һәм аны күп халык җыелып Троица — Сергий лаврасында җирлиләр вафатын Разряд Приказына теркәп куялар (бусы инде — табигый хәл. Гади бер исәрне түгел ә бөек патшаны җирлиләр ләбаса!

Хөер Догалыкта (Свяца) Мәскәү могҗизачысы Иван Блаженный да искә алына Әмма аның тәрҗемәи хәле турында берничә дә мәгълүматлар юк Күрәсең, бу шул ук Василий Блаженныйны (Иван IY) икенче тапкыр искә алу гынадыр Догалыклар XYII гасырның беренче яртысында төзелгән һәм аларның инде моның шул бер үк кеше икәнлеген оныткан да булулары ихтимал Шуның өстенә чиркәүдә кычкырып укыганда Иван Блаженный никтер искә алынмый Юкса алар Мәскәүдә өчәү генә булганнар бит Максим Василий һәм Иван Шулай итеп Иван белән Василий — бер үк адәм булып чыга

Иван IYнең (Василий Блаженныйның) иң-иң мәшһүр гамәле — Казанны яулап алу Мәскәүнең Кызыл мәйданында атаклы храмны салу әнә шул вакыйгага багышлана инде

Аның гөмбәзләре мөселман чалмалары рәвешендә эшләнгән Бу да аның Казанны алуга багышланганын раслап тора Шулай да без аны бүгенге көндә дә Василий Блаженный соборы дип йөртәбез Димәк ки без шушы атамада да Казанны алуны Василий Блаженный исеме белән бәйлибез

Шулай итеп гаҗәеп тигезләмә килеп чыга Иван IY = Василий Блаженный

Хөрмәтле укучылар! Әгәр «Мәдәни җомга» атналык газетасына язылырга ниятләсәгез, күргәнегезчә, атаклы шәхесләребезнең истәлекле култамгаларына да ия булачаксыз. Һәм сезнең почта бүлекчәләренә килүегез элемтәчеләребезгә дә рәхмәт әйтергә форсат бирер. Менә бит ул «Мәдәни җомга»ны алдыруның файдалы яклары!

«Мәдәни җомга» газетасы өегезгә нур естәсен!

Илһам ШАКИРОВ — *Гариф АХУНОВ*

Луиза БАТЫР-БОЛГАРИ — *Равил ШӘРӘФИЕВ*

Хөрмәтле элемтәчеләр, почта хезмәткәрләре! «Мәдәни җомга»ны яздырып таратуыгыз өчен чын күңелдән рәхмәт сезгә.

Баш мөхәррир — *Зиннур МАНСУРОВ*



Әсрар ШАКИРҖАНОВ фотосы.

ҮЛЧӘҮ ЙОЛДЫЗЛЫГЫ АСТЫНДА ТУГАННАР

КОТЛЫЙБЫЗ!

13 октябрь

ӘГЪЛӘМОВ Мөдәррис (ӘГЪЛӘМЕТДИНОВ Мөдәррис Зөфәр улы) — шагыйрь.

ӘХМӘДУЛЛИН Азат Гыйлмулла улы — Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

ДӘРЗАМАНОВ Җәүдәт Харис улы — язучы.

ИЛЬИН Игорь Иванович — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры оркестры артисты.

КУЗИНА Флера Әнәс кызы — Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты.

14 октябрь

КОРЧАГИН Владимир Владимирович — язучы.

ХОДЖИЕВА Гәүһәр Әбүбәкер кызы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты.

15 октябрь

ГАЛАНИН Иван Дмитриевич — РФнең атказанган архитекторы.

ЗАРИПОВА Наилә Гата кызы — композитор.

РАВИЛОВ Габделхәмит Зариф улы — Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү институты директоры, ветеринария фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире, Татарстанның һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе.

16 октябрь

ГАЛИЕВ Әсрар Абрар улы — язучы.

ЛАЗАРЕВА-ГЫЙЛМАНОВА Елена Ивановна — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры балет солисты.

МӨХӘММӘТГАЛИЕВА Луиза Илдус кызы — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры балет солисты.

17 октябрь

ҖИҺАНШИНА Рәшидә Абдуллаҗан кызы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Татарстанның һәм РФнең халык артисты.

18 октябрь

САФИУЛЛИН Юныс Габдулла улы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының әдәби бүлеге мөдире, драматург

19 октябрь

ИГЛАМОВ Рәүф Мәхмүд улы — театр белгече, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә профессор вазифаларын башкаручы.

Куанычтыр бергә булулар

Мөхтәрәм җәмәгать, газета укучылар!

Исегезгә төшерәбез: киләсе ел өчен көндәлек матбугатка язылу дәвам итә. Җөмһүриятебездә нәшер ителә торган дистәләрчә басмалар арасында «Мәдәни җомга» милли матбагачылыкны баетырлык байтак яклары белән аерылып тора:

«Мәдәни җомга» — татар дөньясында әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен үзәккә алып яктыртучы, халкыбызның рухи елъязмасы булган бердәнбер газета;

«Мәдәни җомга» — һәр атнаның бишенче көнендә 24 битле булып чыгучы иң саллы басма;

«Мәдәни җомга» — күләме ягыннан карaганда иң арзан газета.

Язылу бәясе:
1 елга — 36 мең сум;
6 айга — 18 мең сум.
Газетаның индексы — 54129.

Хөрмәтле милләттәшләр!

Туган халкыбызның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген каләм сәнгате югарылыгында тулы итеп чагылдыручы «Мәдәни җомга» Сезнең күңелләрегезгә һәрьяктан хуш килер һәм өегезгә һәрдаим нур өстәп торыр, дип ышанабыз.

Ф СП-1

АБОНЕМЕНТ на газету **54129** (индекс издания)

Мәдәни ҖОМГА

Количество комплектов

на 19 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (Фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ	место	литер

на газету **54129** (индекс издания)

Мәдәни ҖОМГА

Стоимость	подписки ___руб. ___коп	Количество комплектов
	переадресовки ___руб. ___коп	

на 19 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (Фамилия, инициалы)

Газетабызның 10 нчы санында чыккан кроссвордның җаваплары

ГОРИЗОНТАЛЬ БУЕНЧА: 5 Алеша 7 «Юану». 8 Флаг 9 «Саламторхан» 12 «Казан» 14. Ито 16 Ананд 17 Нигъмәт 18 Ефремов 19 Борис 21 Шик 23 Уткин 27 Дэббетеларз 28 Убыр 29 Егет 30 Очкын

ВЕРТИКАЛЬ БУЕНЧА: 1 «Таулар» 2 «Депутат» 3 «Сафура» 4 Наташа 6 «Фараон» 10 Бакиров 11 Антоним 13 «Намус» 14 «Иптәш» 15 Очерк. 16 «Асрау» 20 Исәнбәт. 22 «Иптәшкә» 24 Тәрҗемә 25 Оберон 26 Элпенс

Татарстан мәдәният министрлыгы, халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча республика фәнни-методик үзәге, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, республикада хореография сәнгатен үстерүдә зур көч куйган режиссер, хореограф

Котдус Хәбибрахман улы ХӨСӘЕНОВның

каты авырудан соң вафат булуы сәбәпле, гаиләсенең, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Мәдәни ҖОМГА

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары хималәсендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты: 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре турында 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4461